Татарстанда
# ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ
№2 ИЮНЬ 2016
МЕСТНОЕ САМОУПРАВЛЕНИЕ В ТАТАРСТАНЕ
ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ П2268




## Сабантуй – 2016. Татарстанны танытучы бәйрәм

40 бит

*Татарстанда*
# ҖИРЛЕ үзидарә
**МЕСТНОЕ САМОУПРАВЛЕНИЕ В ТАТАРСТАНЕ**

№2, июнь 2016
Мәгълүмати-аналитик, иҗтимагый-сәяси басма

**БАШ МӨХӘРРИР**
Нияз ӘХМӘДУЛЛИН, e-mail: redaktorms@gmail.com

**БАШ МӨХӘРРИР УРЫНБАСАРЫ**
Надил ГЫЙМАДЕТДИНОВ

**ЧЫГАРЫЛЫШ МӨХӘРРИРЕ**
Фәридә Әхмәтҗанова

**АВТОРЛАР**
Наталья Аксенова, Лилия Нурмөхәммәтова,
Линар Закиров, Людмила Карташова

**ФОТОГРАФ**
Андрей Титов

**ВЕРСТКА**
Евгений Курьянов

**КОРРЕКТОР**
Айсылу Корманова

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәт Идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү турындагы таныклык ПИ №ТУ 16-00621, 29.09.2011.

Журнал татар һәм рус телләрендә нәшер ителә.
Гомуми тираж: 3270 данә (татар телендә – 1341 данә,
рус телендә – 1929 данә)



Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстанда җирле үзидарә» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.



**РЕДАКЦИЯ:**
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2нче йорт
Тел.: (843) 293-60-15

«Казанская недвижимость» Нәшрият йорты» ЯАҖндә басылды.
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2нче йорт
Заказ: № 13347
Офсет басма
Басарга кул куелды: 16.06.2016

16+

**Гамәлгә куючы һәм нәшер итүче:**
**«Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы» Ассоциациясе,**
**420014, Татарстан Республикасы, Казан, Кремль**


## ЭЧТӘЛЕК




*УН елдан соң (Татарстан муниципаллары беренче юбилейларын билгеләп үтте)* 6 **бит**





*РЕЙТИНГ турында бәхәс* 10 **бит**





*КИЛӘЧӘККӘ хат!* 12 **бит**



**РЕДКОЛЛЕГИЯ:**
РӘИС –
**Шакиров Минсәгыйть Закирович,** Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе

**Андреева Людмила Николаевна** – Казан шәһәр думасы секретаре

**Белов Александр Николаевич** – Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре буенча департамент җитәкчесе

**Воропаева Татьяна Васильевна** – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе урынбасары

**Гарипов Илнур Мәхмүтович** – ТР Президенты Аппараты җитәкчесе урынбасары – ТР Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы

**Гусева Любовь Акимовна** – сәясәт фәннәре кандидаты, КФУның дәүләт һәм муниципаль идарә кафедрасы доценты

**Ратникова Римма Атласовна** – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары

**Хәбибуллин Альберт Галимҗанович** – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе



*ПРОФЕССИОНАЛЛАР өчен семинар*
**14 бит**

*РЕСПУБЛИКА саннарда*
**18, 30, 50 бит.**





*ТИҮ ярдәм итсен*
**20 бит**

*АГЛОМЕРАЦИЯЛӘРДӘ җирле үзидарә: нәтиҗәлелек проблемалары*
**22 бит**





*ЭШ – уртак, өлеш – шәхси*
**26 бит**

*АВЫЛ язмалары*
**32 бит**






*ТУГАН җир тарта*
**36 бит**

*САБАНТУЙ-2016*
**40 бит**



*ЯРЛАРНЫ югалтмыйк*
**42 бит**

*БӨРБАШ аксакаллары*
**46 бит**





*ЧИРМЕШӘН районы: киләчәккә инвестицияләр*
**52 бит**

*КАНУН яңалыклары*
**58 бит**



*Татарстанда*
# ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ
**МЕСТНОЕ САМОУПРАВЛЕНИЕ В ТАТАРСТАНЕ**

№2, июнь 2016
Мәгълүмати-аналитик, иҗтимагый-сәяси басма

**БАШ МӨХӘРРИР**
Нияз ӘХМӘДУЛЛИН, e-mail: redaktorms@gmail.com

**БАШ МӨХӘРРИР УРЫНБАСАРЫ**
Надил ГЫЙМАДЕТДИНОВ

**ЧЫГАРЫЛЫШ МӨХӘРРИРЕ**
Фәридә Әхмәтҗанова

**АВТОРЛАР**
Наталья Аксенова, Лилия Нурмөхәммәтова, Ленар Закиров, Людмила Карташова

**ФОТОГРАФ**
Андрей Титов

**ВЕРСТКА**
Евгений Курьянов

**КОРРЕКТОР**
Айсылу Корманова

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәт Идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү турындагы таныклык ПИ №ТУ 16-00621, 29.09.2011.

Журнал татар һәм рус телләрендә нәшер ителә.
Гомуми тираж: 3270 данә (татар телендә – 1341 данә, рус телендә – 1929 данә)

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстанда җирле үзидарә» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

**РЕДАКЦИЯ:**
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2нче йорт
Тел.: (843) 293-60-15

«Казанская недвижимость» Нәшрият йорты» ЯАҖндә басылды.
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2нче йорт
Заказ: № 13347
Офсет басма
Басарга кул куелды: 16.06.2016

16+

**Гамәлгә куючы һәм нәшер итүче:**
**«Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы» Ассоциациясе, 420014, Татарстан Республикасы, Казан, Кремль**

# ЭЧТӘЛЕК



*УН елдан соң*
*(Татарстан муниципаллары беренче юбилейларын билгеләп үтте)* **6 бит**



*РЕЙТИНГ турында бәхәс* **10 бит**



*КИЛӘЧӘККӘ хат!* **12 бит**

**РЕДКОЛЛЕГИЯ:**
РӘИС –
**Шакиров Минсәгыйть Закирович,** Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе

**Андреева Людмила Николаевна** – Казан шәһәр думасы секретаре

**Белов Александр Николаевич** – Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре буенча департамент җитәкчесе

**Воропаева Татьяна Васильевна** – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе урынбасары

**Гарипов Илнур Мәхмүтович** – ТР Президенты Аппараты җитәкчесе урынбасары – ТР Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы

**Гусева Любовь Акимовна** – сәясәт фәннәре кандидаты, КФУның дәүләт һәм муниципаль идарә кафедрасы доценты

**Ратникова Римма Атласовна** – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары

**Хәбибуллин Альберт Галимҗанович** – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе

## НӘТИҖӘЛЕЛЕКНЕ НИЧЕК БИЛГЕЛӘРГӘ?



8 июньдә Кремльдә ТР Муниципаль берәмлекләре Советы Президиумының чираттагы утырышы булды. Чара видеоконференция режимында узды, анда республиканың барлык район һәм шәһәрләре катнашты. Аның эшендә ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, ТР Премьер-министрының беренче урынбасары Алексей Песошин, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, ТР икътисад министры Артем Здунов, республика министрлыклары һәм ведомстволарының җаваплы хезмәткәрләре катнашты. Утырышны Совет рәисе Минсәгыйть Шакиров алып барды.

Көн тәртибендәге төп мәсьәлә – ТР муниципаль хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген нинди төп күрсәткечләр буенча билгеләячәкләрен карадылар. Җирле хакимият органнарының эшен бәяләү нигезендә система авторлары күрсәткечләрнең ике төркемен кулланырга тәкъдим итәләр – ирешелгән нәтиҗәләр буенча бәя һәм процесстагы (аерым кушылган эшләрне башкару буенча). Утырышта катнашучылар яңа системаны кулланып карау өчен, пилот муниципаль берәмлекләр итеп республиканың Яшел Үзән, Түбән Кама һәм Теләче районнарын билгеләделәр. Әлеге пилот мәйданнарында ел ярым вакыт эчендә тупланган тәҗрибәне алга таба калган муниципаль берәмлекләргә дә күчерәчәкләр. Система авторлары әйтүенчә, «аны премияләр системасына да бәйләргә була. Система җитәкчеләргә үзләренең кул астындагыларның эшчәнлеге нәтиҗәсен күреп барырга, эш күләме белән идарә итәргә һәм матди кызыксындыру күләмен дөрес итеп билгеләргә мөмкинлек бирәчәк».

Президиум шулай ук Интернет челтәрендә гражданнарның ТР шәһәр округлары һәм муниципаль районнары җитәкчеләренең эш нәтиҗәләренә карата мөнәсәбәтен ачыклауга юнәлтелгән халыктан сораштыру нәтиҗәләренең дөреслеге һәм объективлыгы проблемасын да карады. Катнашучылар шулай ук иң яхшы ТИҮне ачыклау буенча республика бәйгесенең нигезләмәсенә төзәтүләр керттеләр, бәйгенең бүләкләү фонды узган елгы кебек үк 50 миллион сум тәшкил итә.

## ХЕЗМӘТ ХАКЫ ТУРЫНДА БӘХӘС



19 майда ТР Премьер-министры Илдар Халиков республиканың профсоюз активы белән очрашты. Чарада катнашучылар төп мәсьәлә итеп хезмәт хакының күләме турында фикер алыштылар.

ТР Профсоюзлары федерациясе рәисе Татьяна Водопьянова профсоюзларның республикада хезмәткә түләү дәрәҗәсенең түбәнлегенә, соры хезмәт базары булуына, бай һәм ярлы гражданнарның керемнәре арасындагы аермага җитди борчылуын ассызыклады.

«Без бүген чынбарлыктагы хезмәт хакы буенча минуста», – дип белдерде ул. Байларның керемнәре ярлыларныкыннан 17 тапкырга артык, өстәвенә, бу аерма үсә бара. «Керемнәр аермасы турында сөйләгәндә, югары звено җитәкчелек белән гади хезмәткәрләрнең хезмәт хакы арасындагы балансны саклау буенча чаралар күрелүен истә тотарга кирәк. Реаль сектор өчен бүген бу кулланылмый диярлек», – диде ул. Татьяна Водопьянова 2015 ел йомгаклары буенча хезмәт хакының номиналь күләме 5,7 процентка артты, ләкин реаль хезмәт хакы 6 процентка кимеде, дип хәбәр итте.

ТР Премьер-министры Илдар Халиков күтәрелгән проблемаларның ни дәрәҗәдә мөһим булуы белән килеште, шулай да хезмәт хакы дәрәҗәсен генә түгел, тормыш дәрәҗәсен дә карарга тәкъдим итте. Ул Татарстанның хезмәт хакы буенча Идел буе федераль округында беренче торуын һәм бездә азык-төлек кәрзиненең иң арзаннардан берсе булуын искәртте. Аның мәгълүматларына караганда, реаль хезмәт хаклары 2015 ел йомгаклары буенча 93,7 процент тәшкил иткән, кулланучылык активлыгы да кимегән (2015 елда, 2014 ел белән чагыштырганда, 13 процентка). Шул ук вакытта агымдагы елның гыйнвар-апрель айларында әлеге активлык 1 процентка түбәнәйгән – бу уңай үзгәрешләр турында сөйли. Агымдагы елның апреленә бәяләр 2015 елның декабренә карата 102,1 процентка арткан, шул рәвешле инфляциянең акрынаюы турында сөйләргә мөмкинлек бар.



## МУНИЦИПАЛЛАР ӨЧЕН ФИНАНСЛАР

Апрель ахырында Россия Федерация Советында Федерация Советы каршындагы Җирле үзидарә буенча совет һәм Дәүләт Думасы Рәисе каршындагы шундый ук Советның уртак утырышы булды. Утырышта катнашучылар җирле үзидарә өлкәсен законнар белән тәэмин итү һәм хокуклар куллану практикасы мәсьәләләре турында сөйләштеләр. Чараны Федерация Советы Рәисе Валентина Матвиенко һәм Дәүләт Думасы Рәисе урынбасары Владимир Васильев үткәрде.

Думаның Федератив корылыш һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча комитетының рәисе, Бөтенроссия муниципаль берәмлекләре конгрессы президенты Виктор Кидяев муниципалитетларның икътисадый хәле темасына да кагылды: «Без штрафларның, ягулык-майлау материаллары акцизларының, патент, бердәм авыл хуҗалыгы салымының урыннарда калуына ирештек. Тагын физик затларның милегенә, Техник инвентарьлаштыру бюросы буенча түгел, ә базардагы хакы буенча  салынган салым бар, гәрчә әлеге механизмны камилләштерәсе булса да. Боларның барысы да миллиард, бернечә миллиард бирәчәк, шул ук вакытта җирле бюджетлардагы җитешмәүчелек аннан күбрәк суммалар белән билгеләнә». Конгресс президенты физик затларның кеременә салымны һәм транспорт салымын җыю системасын акчалар салым түләүчеләрнең яшәгән урыны буенча җирле бюджетка керә торган итеп үзгәртергә тәкъдим итте. Ул шулай ук башка тәкъдимнәрен дә җиткерде. «Муниципалитетлар үзләрен асрамада итеп түгел, ә илнең социаль-икътисадый үсешендә актив катнашучы итеп хис итәргә тиеш», – дип ассызыклады Виктор Кидяев.

Утырышта катнашучылар алдында РФнең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры Михаил Мень чыгыш ясады. Ул министрлыкның муниципалитетларда төзелеш алып бару өчен рөхсәт биргәндә административ каршылыкларны киметү өстендәге эшләре турында сөйләде. Министр игътибарны иң яхшы муниципаль практикаларның төбәкләрдә кулланылуын популярлаштыруның, «Иң төзек шәһәр (авыл) җирлеге» бәйгесен уздыруның ни дәрәҗәдә мөһим булуына юнәлтте, болар муниципалитетларга төзекләндерү эшен тагын да тизрәк алып барырга этәргеч бирә, дигән фикерен белдерде.



## ТӨП ТАРМАК ДИНАМИКАСЫ

«Татнефтехиминвест-холдинг» ААҖнең Директорлар советы республиканың нефть-газ химиясе комплексының 2016 елның I кварталындагы үсешенә йомгак ясады. Тулаем алганда, республикада нефть чыгару, шулай ук аны эшкәртү, пластик масса эшләү күләмнәре үсә. Квартал йомгаклары буенча химия продукциясе җитештерү быелтыргы дәрәҗәдә калган. Шуның белән бергә ягулык тармагы компанияләренең сатудан кергән акчасы, табышы һәм республика бюджетына аерып бирелгән суммасы кимегән. Химия һәм нефть химиясе буенча «Аммоний» комплексын эшләтә башлау, төп химия предприятиеләрендә, «Кварт»та һәм «Химград»та сату арту аркасында үсеш күзәтелә. «Татнефть» агымдагы елның I кварталында нефть чыгару күләмен 5,4 процентка арттырган – 6 млн 847 мең тоннага җиткергән. Кече нефть компанияләренең үсеше 1 процент тәшкил иткән. Уңай динамика борауланган скважиналарның санын арттыру белән бәйле.

Нефть продуктларын җитештерү 2016 елның I кварталында 4,2 процентка арткан, шул исәптән дизель ягулыгын җитештерү – 26 процентка, автомобиль бензинын – 2 процентка. Шул исәптән «ТАНЕКО»да нефть продуктлары чыгару 8 процентка арткан, «ТАИФ-НК»да – 6,9 процентка.



## МИЛЛИ ПРОБЛЕМА



Май уртасында Казанда коррупциягә каршы законнар таләпләрен үтәү мәсьәләләре турында сөйләштеләр. Семинарда республика министрлыклары һәм ведомстволарының җитәкчеләре катнашты. Чара видеоконференция режимында узды, аңа республиканың барлык муниципаль берәмлекләре кушылды.

Катнашучылар алдында чыгыш ясап, Татарстан башлыгы Рөстәм Миңнеханов коррупцияне Россиянең милли проблемасы дип атады, аңа каршы көрәшү дәүләтнең төп бурычларының берсе, диде. «Әлеге күренешкә каршы федерация күләмендә дә, республика буенча да зур эшләр башкарыла. Шуңа карамастан хәл ителәсе мәсьәләләр кала әле», – дип ассызыклады ул.

РФ Президентының Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре идарәсенең Оештыру-аналитик эшләр белән тәэмин итү департаменты башлыгы Евгений Кузьмин семинарда катнашучыларга илдә коррупциягә каршы алып барыла торган гамәлләр турында сөйләде, Татарстандагы вазгыятькә дә кагылды. Аның сүзләренчә, былтыр ТР дәүләт һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан 6 мең тикшерү үткәрелгән, коррупциягә каршы таләпләрне бозуга юл куйган 400 кеше ачыкланган. Стандартларны тупас рәвештә бозган өчен 300дән артык вазыйфаи зат дисциплинар җаваплылыкка тартылган. Закон бозучыларны, ышанычны югалту сәбәпле, эштән азат итү очраклары да бар.

Аның фикеренчә, Татарстанда коррупциягә каршы актив эшчәнлек алып барыла. Ул республиканың коррупциягә каршы идарәсенең һәм дәүләт органнарының эшен югары бәяләде. Әмма муниципаль дәрәҗәдә, аның фикеренчә, эшне камилләштерү таләп ителә. «Анда норматив-хокукый җайлау буенча хәл итәсе мәсьәләләр бар. Ләкин бу җәһәттән шактый ук үтемле чаралар кулланылуын беләм. Күпчелек җирле үзидарә органнарында тиешле контроль-методик чаралар уздырылган да инде. ТРның коррупциягә каршы структуралары тарафыннан җир урлашу, территорияләрне бүлүдәге гаделсезлекләр, республика милегенә зыян салу кебек гамәлләр ачыклана. Шуңа да республикада коррупциягә каршы гамәлләрне мин уңай дип бәялим», – дип ассызыклады федераллар вәкиле.

## ИҢ ЯХШЫ МУНИЦИПАЛЬ САЙТ

20–21 апрельдә Мәскәүдә, Идарә буенча дәүләт университетында «Хәзерге заман дәүләт үсешендә җирле үзидарәнең роле» темасына халыкара фәнни-гамәли конференция узды. Форум эшендә Россиянең 50дән артык төбәгеннән килгән вәкил катнашты. Алар арасында «Татарстанда җирле үзидарә» журналының баш мөхәррире Нияз Әхмәдуллин да бар иде.

Конференция башланыр алдыннан Россия муниципаль академиясе тарафыннан уздырыла торган «Иң яхшы муниципаль хезмәткәр» бәйгесендә җиңүчеләрне бүләкләделәр, шулай ук «Җирле үзидарәне үстерүгә керткән өлеше өчен» һәм «Фидакарь хезмәт өчен» медальләре тапшырылды. Шулай ук Россия муниципаль академиясе президенты, Мәскәү шәһәре Думасы рәисе Алексей Шапошников һәм Россия Журналистлар берлеге секретаре Наталья Чернышова беренче тапкыр уздырылган «Журналистлар җирле үзидарә яклы» бәйгесенең җиңүчеләрен котладылар. Әлеге бәйге Россия Муниципаль академиясе тарафыннан Россия Журналистлар берлеге белән бергә үткәрелде. «Иң яхшы муниципаль сайт» номинациясендә Татарстан муниципаль берәмлекләре Советы сайты җиңү яулады.




## БАКЧАЧЫЛАР ӨЧЕН ПРОГРАММА

Май бәйрәмнәре алдыннан ТР Хөкүмәт йортында бакчачылар проблемалары турында фикер алыштылар. ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов бүген ТРнда 376 мең бакча кишәрлеге булуы турында хәбәр итте. Аның фикеренчә, муниципаль берәмлекләр бакчачылар белән бөтенләй диярлек шөгыльләнми, гәрчә салымнар территорияләр бюджетында калса да, төзелеш программаларына бакчаларга илтә торган юллар кертелми. Күп кенә районнарда муниципаль хакимият тарафыннан бакчачылык җәмгыятьләре җир кишәрлекләрен бакчачылар исеменә хосусыйлаштырганда ярдәм күрсәтелми.

Республикада бакчаларга илтә торган автобус маршрутларын оештыру буенча дәгъвалар күп, шәһәр читендә урнашкан бакчачылык җәмгыятьләрендәге җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру проблемасы кискен тора, милекне саклау, хокукларны яклау, рейдерлык һөҗүмнәре, электр энергиясенә тарифлар билгеләүгә кагылышлы проблемалар да бар. Марат Әхмәтов чыгышы буенча, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, бакчачылык ширкәтләрен үстерү темасы, бигрәк тә эре шәһәрләр янындагы территорияләрдә, актуаль булды һәм шулай булып кала, дип ассызыклады. «Бакчачыларга кагылышлы барлык мәсьәләләр дә игътибар сорый, – дип билгеләде Рөстәм Миңнеханов. – Кайсыларыдыр район дәрәҗәсендә хәл ителә ала, кайсыларын югарырак дәрәҗәдә хәл итү таләп ителә». Республика башлыгы фикеренчә, транспорт белән тәэмин итүгә, бакчаларга илтә торган автобус маршрутларын оештыруга җитди игътибар бирергә кирәк. «Бакча кишәрлекләренә илтә торган юлларны тәртипкә китерергә, чүп-чар җыю эшен оештырырга кирәк. Ихтимал, безгә нинди дә булса программа кабул итәргә кирәктер. Без бит балалар җәй көне ял итә торган лагерьлар белән шөгыльләнәбез. Ә дачаларда, бакча участокларында дистәләрчә мең кеше ял итә, моны истә тотарга кирәк».



Нияз ӘХМӘДУЛЛИН тексты.
Андрей ТИТОВ фотолары.

# УН елдан соң

## (Татарстан муниципаллары беренче юбилейларын билгеләп үтте)

ИЛНЕҢ БАРЛЫК СУБЪЕКТЛАРЫНДАГЫ КЕБЕК ҮК, 21 АПРЕЛЬДӘ ТАТАРСТАНДА ДА РОССИЯДӘ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ КӨНЕ БИЛГЕЛӘП ҮТЕЛДЕ. БУ ЕЛ РЕСПУБЛИКА МУНИЦИПАЛЛАРЫ ӨЧЕН АЕРУЧА ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ – МОННАН УН ЕЛ ЭЛЕК, 2005 ЕЛДА, ТАТАРСТАНДА ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ СИСТЕМАСЫ ЭШЛИ БАШЛАДЫ, Ә БЫЕЛ МАРТТА ТР МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ СОВЕТЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ БАШЛАНУГА УН ЕЛ ТУЛДЫ. РЕСПУБЛИКА МУНИЦИПАЛЛАРЫ ҮЗЛӘРЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ ЮБИЛЕЙЛАРЫН БӘЙРӘМ ИТӘРГӘ КАЗАН РАТУШАСЫ БИНАСЫНА ҖЫЕЛДЫ. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ВЕТЕРАННАРЫН ҺӘМ РЕСПУБЛИКА МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ БАШЛЫКЛАРЫН ҺӨНӘРИ БӘЙРӘМНӘРЕ БЕЛӘН ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ ҺӘМ ТР МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ СОВЕТЫ РӘИСЕ МИНСӘГЫЙТЬ ШАКИРОВ ТӘБРИКЛӘДЕ. ТАНТАНАДА КАТНАШУЧЫЛАР ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ БУ КӨННЕ БИК КҮП УҢАЙ БӘЯЛӘР БИРЕЛДЕ.

***ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов: «Бүген ТР Муниципаль берәмлекләре Советы нәтиҗәле муниципалитетара хезмәттәшлекне, җирле үзидарәнең дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлеген, хокукый ярдәмне, җирле үзидарә органнары өчен кадрлар әзерләүдә катнашуны тәэмин итә. Безнең Муниципаль берәмлекләр Советы системасы, мөгаен, илдә иң яхшысыдыр, һәм бу тәҗрибәне башка территорияләргә дә таратырга кирәк».***



Залда җыелган муниципалларга һәм республика министрлыгы һәм ведомстволары җитәкчеләренә мөрәҗәгать итеп, Рөстәм Миңнеханов Минсәгыйть Шакиров җитәкчелегендәге Муниципаль берәмлекләр Советы эшчәнлегенең Татарстанда җирле үзидарә булдыру һәм үстерүдәге мөһим роленә тукталды: «Моннан ун ел элек кабул ителгән Совет төзү турында карар дөрес булган. Без үзебезнең муниципалитетларыбыз белән тыгыз элемтә урнаштырырга мөмкинлек бирә торган орган формалаштырдык. Муниципаль берәмлекләр Советы бүген нәтиҗәле муниципалитетара хезмәттәшлекне, җирле үзидарәнең дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлеген, хокукый ярдәмне, җирле үзидарә органнары өчен кадрлар әзерләүдә катнашуны тәэмин итә. Безнең Муниципаль берәмлекләр Советы системасы, мөгаен, илдә иң яхшысыдыр, һәм бу тәҗрибәне башка территорияләргә дә таратырга кирәк».

«Соңгы ун елда Татарстандагы муниципаль хакимият зур юл үтте һәм ныгыды, – дип ассызыклады ТР Президенты. – Бу вакыт эчендә муниципаль берәмлекләрнең



тотрыклы структуралары формалаштырылды, җирле үзидарә органнарының нәтиҗәле системасы булдырылды. Ә иң мөһиме – территорияләрнең күп кенә актуаль проблемалары хәл ителде, муниципаль бурычларны хәл итү системага салынды. Икътисадый кыенлыкларга карамастан, республикада социаль юнәлештәге программаларны гамәлгә кертү дәвам итә, без бер генә программаны да кыскартмадык».

Республика башлыгы җыелганнарның игътибарын быел гамәлгә кертелә башлаган яңа программага – авыл җирлекләре советлары биналарын капиталь ремонтлау программасына юнәлтте. Сүз уңаеннан, былтыр аны ТР Муниципаль берәмлекләре Советы тәкъдим иткән иде.

Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, җирле үзидарә органнары идарәче кадрлар резервы өчен яхшы база булып тора. Аларның эшендә алынган тәҗрибәләре республика һәм федераль дәрәҗәдә таләп ителерлек белгеч булу мөмкинлеге бирә. «Районнарда эшләп килгән кешеләр теләсә кайсы участокта эшләргә сәләтле. Бу гаять файдалы тәҗрибәгә без бик зур хөрмәт белән карыйбыз. Моңа ачык мисаллар – Илдар Халиков, Алексей Песошин һәм башка бик күпләр, мин үзем дә – муниципаль хакимияттән чыккан кадр. Тулаем алганда, муниципалитетларда зур тәҗрибә туплаучылар саны бик күпкә җыела».

Татарстан башлыгы аерым басым ясап әйткәнчә, соңгы елларда республикада муниципалитетларның матди-техник базасын яхшырту өчен күп нәрсә эшләнгән. Аерым алганда, соңгы биш елда муниципалитетларга республика бюджеты хисабына алынган 1200дән артык автомобиль тапшырылган. Транспорт проблемасын хәл итү авыл җирлекләре эшен, бигрәк тә еракта урнашканнарыныкын, шактый җиңеләйтә. Шунысын да әйтергә кирәк: муниципалларның һөнәри бәйрәмендә дә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, күркәм традицияне дәвам итеп, ТР Муниципаль

берәмлекләре Советы рәисе Минсәгыйть Шакировка илле «Форд Мондео» җиңел автомобиле сатып алуга сертификат тапшырды. Бу транспортны Татарстан муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары алачак.

Чыгышының азагында Рөстәм Миңнеханов дәүләт бүләкләре тапшырды. Бүләкләнүчеләр арасында – ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров. Ул Россия Президентының Мактау грамотасына лаек булды. Муниципалитет хезмәткәрләре дә ТР Президенты медальләре һәм Рәхмәт хатлары белән бүләкләнде.

Коллегаларын тәбрикләп, республика муниципаллары Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров Татарстанда муниципаль хакимият системасы һәм ТР Муниципаль берәмлекләре Советын булдыруда һәм ныгытуда республика җитәкчелегенең мөһим роленә басым ясады. Ул җирле үзидарә системасы үсеше процессының мөһим сәхифәләренә тукталды. «2006 елның 22 мартында, үзләренең беренче съездларында, республиканың ул чактагы барлык 999 муниципаль берәмлеге депутатлары безнең оешманы төзү турында карар кабул итте, – диде Минсәгыйть Шакиров. – Советның аякка басуы һәм үсеше ул елларда республика муниципаль системасы үсеше белән бергә барды».

Совет үсешенең башлангыч этабы эш формаларын һәм методларын даими эзләү, муниципалитетлар һәм хакимиятнең барлык тармаклары арасында үзара хезмәттәшлекне оештыру белән бәйле иде. Уртак тырышлык белән республика муниципалитетлары һәм дәүләт органнары җитәкчеләре эшнең төп юнәлешләрен билгеле алды.

Совет рәисе җирле үзидарә үсешендә республика муниципаль бергәлегенең еллык съездларының хәлиткеч роленә аеруча басым ясады. Төрле елларда съездларда күтәрелгән һәм аннары хәл ителгән мәсьәләләр арасында – гидротехника корылмаларын



һәм уләксә базларын ремонтлау һәм реконструкцияләү программалары, гражданнарның үзара салым программасын хуплау һәм авыл җирлекләренә грантлар булдыруны дәгъвалау, ТИСларны үстерү, муниципаль хезмәткәрләрне пенсия белән тәэмин итү мәсьәләсен хәл итү һ.б. Минсәгыйть Шакиров соңгы елларда ТР Президентының Татарстан муниципаль берәмлекләре Советы Президиумы һәм ревизия комиссиясе әгъзалары белән муниципалларның һөнәри бәйрәме – Җирле үзидарә көне алдыннан эшлекле очрашуларының гадәткә кергән дә аерым билгеләп үтте. Совет Президиумының республика хөкүмәте әгъзалары, муниципаль берәмлек башкарма ко-





митетлары җитәкчеләре белән үткәргән «түгәрәк өстәлләре» дә үзләрен эшнең нәтиҗәле форматы сыйфатында күрсәткән. Аларның эш нәтиҗәләре буенча муниципалитетларның социаль-икътисадый үсешенә кагылган күп кенә актуаль мәсьәләләр буенча дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының килешенгән карарлары кабул ителә.

Минсәгыйть Шакиров игътибарны муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсеше буенча гамәлгә ашырыла торган президент программаларының әһәмиятенә юнәлтте, чөнки гражданнарның тормыш сыйфаты күп очракта аларны гамәлгә кертү нәтиҗәләренә дә бәйле. Әлеге нәтиҗәләр җирле хакимият органнары абруе үсешенә дә турыдан-туры йогынты ясый, муниципалитетларга йөкләнгән вәкаләтләрне башкару мөмкинлекләрен билгели.

«Ремонтланган мәктәп, балалар бакчасы, төзелгән ФАП һәм полиция участок пункты, яңа юллар һәм су белән тәэмин итү системалары, башка объектлар – болар барысы да Татарстан үсеше дәлилләре. Без җөмһүриятебез Президенты Рөстәм Миңнехановка республика халкы проблемаларын хәл итүнең нәтиҗәле системасын булдырган өчен ихлас рәхмәтлебез, – дип басым ясады Совет рәисе. – Муниципалитетлар киләчәктә дә республика социаль-икътисадый үсеше бурычларын хәл итү, халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, Татарстанның гражданлык җәмгыяте һәм демократик институтларын даими камилләштерү буенча актив эшләрен дәвам итәчәк».

Юбилей чарасында катнашучыларга Татарстан Республикасының беренче Президенты, Татарстан Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиевтән котлау телеграммасы килеп иреште. Татарстан муниципалларын видеомөрәҗәгать форматында Гомумроссия муниципаль берәмлекләр конгрессы президенты, РФ Дәүләт Думасының Федератив корылыш һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча комитеты рәисе Виктор Кидяев сәламләде. Моннан тыш, Татарстандагы коллегаларын Красноярск крае, Белгород, Курган, Пенза, Төмән, Кемерово, Курск өлкәләре, Башкортостан, Алтай, Хакасия, Дагыстан муниципаль берәмлекләре Советлары тәбрикләде.

Коллегаларын шулай ук Лаеш муниципаль районы башлыгы, ТР Муниципаль берәмлекләре Советы Президиумы әгъзасы Михаил Афанасьев, ТР Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе Альберт Хәбибуллин да котлады.

**Гомумроссия муниципаль берәмлекләр конгрессы президенты, РФ Дәүләт Думасының Федератив корылыш һәм җирле үзидарә мәсьәләләре комитеты рәисе Виктор КИДЯЕВ:**

**«Сезгә урыннарда алып барган эшегез өчен ихластан рәхмәт әйтәсем килә. Аның нәтиҗәләре ачык күренеп тора. Хакимиятнең халыкка иң якын торган баскычы буларак, җирле үзидарә органнары, көн саен меңләгән катлаулы мәсьәлә һәм проблеманы хәл итеп, халыкка уңайлы яшәү шартлары тудыра. Сезгә үз эшегезне яратуыгызны һәм сабырлык телим. Сезнең хезмәтегез һәрвакыт югары бәяләнсен, аның җимешләре сезгә куаныч һәм канәгатьлек китерсен. Барлык башлангычларыгызга уңышлар, үзегезгә һәм якыннарыгызга сәламәтлек, бәхет һәм муллык телим!»**

**(Россиядә Җирле үзидарә көне уңаеннан котлаудан)**





Нияз ӘХМӘДУЛЛИН тексты.

# РЕЙТИНГ турында бәхәс

29 АПРЕЛЬДӘ КАЗАНДА ТР МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ ҺӘМ РЕВИЗИЯ КОМИССИЯСЕНЕҢ ЧИРАТТАГЫ КИҢӘЙТЕЛГӘН УТЫРЫШЫ БУЛДЫ. АНЫҢ ЭШЕНДӘ ТРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ВИЦЕ-ПРЕМЬЕРЫ АЛЕКСЕЙ ПЕСОШИН, ТР ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ВИЦЕ-СПИКЕРЫ РИММА РАТНИКОВА, ТР ПРЕЗИДЕНТ АППАРАТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ УРЫНБАСАРЫ, ТР ПРЕЗИДЕНТЫНЫҢ ТЕРРИТОРИЯЛӘР БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ИДАРӘСЕ БАШЛЫГЫ ИЛНУР ГАРИПОВ, РЕСПУБЛИКА МИНИСТРЛЫКЛАРЫ ҺӘМ ВЕДОМСТВОЛАРЫНЫҢ ҖАВАПЛЫ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ КАТНАШТЫ. ПРЕЗИДИУМ ЭШЕНДӘ ВИДЕОКОНФЕРЕНЦИЯ РЕЖИМЫНДА РЕСПУБЛИКАНЫҢ БАРЛЫК МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ БАШЛЫКЛАРЫ ДА КАТНАШТЫ. УТЫРЫШНЫ ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ СОВЕТЫ РӘИСЕ МИНСӘГЫЙТЬ ШАКИРОВ АЛЫП БАРДЫ.

Көн тәртибенә куелган төп мәсьәләләрнең берсе – республика муниципаль берәмлекләренең социаль-икътисадый үсеше рейтингын исәпләү методикасы. Бу тема берничә ел дәвамында муниципаллар даирәсендә дә, алар белән ТР Икътисад министрлыгы арасында да кискен бәхәсләр чыганагы булып тора. Әлеге рейтинг 2011 елның гыйнварыннан бирле төзелә. Муниципаль берәмлек позициясен билгеләү өчен 14 күрсәткеч (6 абсолют һәм 8 чагыштырма) кулланыла. Баштарак критерийлар саны берничә дистәдән артык иде (федераль индикаторларны да кертеп санаганда), әмма әкренләп аларның саны киметелә. Һәрхәлдә, гамәлдәге критерийларга карата җәмгыятьтә билгеле бер консенсус бар. Шул ук вакытта, республикада исәпләү чорын үзгәртү (рейтингны хәзерге кебек ай саен түгел, бәлки өч айга бер төзү), гамәлдәге кайбер критерийларны юкка чыгару, аларны башкаларына алыштыру буенча төрле тәкъдимнәр дә яңгырый. Президиум утырышында билгеләп үтелгәнчә, күп кенә дәлилләр белән килешми дә мөмкин түгел. Аерым алганда, җирле үзидарә органнары сәнәгать ягыннан үскән, бигрәк тә нефть эшкәртү сәнәгате булган муниципаль районнарны авыл хуҗалыгы районнары белән чагышты-






руны дөрес түгел, дип саный. Әлеге җәһәттән соңгы вакытта теге яки бу күрсәткечнең үзгәрү динамикасын бәяләүгә күчү зарурлыгы турында караш яклылар күбәя бара.

Президиум утырышында рейтинг төзү чорына, күрсәткечләр исемлегенә, бәяләү методикасына кагылган төрле фикерләр әйтелде. ТР Икътисад министрлыгы вәкиле айлык мониторингны саклау зарурлыгы турында позицияне якларга тырышты, чөнки ул күрсәткечләрне даими нигездә күзәтеп бару мөмкинлеге бирә. Тикшерү барышында чарада катнашучылар рейтинг төзүнең гамәлдәге методикасын саклау зарурлыгы белән килештеләр, шул ук вакытта, иң әүвәл, индикаторлар үзгәрү динамикасын бәяләүгә юнәлтелгән методика булдыру хакында тәкъдимнәр кертергә карар кылдылар. Бу очракта муниципаль районнар позициясе алар икътисадының база потенциалына азрак бәйле булачак, һәм рейтинг конкрет исәп чорында муниципаль хакимият органнары эшенең нәтиҗәлелеген яхшырак чагылдырачак.

Киңәшмәдә катнашучылар шулай ук президент программалары кысаларында соңгы елларда республиканың барлык муниципаль берәмлекләрендә төзелгән авыл клублары эшчәнлеген дә тикшерделәр. Республикада мәдәни инфраструктураны үстерү муниципалитетлар потенциалын җитди ныгытырга, авыл территорияләренең яшәү өчен уңайлылыгын арттырырга, мәдәният объектларының мөмкин кадәр күбрәк авыл халкына хезмәт күрсәтүен тәэмин итәргә тиеш. Шул ук вакытта төзеп куелган мәдәният йортлары еш кына ял көннәрендә дә ябык тора, аларның кайберләре кирәкле инвентарьга кытлык кичерә. Быел ТР Президенты кушуы буенча ТР Хисап палатасы әлеге тармактагы эшнең торышын өйрәнде. ТР Муниципаль берәмлекләре Советы Президиумы утырышы барышында бу мәгълүмат та җиткерелде.

Бүген Татарстанда 1981 мәдәният-ял учреждениесе эшли, алардан 1899ы – авыл җирлекләрендә. 2012–2015 елларда 181 клуб (күпфункцияле үзәк) төзелгән, быел тагын 45 мәдәни объект төзү планлаштырыла. Моннан тыш, республика, федераль, җирле бюджетлар, иганәчеләр акчасына 2012-–015 елларда өстәмә 29 объект торгызылган (27 авыл клубы һәм 2 балалар сәнгать мәктәбе). Республика бюджеты хисабына яңа клублар яктырту-тавыш кую җиһазлары комплектлары, ноутбуклар белән җиһазландырылган (бер клуб учреждениесенә уртача 100 мең сум акча бүленгән).

ТРның барлык муниципаль берәмлекләрендә яшәүчеләр арасында үткәрелгән социологик сораштырулар нәтиҗәләре гражданнарны борчыган төп проблемаларны ачыклаган. Тулаем алганда, республикада шактый уңай картина күзаллана. Сораштырылган респондентларның 91 процентын авыл клублары эше тулысынча, 8,2 процентын өлешчә канәгатьләндерә, 0,8 процентын гына канәгатьләндерми. Респондентларның 59,6 проценты клубта атнасына берничә тапкыр, 25,2 проценты – атнасына бер тапкыр, 15,2 проценты ике атнага бер тапкыр яки сирәгрәк була.

Халык исә мондый тәкъдимнәр керткән: клубларның эш графигын озайтуны, графикка өстәмә түгәрәкләр һәм спорт секцияләре үткәрүне дә кертүне сораган; концертлар, театр чараларының (шул исәптән чакырылган артистлар белән) аз булуыннан, яшьләр һәм өлкәннәргә тәгаенләнгән чараларның җитәрлек булмавыннан зарланган.

Авыл клублары хезмәткәрләре дә үз проблемаларын җиткергән. Алар фикеренчә, кадрлар җитми; түгәрәкләр өчен кабинетлар, грим салу, киенү бүлмәләре юк яки җитәрлек түгел; авыл клубларында спорт инвентаре һәм өстәл уеннары, бильярд һәм теннис өстәлләре, яктылык һәм тавыш кую җиһазлары, фильмнар һәм мультфильмнар күрсәтү өчен җиһазлар, музыка уен кораллары, сәхнә костюмнары юк яки җитәрлек түгел; гардероб, кием элгечләр, кондиционерлар, кайнар су, Интернет юк; КФҮ биналары киртәләнмәгән, территорияләре төзекләндерелмәгән.

Хисап палатасы белгечләре КФҮ биналарын төзегәндә һәм файдалангандагы сыйфатсыз төзү-монтаж эшләре нәтиҗәсе буларак төзелеш кимчелекләрен һәм техник җитешсезлекләрне дә ачыклаган.

Авыл клублары эшенә бәйле мәсьәләләр комплексын тикшерү нәтиҗәсендә Президиум муниципалитетлар өчен тәкъдимнәр кабул итте, алар мәдәният объектларын файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрүгә, кадрларга, биналарның техник җиһазландырылуына караган һ.б. проблемаларны хәл итүгә юнәлтелгән.

Совет Президиумында катнашучылар гражданлык халәте актларын теркәү буенча авыл җирлекләре башлыкларының вәкаләтләрен гамәлгә кертү, кунакханәләрне классификацияләү мәсьәләләрен, ТР Муниципаль берәмлекләре Советы каршында ТИСларның Координация советын төзү турында тәкъдимне дә карады, җирле үзидарә турындагы законнардагы соңгы үзгәрешләр хакында мәгълүмат җиткерелде. Көн тәртибендәге башка актуаль мәсьәләләр дә тикшерелде.

# КИЛӘЧӘККӘ ХАТ!






Фото www.tatarstan.ru сайтыннан

2016 елның 21 мае республиканың ислам җәмәгатьчелеге, бөтен Россия мөселманнары өчен үзенчәлекле һәм истәлекле көнгә әйләнде. Бу көнне Болгарда Татарстан җитәкчелеге һәм илебезнең һәм чит илләрнең ислам дине әһелләре булачак Болгар ислам академиясе нигезенә истәлекле капсула салдылар. Капсула эчендә киләчәк буыннар өчен дүрт телдә – татар, рус, гарәп һәм инглиз телләрендә язылган хат бар. Ә хатта рухиятне һәм ислам кыйммәтләрен: иминлек, динара татулык һәм бер-береңне хөрмәт итеп яшәүне сакларга кирәклеге язылган. Төргәкне, Коръән сүрәләре укый-укый махсус капсулага салып, бөкеләп куйдылар. ТР мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм мөселманнарның Үзәк Диния нәзарәте рәисе, Россиянең баш мөфтие Тәлгать Таҗетдин аны ташка уелган чокырга төшерделәр. Киләсе елга бу урында Болгар ислам академиясенең бинасы үсеп чыгарга тиеш. Аны булдыру турындагы указны ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов узган елның көзендә имзалаган иде.

Әлеге вакыйгага Болгарда ел саен Идел буе Болгар дәүләтендә исламны дәүләт дине буларак кабул иткән көнгә багышлап үткәрелә торган «Изге Болгар җыены» да аерым бер тантана төсе бирде. Бәйрәмгә республиканың район һәм шәһәрләреннән генә түгел, илнең төрле төбәкләреннән утыз меңнән артык мөэмин-мөселман халкы җыелган иде.

Бөек Болгарда җыелган халыкка мөрәҗәгать итеп, республика башлыгы Рөстәм Миңнеханов болай диде: «Бүгенге көндә иң мөһиме – рухиятне саклау, ә моның өчен дәрәҗәле уку йортлары кирәк». Ул безнең татар мөселман өммәтендә бөтен дөньяга танылган дин әһелләре булуын да искә төшереп үтте. Ләкин соңгы йөз елда бу өлкәдә күпне югалттык, һәм аны яңадан торгызырга кирәк. Ул дини укыту үзәгенең федераль үзәк һәм шәхсән Россия Президенты Владимир Путин ярдәме белән төзелүен ассызыклады.

Тантанада шулай ук ТР Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Премьер-министры Илдар Халиков, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык җитәкчесе Игорь Баринов, Казан һәм Татарстан митрополиты Феофан һәм башка дин әһелләре катнашты.



Нияз ӘХМӘДУЛЛИН тексты.

# ПРОФЕССИОНАЛЛАР өчен семинар

ТАТАРСТАНДА АПРЕЛЬ АЕНДА РЕСПУБЛИКА МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ БАШЛЫКЛАРЫ УРЫНБАСАРЛАРЫ ҺӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕ БАШЛЫКЛАРЫ ӨЧЕН ТРАДИЦИОН РӘВЕШТӘ ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН БЕЛЕМ БИРҮ СЕМИНАР-КИҢӘШМӘЛӘРЕ ЦИКЛЫ ОЕШТЫРЫЛДЫ. ӘЛЕГЕ ЧАРА ТР ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ ҺӘМ ТР МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ СОВЕТЫ ТАРАФЫННАН ҮТКӘРЕЛӘ. ТЕРРИТОРИАЛЬ ЯКТАН БЕР-БЕРСЕНӘ ЯКЫН ШӘҺӘР ҺӘМ АВЫЛ ТӨРКЕМНӘРЕ ВӘКИЛЛӘРЕ САРМАНДА, АЛАБУГАДА, ЧИСТАЙДА, ТӘТЕШТӘ ҺӘМ ЛЕНИНОГОРСКИДА ҖЫЕЛДЫЛАР. ЙОМГАКЛАУ СЕМИНАРЫ КАЗАНДА ҮТТЕ. БЕЛЕМ БИРҮ СЕМИНАРЛАРЫНЫҢ ТӨП БУРЫЧЫ – МУНИЦИПАЛЛАРНЫ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ӨЛКӘСЕНӘ КАРАГАН ЗАКОННАРГА КЕРТЕЛГӘН ҮЗГӘРЕШЛӘР БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ, ҮЗЛӘРЕН УҢАЙ ЯКТАН ТАНЫТКАН МУНИЦИПАЛЬ ТӘҖРИБӘЛӘРНЕ ТАРАТУ, РОССИЯДӘ МУНИЦИПАЛЬ БЕРГӘЛЕКНЕҢ ҮСЕШ ТӘҖРИБӘСЕН АНАЛИЗЛАУ, РЕСПУБЛИКА ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ КАГЫЛЫШЛЫ АКТУАЛЬ МӘСЬӘЛӘЛӘРНЕ ТИКШЕРҮ, ШУЛ ИСӘПТӘН ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ Һ.Б. БЕЛӘН ҮЗАРА ЭШ ИТҮГӘ КАРАГАН ӨЛЕШТӘ ДӘ.

Республика муниципаллары каршында федераль хакимиятнең территориаль органнары, республика министрлыкларының һәм ведомстволарының җаваплы хезмәткәрләре чыгыш ясадылар һәм сорауларга җавап бирделәр.

Семинарны ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров, ТР Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы урынбасары Андрей Нефедов алып барды. Минсәгыйть Шакиров республика җирле үзидарә органнары





вәкилләрен хокукый кырдагы мөһим үзгәрешләр белән таныштырды, Муниципаль берәмлекләр Советы эше, муниципаль берәмлекләрнең соңгы X съездында кабул ителгән карарларның үтәлеше, агымдагы елда республика муниципаль хакимият эшчәнлегенең төп юнәлешләре турында сөйләде.

Республика муниципаль бергәлеге башлыгы семинарда катнашучыларның игътибарын җирле үзидарә турындагы законнарга кертелгән төп үзгәрешләргә юнәлтте. Узган елда авыл җирлекләре дүрт өстәмә вәкаләткә ия булганнар иде: РФ законнарында билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында җирлек чикләрендә чиста су белән тәэмин итүне, калдык суларны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру; җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге буенча; җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятләрен саклау һәм үстерүгә, милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этносара) низагларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру, һәм шулай ук җирлек халкының күмәк ялын оештыру һәм халыкның күмәк ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру өчен шартлар тудыру буенча, шул исәптән гражданнарның гомумкуллану су объектларына һәм яр буйларына керә алуын тәэмин итүне дә кертеп. Шулай итеп, бүген авыл җирлекләренә гомумән алганда унтугыз вәкаләтне тормышка ашыру йөкләнгән.



Тагын бер яңалык – вәкаләтләрне үтәү өчен бюджет акчалары бирелмәгәндә, муниципалитетларның җаваплы затларының үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәмәгәннәре өчен җавап бирү проблемасын хәл итү. Билгеле булганча, әлеге проблема соңгы вакытка кадәр бик кискен торды һәм ул илнең барлык төбәкләренә кагыла иде. Муниципалитетлар мәнфәгатьләрен яклау күзлегеннән караганда, РФ Административ хокук бозулар кодексына вәкаләтләрне үтәмәгән өчен муниципалитетларның җаваплылыгы соравына кертелгән өстәмәләр мөһим алга китеш булды. 2015 елның 5 октябрендәге 288-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, вазыйфаи затның, муниципаль учреждение җитәкчесенең, җирле үзидарә органының тиешле вәкаләтен үтәү өчен, муниципаль учреждениенең уставындагы бурычларны башкару өчен, бюджет акчалары сорап үз вакытында (ягъни тиешле җирле бюджет проектын төзү тәртибенә һәм срокларына ярашлы рәвештә) мөрәҗәгать итүе һәм әлеге максатларга акчалар бүлеп бирелмәве ачыкланган очракларда, җирле үзидарә органының вазыйфаи затына яисә муниципаль учреждение җитәкчесенә карата башланып киткән административ хокук бозу турындагы эш туктатылырга тиеш. Минсәгыйть Шакиров семинарда катнашучыларга әлеге законны гамәлдә активрак кулланырга тәкъдим итте.

Тагын бер мөһим яңалык вәкаләтләрен даими нигездә алып бармый торган муниципаль дәрәҗәдәге депутатларның үз керемнәре турында хисап бирү мәҗбүриятенә карый. Әлеге норма быел гына кертелде. Аңа ярашлы рәвештә, үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматны барлык дәрәҗәләрдәге депутатлар да тапшырырга тиеш. Элегрәк бу норма җирлек дәрәҗәсендәге депутатларга кагылмый иде. Минсәгыйть Шакиров шулай ук, норманың бәхәсләр тудыру мөмкинлеген искә алып, ТР Муниципаль берәмлекләре Советының Гомумрос-

сия муниципаль берәмлекләр конгрессына законга кертелгән әлеге яңалыкны ГМБК президиумы утырышында, РФ Дәүләт Думасының Федератив корылыш һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча комитетында тикшерү үтенеченә башлангычы белән мөрәҗәгать итүен ассызыклады.

Совет рәисе шулай ук юридик идарә алып барган киң колачлы эшләр турында сөйләде. Идарә белгечләре авыл җирлекләре һәм районның юридик хезмәтләре башлыкларына консультацияләр үткәрәләр. Кирәк булганда судларга дәгъва гаризалары әзерләнә, суд карарлары, контроль-күзәтчелек органнарының карарлары һәм беркетмәләре белән риза булмаганда, шикаятьләр языла. Авыл муниципалитетларының юридик белеменең күтәрелүен искә алып, Минсәгыйть Шакиров шул ук вакытта республика муниципаль берәмлекләренең эшчәнлеген хокукый яктан тәэмин итүдә җитди проблемалар булуына игътибарны юнәлтте.

Мисалга, прокуратура тарафыннан ризасызлык белдерелгән муниципаль хокукый актларның бик күпкә кимүен атарга була: 2015 елның беренче яртыеллыгында – 1584, шул ук елның икенче яртыеллыгында инде – 469. «Ризасызлык белдерелгән норматив хокукый актларның гомуми саныннан 125е – район дәрәҗәсендә, 344 акт авыл җирлекләре дәрәҗәсендә кабул ителгән иде». Ризасызлык белдерелгән муниципаль норматив хокукый актларның күпчелеге муниципаль хезмәт турындагы карарлар сферасына кагыла, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү исемлеген раслау турындагы нигезләмәне кертеп (ТР буенча барлыгы 173 актка карата ризасызлык белдерелгән). Алга таба торак-коммуналь хуҗалык һәм төзелеш сораулары буенча кабул ителгән актлар (103 актка ризасызлык белдерелгән), адресларны беркетү, үзгәртү, юкка чыгару кагыйдәләрен раслау турында карарлар (90 акт), авыл җирлеге территориясендәге җирләрдән файдалану һәм саклауга муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәләр (47 акт) бара.

Прокуратура органнары протесты нигезе сыйфатында түбәндәгеләрне атарга мөмкин: норматив хокукый актларның Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры килмәве яисә аларның әлеге законнарга карата каршылыклы булуы, һәм шулай ук муниципаль хокукый актларның закон тарафыннан бирелгән вәкаләтләрне арттырып кабул ителүе.

«Ризасызлык белдерелгән хокукый актларның күп санда булуының төп сәбәбе федераль законнардагы үзгәрешләргә карата үткәрелә торган мониторинг дәрәҗәсенең йомшаклыгы. Еш кына яңа хокукый актлар искеләреннән күчерелеп языла һәм, димәк ки, законнардагы яңалыклар исәпкә алынмый. Муниципалитетларның күп кенә юристлары, муниципаль хезмәткәрләр муниципаль актларны әзерләгәндә нормалар эшләү техникасы принципларын сакламый», – дип билгеләп үтте Минсәгыйть Шакиров. Спикер муниципаль берәмлекләрне муниципаль актларны әзерләгәндә ТР Юстиция министрлыгы, ТР Муниципаль берәмлекләре Советы киңәштәкъдимнәренә колак салырга, һәм шулай ук үз эшләрендә заманча мәгълүмати-хокукый системаларны кулланырга чакырды.

Минсәгыйть Шакиров шулай ук авыл җирлекләре башлыклары тарафыннан нотариаль гамәлләрне башкару, территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерү сорауларына кагылды, муниципалларның игътибарын үзара салым программасын тормышка ашыру барышында очрый торган проблемаларга юнәлтте. Аерым алганда, референдумны билгеләү һәм муниципаль берәмлекләр территорияләрендә үзара салымны кертү турындагы карарларда, һәм шулай ук уртак финансларны алуга гаризаларда җирле әһәмияттәге сорауларны хәл итү буенча конкрет чаралар һәм әлеге чараларны хәл итүгә бирелергә тиешле акчалар күләме һәрвакытта да язылмый; үзара салым сыйфатында уртак финанслауга кертелми торган иркле кертемнәр дә исәпкә алына. Кайбер муниципаль берәмлекләрдә җыела торган үзара салым акчаларын аерым еллар буенча исәпкә алу оештырылмаган. Шуңа күрә агымдагы ел референдумы буенча җыелган акчаларны узган еллар референдумнары буенча тупланган акчаларга күчерәләр – бу шулай ук үзара салымны көйләргә тиешле норматив актларны бозу булып тора. Башка хилафлыклар да очрый.

ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе үзара салым буенча чараларның законнарга туры килүен тикшерү дәвам иттереләчәген ассызыклады. «Үзара салым салу юлы белән конкрет хуҗалык проблемаларын хәл итә барып, без берүк вакытта халыкны территорияләр белән идарә итү процессына җәлеп итәбез, аларны муниципаль акчаларга эшләнгән барлык нәрсәләргә кайгыртучан мөнәсәбәт күрсәтергә өйрәтәбез. Әмма җитәкчелеккә ышаныч күрсәтүне ныгыту өчен, халыкта урыннардагы мәсьәләләрне хәл итү теләгән формалаштыру өчен, референдумнар-



ны үткәргәндә һәм гражданнардан җыелган акчаларны тотканда законнарны һәм барлык чараларның да ачыклыгын сакларга кирәк», – диде спикер.

Муниципаллар каршында чыгыш ясаган министрлык һәм ведомство вәкилләре дәүләт органнары һәм муниципаль хакимиятләр арасында үзара эш алып бару турында сөйләделәр, семинарда катнашучыларга республикада гамәлгә ашырыла торган программалар һәм проектларга кагылышлы актуаль мәгълүматны җиткерделәр. ТР Финанслар министрлыгы вәкиле республиканың финанс-бюджет сәясәте турында сөйләде. Аерым алганда, шуны билгеләп үтте: муниципаль бюджетларның үз керемнәре белән тәэмин ителеше уртача алганда 58%ны тәшкил итә, җитмәгән акчалар бюджетара трансфертлар нәтиҗәсендә ябыла. ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы вәкиле АСКна ярдәм программаларының гамәлгә ашырылуы барышын яктыртты, ТР Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы вәкиле әйләнә-тирә мохитне саклау эшчәнлеге турында мәгълүмат бирде. ТР Президентының Коррупциягә каршы эшчәнлек мәсьәләләре идарәсе вәкиле шуны хәбәр итте: авыл җирлеге эшчәнлегендә коррупцион элементлар күбрәк җирдән файдалану, җир кишәрлекләре бүлеп бирү, һәм шулай ук гражданнарның үзара салым акчаларын тоту кебек өлкәләргә туры килә. ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы вәкиле авыл җирлекләрендә гидротехник корылмаларны исәпкә кую буенча эшнең мөһимлегенә басым ясады, һәм шулай ук хуҗасыз калган милекне теркәү буенча вәкаләтләрне активрак кулланырга кирәклегенә игътибарны җәлеп итте. Бүген республикада авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге 38,8 мең гектарга якын кулланылмый торган җир исәпкә алынган. Әлеге проблема муниципалитетлар ягыннан да, хөкүмәт ягыннан да үз чишелешен көтә. Семинарда милләтара һәм конфессияара татулыкны тәэмин итү, экстремизмны профилактикалау буенча чараларны көчәйтүнең актуаль сораулары турында сөйләштеләр. Әлеге әһәмиятле участок өчен җаваплылык бүгенге көндә шул исәптән муниципаль берәмлекләр башлыкларына да төшә.







Семинарда катнашучыларның чыгыш ясаучыларга сорау бирү мөмкинлеге булды. Муниципаллар тарафыннан күтәрелгән проблемалар арасында нотариаль эшчәнлек, дәүләт транспорт чараларын теркәү, үзара салым буенча референдумнар үткәрү һ.б. сорауларны билгеләп үтәргә була. Муниципалитетлар башлыклары кайбер тәкъдимнәрен дә яңгыраттылар. Алар арасында түбәндәгеләр бар: гамәлдәге программаларны финанслауны арттыру, яңа республика программаларын кабул итү (инфраструктур объектларны капиталь төзекләндерү, чистарту корылмаларын реконструкцияләү һ.б.лар), муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакын күтәрү һ.б.

Гомумән алганда, шунысын билгеләп үтәргә кирәк: үткәрелгән семинарлар яхшы белем бирү, шул ук вакытта дискуссия мәйданчыгы булып тора. Анда катнашу җирле үзидарә үсешенең иң мөһим юнәлешләре буенча позицияләрне төгәлләштерергә, проблемаларны ачыкларга һәм Татарстанның дәүләт хакимияте органнары белән бергә уртак чишелеш юлларын билгеләргә мөмкинлек бирә.



**Знче урын – Татарстан башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге буенча Топ-20лектә 2015 елда әнә шул урынны алды.** Беренче урында – Воронеж өлкәсе, икенчедә – Чечен Республикасы. 2014 елда Татарстан шундый рейтингта беренче урынны алган иде. «Татарстан федерация субъектының берләштерелгән бюджетына салым һәм салым булмаган керемнәр күләме һәм халыкның реаль акча керемнәре буенча лидер төбәкләр арасына керә, төп капиталга шәхси инвестицияләр кертүнең югары дәрәҗәсе, эшсезлекнең түбәнлеге, башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең югары бәяләнүе белән сыйфатлана», – диелә РФ Хөкүмәте хәбәрендә.



**37,8 млрд сум Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына 2016 елның 1 кварталында (2015 елның 1 кварталында – 59,4 млрд сум) керде.** Федераль бюджетка 1 квартал эчендә 45,7 млрд сум акча күчерелде (узган елның шул чорында – 40,6 млрд сум).




**14 млрд сум – беренче кварталда республикада түләнгән физик затларның кеременә салым күләме шуның кадәр.** Җыелган акчаларның күләме, 2015 елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 1,7 млрд сумга, яки 13,6%ка артты.



**91,3 млрд сум – 2016 елның 1 гыйнварына карата Татарстанның дәүләт бурычы күләме әнә шуның кадәр.** Бурычның күләме 2014 ел дәрәҗәсенә карата 2 процентка азайды, аңа хезмәт күрсәтү чыгымнары да кимеде. Шулай да республиканың бурычы Россия төбәкләре арасында иң югарылардан кала бирә.



**1,2 меңнән артык – Россия һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмасының (ИХО) «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit 2016»** дип аталган VIII Халыкара икътисадый форумы дөньяның 40 иленнән һәм 20 төбәктән килгән әнә шулкадәр кешене кабул итте. Алар арасында – күренекле дипломатлар, ИХО илләре министрлыклары һәм ведомстволары вәкилләре, банк һәм эре бизнес җитәкчеләре.

**2 млрд сумны ТР Хисап палатасы 2015 елда барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларга кайтарды.** Хисап палатасы тикшерүләре нигезендә прокуратура органнары тарафыннан законны бозуны юкка чыгару турында 65 кисәтү кертелде. 214 вазыйфаи зат административ, дисциплинар җаваплылык формасында җәза алды, дүрт кеше биләгән вазыйфаларыннан азат ителде, ике җинаять эше ачылды.



**39 млрд сум күләмендәге федераль акчаларны Татарстан 2016 елда җәлеп итәчәк.** Башта республика 51,5 млрд сум турында сүз алып барган иде. Нәтиҗәдә кабул ителгән сумма, 2015 ел (61,4 млрд сум) белән чагыштырганда, 20 млрд сумга азрак булып чыкты. Бу федераль бюджетны кисүгә бәйле.



**299,4 млн сум күләмендәге федераль акчалар Татарстанга халык мәшгульлеге өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру максатларына бирелә.** Барлыгы (берничә төбәккә) әлеге максатларга дип, 1 млрд сумнан артык акча бүленә.



**2,9 млн гектар – республикада чәчүлек җирләре барлыгы әнә шулкадәр мәйданны тәшкил итә.** Шуларның – 1,8 млн гектары язгы чәчү өчен билгеләнгән. Бөртекле һәм кузаклы культураларга – 1,6 млн гектар, техник культураларга – 315,8 мең гектар, шул исәптән шикәр чөгендеренә – 63,4 мең гектар туры килә. Азык культуралары 1 млн гектарга якын мәйданны били.



**3,9 млрд сум – 2016–2020 елларга сәнәгатьнең эшкәртү тармакларын үстерү буенча республика дәүләт программасын финанслау әнә шул сумманы тәшкил итә.** Республика акчалары 500 млн сум булачак, федераль акчалар – 1,1 млрд сум, шулай ук бюджеттан тыш чыганаклардан 2,3 млрд сум җәлеп итү планлаштырыла. Көтелгән нәтиҗәләр арасында түбәндәгеләр бар: 2015 ел дәрәҗәсенә карата сәнәгать җитештерүе күләменең 20,8%ка артуы, эшкәртү тармакларында җитештерү күләменең 29,6%ка үсүе.





**Надил ГЫЙМАДЕТДИНОВ тексты.**
**Фотолар ТР Дәүләт Советының матбугат хезмәтеннән алынды.**

# *ТИҮ ярдәм итсен*

ҺӘРКЕМ ӨЧЕН ШӘҺӘР ЯКИ БИСТӘ ҮЗЕНЕҢ ӨЕННӘН ЯКИ ПОДЪЕЗД, ИШЕГАЛДЫННАН БАШЛАНА. КЕШЕ БИРЕДӘ ҮЗЕН ХУҖА ИТЕП ТОЯРГА, ҮЗЕНЕҢ ИРТӘГЕСЕ ТУРЫНДА ГЫНА ТҮГЕЛ, Ә УРЫННАРДАГЫ ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШТА АКТИВ КАТНАШЫП, БАЛАЛАРЫНЫҢ, ОНЫКЛАРЫНЫҢ КИЛӘЧӘГЕ ТУРЫНДА ДА КАЙГЫРТЫРГА ТИЕШ.

Гражданнарны үзләре яшәгән территория үсешенә караган көндәлек бурычларны хәл итү өчен берләштерү ягыннан территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең (алга таба – ТИҮ) мөмкинлекләре зур. Соңгы өч ел эчендә ТИҮ Советлары саны 3,5 тапкырга артты. Хәзерге вакытта Татарстанда 347 ТИҮ эшчәнлек алып бара, алар җирле хакимият органнары өчен менә дигән ярдәмче дә, теләктәш тә булып китте.

Республикада ТИҮ хәрәкәтенең иң яхшы тәҗрибәләре һәм аның формалашу проблемалары турында 20 майда Әлмәттә Татарстанда ТИҮләр эшчәнлегенең актуаль мәсьәләләре буенча күчмә конференция барышында сөйләштеләр. ТР Муниципаль берәмлекләре Советы һәм «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге оештырган форумның делегатлары 24 муниципаль район һәм 2 шәһәр округыннан килгән территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләре булды. Конференция эшендә ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров, Россия Дәүләт Думасы депутаты Ринат Хәйров, ТР Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе Альберт Хәбибуллин һәм аның җитәкчелегендәге комитет әгъзалары, ТР Президент Аппаратының, республика министрлыклары һәм ведомстволарының җаваплы хезмәткәрләре катнашты.

Конференцияне үткәрү урыны итеп Әлмәтнең сайлануы очраклы түгел иде: иң беренче иҗтимагый үзидарәләр биредә 16 ел элек үк барлыкка килгән, ә аларга узган гасырның 80нче елларында нефтьчеләр шәһәрендә оештырылган социаль-педагогик комплекслар нигез булган. Бүген шәһәрдә һәм районда җирле үзидарәнең 37 территориаль иҗтимагый советы гамәлдә (алга таба – ҖҮТИС). Аларның кайберләренең эшчәнлеге белән чарада



«Татарстанда ТИҮләргә ышаныч арта бара», – дип саный Минсәгыйть Шакиров.



катнашучылар форумның гамәли өлешендә таныша алды.

Әлмәттә һәрбер ҖҮТИС территориясендә мең ярымнан алып унбер меңгә кадәр кеше яши. Баш предприятиеләрнең финанс ярдәме аркасында җирле иҗтимагый советлар шәһәр эчендәге бистәләрне карап тора һәм аларны төзекләндерү буенча планлы эш алып бара ала. Тулаем алганда, 16 ел эчендә шушы максатларда биредә миллиард сумнан артыграк шефлык ярдәме үзләштерелгән. Әлеге сумманың саллы өлешен ТИҮләр «Татнефть» компанияләр төркеме предприятиеләреннән алган.

Әлмәтнең барлык ТИҮләрендә иҗтимагый кабул итү бүлмәләре, полиция пунктлары эшли, хокук бозуларны кисәтү буенча советлар булдырылган, полициягә булышлык итү отрядлары тупланган. Балаларның, үсмерләрнең һәм яшьләрнең буш һәм ял вакытын оештыру мәсьәләләрен ТИҮләр каршындагы 32 клуб хәл итеп бара. Бөек Ватан сугышы ветераннары, аларның толлары, тыл хезмәтчәннәре, житештерү ветераннары – җәмгысе 1600дән артык кеше җирле активистларның кайгыртуын һәм игътибарын тоеп яши.

– Территориаль иҗтимагый үзидарә тулаем җирле үзидарә үсеше өчен мөһим һәм перспективалы институт булып кала, – дип белдерде, конференциянең пленар утырышында чыгыш ясап, ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров. – Бүген Әлмәт мисалында без үзебез күргәнчә, ТИҮләр җирле хакимият аларга йөз белән борылган, уртак тел табылган урыннарда нәтиҗәле эшли.

Шундый ук картина шәһәр җитәкчелегенең дөрес һәм эзлекле эш алып баруы нәтиҗәсендә Яр Чаллыда күзәтелә. Биредә әлеге вакытта 65 ТИҮ бар, озакламый алар янына тагын 15 өстәләчәк, ТИҮләргә ярдәм итү өчен, муниципаль программа кабул ителгән, шәһәр күләмендә ике бәйге үткәрелә. Шул ук вакытта аерым бер муниципалитетлар үзләренең ТИҮләренә хәтта бина бүлеп бирерлек хәлдә түгел (бүген республикадагы 91 ТИҮнең «торыр урыны» юк – авт.), ә инде мәгълүмат тактасы әзерләү турында сүз дә юк.

Соңгы елларда республикада ТР Муниципаль берәмлекләре Советының турыдан-туры катнашлыгы белән, ТИҮләргә дәүләт ярдәме күрсәтү системасын оештыру буенча зур эшләр башкарылды. 2014 елдан башлап, Татарстан муниципалитетлары ТИҮ җитәкчеләренә айлык хезмәт хакын компенсацияләү өчен субсидияләр ала. Агымдагы елда бу максатларга бюджеттан 69 миллион сум акча бүленгән. ТИҮләрнең эшчәнлеген активлаштыруга 2015 елда «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика бәйгесе оештырылу зур этәргеч бирде. Аның кысаларында 120 ТИҮ 50 миллион сумлык грант отты. Бер үк вакытта безнең күп кенә ТИҮләр бизнес-җәмәгатьчелек ресурсларын нәтиҗәле файдалана. Бу күрсәткеч буенча Әлмәт, Яр Чаллы, Түбән Кама, Лениногорск шәһәрләрендәге ТИҮләр алда бара.

ТИҮ хәрәкәтенең төп казанышы матди күрсәткечләрдә генә түгел, ә формаль статистика белән санап булмый торган социаль нәтиҗәләрдә күренә. Татарстанда ТИҮләргә ышаныч арта, гәрчә, Минсәгыйть Шакиров фикеренчә, безнең кайбер муниципалитетларда алар исем өчен генә оештырылган булса да. Әйтик, кайбер урыннарда ТИҮләр 40 кешелек кенә территорияләрне үз эченә ала.

– Бистәдә ТИҮ оештырасың икән, аның эшенә үзе яшәгән территорияне яхшыртуга шәхсән өлешен кертергә әзер һәм үзе артыннан ияртердәй абруйлы кешеләрне җәлеп итәргә кирәк, – дип ассызыклады ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе. – Шул ук вакытта әлеге иҗтимагый институтларны авыл җирлекләрендә оештыру белән артык мавыкмаска кирәк, анда җирле хакимият болай да халыкка якын.

Минсәгыйть Шакиров фикеренчә, Татарстан ТИҮләре гамәли эшчәнлек алып барганда, әлегә үзләренең куәтен тулы көченә файдаланырга әзер түгел. Аерым алганда, алар еш кына закон чыгару башлангычларына хокуклары булуы турында онытып җибәрәләр – «РФндә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131нче Федераль закон мондый хокук бирә. ТИҮ хәрәкәтен республикада бөтенләй башка – үсешнең сыйфатлырак дәрәҗәсенә күтәрү максатыннан күптән түгел ТР Муниципаль берәмлекләре Советы каршында Территориаль иҗтимагый үзидарәнең координацион советы булдырылды.



Икътисад фәннәре кандидаты, КФУ ДМИЮМ директоры урынбасары Наталья АКСЕНОВА тексты.

# АГЛОМЕРАЦИЯЛӘРДӘ җирле үзидарә: нәтиҗәлелек проблемалары

БҮГЕН АГЛОМЕРАЦИОН ҮСЕШ ИЛНЕҢ БАР ТӨБӘКЛӘРЕНЕҢ АЛГАРЫШЫНДА ТӨП ЮНӘЛЕШКӘ ӘЙЛӘНЕП БАРА. АНЫҢ ТӨП ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ – ИКЪТИСАДЫЙ КИҢЛЕКНЕ ЗУР ШӘҺӘРЛӘР ЯНЫНДА ТУПЛАУ. ӘЛЕГЕ ТЕНДЕНЦИЯЛӘР ДӘҮЛӘТНЕҢ СТРАТЕГИК ДОКУМЕНТЛАРЫНДА ДА ЧАГЫЛЫШ ТАБА.

Әйтик, Россиянең 2020 елга кадәрге үсеше концепциясендә, «Россия Федерациясенең озак вакытка исәпләнгән социаль-икътисадый үсешенең инновацион һәм социаль юнәлешләре югары сыйфатлы яшәү мохите һәм кеше потенциалы, динамик инновацион һәм мәгариф инфраструктурасы булган эре шәһәр агломерацияләренең фәнни-техник һәм мәгариф потенциалын үстерүдә күренә» диелгән. Бүген Россиядә (һәм бу төрле авторларның басылып чыккан хезмәтләрендә чагылдырылган) берничә дистә агломерация булуы күрсәтелгән (кайбер хезмәтләрдә, аларның саны 50дән артык, дип искәртелгән).

Агломерацияләр формалашу, теоретик яктан, муниципаль берәмлекләрнең үзара

***Агломерация кысаларында муниципалитетара хезмәттәшлек принципларында җитештерүче көчләрне үстерү һәм урнаштыру, транспорт, мәгълүмати, иҗтимагый инфраструктураны үстерү һәм башка мөһим бурычлар хәл ителергә тиеш. Агломерацияләр үсеше нигезенә, муниципаль берәмлекләрнең мөстәкыйльлеген саклап калып, килештерелгән муниципалитетара хезмәттәшлек принцибы салыну зарур.***

мәнфәгатьләрен исәпкә алып, төбәкнең бердәм социомәдәни һәм икътисадый киңлек буларак тотрыклы балансланган социаль-икътисадый үсешен тәэмин итәргә, шулай ук уңайлы яшәү мохите формалаштыру, бизнес алып бару, халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү өчен шартлар тудырырга тиеш. Агломерация кысаларында муниципалитетара хезмәттәшлек принципларында җитештерүче көчләрне үстерү һәм урнаштыру, транспорт, мәгълүмати, иҗтимагый инфраструктураны үстерү һәм башка мөһим бурычлар хәл ителергә тиеш. Агломерацияләр үсеше нигезенә, муниципаль берәмлекләрнең мөстәкыйльлеген саклап калып, килештерелгән муниципалитетара хезмәттәшлек принцибы салыну зарур.

Әмма халыкның урбанлашуының тискәре процесслары хәтта агломерацияләр үсешенә бәйсез рәвештә дә ачык күренә. Авыл җирлегендәге тормышның яшьләр өчен кызыксызлыгы, потенциалны киметеп, авылның үзенә дә, икътисадый нигезләрен какшатып, шәһәрләргә дә тискәре йогынты ясый.

Шәһәрләрдә һөнәри белем алган яшьләр, кагыйдә буларак, үзләре элек яшәгән урыннарга кайтмый. Бу вазгыятьтә шәһәрләр яңа эш урыннары булдыру буенча бурычларны хәл итәргә тиеш, ә моны эшләү кыен, чөнки алынган белемнең профиле шәһәр үсеше юнәлешләренә туры килми. Торак төзү һәм социаль структураны үстерү, шәһәр мохитен яхшырту, халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм аларны чын шәһәр кешеләренә әйләндерү зарур. Шуның өстенә, шәһәрдә халык саны арту белән бергә авылның потенциалы кими бара, бу да республика өчен эзсез үтми.

Гомумән, урбанлашу – шәһәрләрнең роле көчәйтелү процессы ул. Әгәр 2000 елда дөньяда шәһәр халкы 47,5 процент (2 миллиард 926 миллион кеше) тәшкил итсә, бүгенге трендларга ярашлы рәвештә, 2025 елда шәһәр халкының саны 61,1 процентка (5 миллиард 56 миллион кешегә) җитәчәк дип фаразлана.

Республика югары дәрәҗәдә шәһәрләшкән төбәкләргә керә: шәһәр халкының өлеше 76 процент тәшкил итә. Республикада 21 шәһәр һәм шәһәр тибындагы 18 бистә бар. Зур шәһәрләр – Казан, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Яшел Үзән.

Мөгаен, авылдагы югары нәтиҗәле җитештерүләр, күчереп утыртуның нәтиҗәле системалары, бизнес алып баруның кызыктыргыч шартлары һәм, иң мөһиме, кеше капиталының югары сыйфаты гына демографик ресурслар кимегән чорда төбәкләрнең һәм тулаем илнең динамик үсеше бурычларын уңышлы хәл итәргә сәләтледер. Әлеге бурычларны уңышлы хәл итү өчен, дәүләт, муниципаль һәм корпоратив идарә системасында яңа белемнәр һәм осталык кирәк.

Тормышның барлык өлкәләренә дә диярлек кагылган мондый мөһим үзгәрешләр юлындагы төп системалы каршылыклар нидән гыйбарәт соң?

Әлеге проблемаларны формалаштыру ягыннан җавапны 2030 елга кадәр Татарстанның социаль-икътисадый үсеше стратегиясеннән (алга таба – Стратегия) табарга була. Стратегиядә язылганча, агломерация – шәһәр һәм авыл җирлекләренең күптөрле (җитештерү, коммуналь-хуҗалык, хезмәт, мәдәни-көнкүреш, рекреацион) интенсив бәйләнешләр белән катлаулы динамик локаль системага берләштерелгән һәм әлеге ареалны һәм андагы ресурсларны бергәләп куллана торган компактлы территориаль төркемнәре ул. Биредә шулай ук инфраструктураның алгарышлы үсеше, хезмәт базарының киңәюе һәм үсешкә юл тотуы, инвестицияләр җәлеп итүне стимуллаштыру, фәнни, социаль, мәгариф һәм башка тармакларны үстерүнең дә агломерациянең уңай нәтиҗәләре булуы күрсәтелгән. Икенче яктан караганда, агломерацион процесслар муниципаль берәмлекләр социаль-икътисадый үсешенең төбәк эчендәге ярашмаучанлыгын көчәйтә, халыкның ерак урнашкан муниципалитетлардан «юылуына» булыша, төбәкнең аерым территорияләренең традицион тарихи, социомәдәни үзенчәлекләренең зәгыйфьләнүенә китерә.

Шул рәвешле, бу мәкалә контекстындагы төп проблемаларга Стратегиядә түбәндәгеләр кертелгән:

агломерацион идарәнең формаль системасы булмау;

таләп ителгән әзерлек дәрә-

***Әгәр 2000 елда дөньяда шәһәр халкы 47,5 процент (2 миллиард 926 миллион кеше) тәшкил итсә, бүгенге трендларга ярашлы рәвештә, 2025 елда шәһәр халкының саны 61,1 процентка (5 миллиард 56 миллион кешегә) җитәчәк дип фаразлана. Республика югары дәрәҗәдә шәһәрләшкән төбәкләргә керә: шәһәр халкының өлеше 76 процент тәшкил итә. Республикада 21 шәһәр һәм шәһәр тибындагы 18 бистә бар. Зур шәһәрләр – Казан, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Яшел Үзән.***

җәсенә ия идарәчеләр санының җитәрлек булмавы, шулай ук бу тармактагы белем бирү программаларының юклыгы;

авыл халкының түбән тормыш дәрәҗәсе (шәһәр халкы белән чагыштырганда);

муниципаль берәмлекләрнең уртак үсеш белән кызыксынмавы;

республика территориясендә җитештерү көчләрен үстерү һәм урнаштыру программаларының юклыгы һ.б.

Санап кителгән проблемалардан күренгәнчә (бу әле аларның бик азы гына), агломерацион идарәнең яңа системасы буенча проектлар эшләү дә, муниципалитетара программа һәм проектлар әзерләү дә дәүләт, муниципаль һәм корпоратив идарә тармагындагы идарәчеләрнең белемен арттыру, кабат укыту (ә, бәлки, кире әзерләү), квалификациясен күтәрү буенча алдан ук катлаулы эш алып баруны таләп итә. Өстәвенә, бу эш санап кителгән проблемаларны хәл итүгә юнәлтелгән белем бирү программалары һәм аларның модульләре нигезендә үткәрелергә тиеш. Шулай булмаган очракта Стратегияне гамәлгә кертү планы эшләнгән, ә аны гамәлгә кертер кеше булмаган хәлдә калырга мөмкинбез. Стратегиянең төп максаты – кеше капиталын үстерү, ул хезмәт традицияләрен дә, сәламәтлек торышын да, кадрларның белем һәм әзерлек дәрәҗәсен дә, яңалыкларны кабул итүгә сәләтне дә үз эченә ала.

Бу мәсьәләгә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов та ТР Дәүләт Советына 2016 елга Юлламасында зур әһәмият биргән: «Дәүләт һәм муниципаль идарәнең нәтиҗәлелеген күтәрү мәсьәләсе элеккечә үк актуаль булып кала. Барыннан да бигрәк, муниципалитетларның күпләп юкка чыгарылган норматив хокукый актлары борчу уята. Бу хезмәткәрләрнең хокукый белем дәрәҗәсе түбән булуын дәлилли. Хөкүмәткә ел саен муниципаль берәмлекләрнең хокук юнәлешендәге белгечләрен әзерләү буенча максатчан төркемнәр, шулай ук квалификацияне күтәрү курсларын оештырырга кирәк». Шундый ук проблемалар башка тармакларның да күпчелегенә хас.

***Инфраструктураның алгарышлы үсеше, хезмәт базарының киңәюе һәм үсешкә юл тотуы, инвестицияләр җәлеп итүне стимуллаштыру, фәнни, социаль, мәгариф һәм башка тармакларны үстерү дә агломерациянең уңай нәтиҗәләре булып тора. Икенче яктан караганда, агломерацион процесслар муниципаль берәмлекләр социаль-икътисадый үсешенең төбәк эчендәге ярашмаучанлыгын көчәйтә, халыкның ерак урнашкан муниципалитетлардан «юылуына» булыша, төбәкнең аерым территорияләренең традицион тарихи, социомәдәни үзенчәлекләренең зәгыйфьләнүенә китерә.***



Күрәсең, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең база белеме дә, алынган һөнәри күнекмәләре дә шактый аерыладыр. Моны өлешчә аңлатып та була, чөнки аларның хезмәтләрендә эшчәнлек даирәләре төрле. Әмма аларның һәркайсы белергә тиешле база белемнәре һәм күнекмәләр дә бар. Алда санап кителгән проблемалар контурында нәкъ менә алар бирелергә тиеш тә.

Кызганычка, илдә гамәлдә булган кадрларны укыту системасы элеккечә үк артык теоретик булып кала: укыту нигездә муниципаль һәм дәүләт хезмәте һәм идарәсенең теоретик мәсьәләләрен үз эченә ала, территориаль, аерым алганда, муниципаль күптөрлелекне, шулай ук укучыларның әзерлек дәрәҗәсен һәм аларның һөнәри эшчәнлегенең профилен исәпкә алу мөмкинлеге бирми торган программа һәм стандартлардан гыйбарәт. Моннан тыш, системаның төбәкләр һәм ил үсешенең хәзерге чынбарлыгына тулысынча яраклаштырылган булуы зарур. Методикалар даими яңартылырга, законнардагы, икътисадтагы һәм социаль тармактагы үзгәрешләрне, сәяси конъюнк-



***Бу мәсьәләгә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов та ТР Дәүләт Советына 2016 елга Юлламасында зур әһәмият биргән: «Дәүләт һәм муниципаль идарәнең нәтиҗәлелеген күтәрү мәсьәләсе элеккечә үк актуаль булып кала. Барыннан да бигрәк, муниципалитетларның күпләп юкка чыгарылган норматив хокукый актлары борчу уята. Бу хезмәткәрләрнең хокукый белем дәрәҗәсе түбән булуын дәлилли. Хөкүмәткә ел саен муниципаль берәмлекләрнең хокук юнәлешендәге белгечләрен әзерләү буенча максатчан төркемнәр, шулай ук квалификацияне күтәрү курсларын оештырырга кирәк».***

тураны исәпкә алып төзәтелергә тиеш.

КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарәнең югары мәктәбе соңгы елда әлеге бурычларны хәл итү буенча зур эш башкарды, һәм күп нәрсәгә ирешелде. Алай гына да түгел, башка төбәкләрдә дә кулланырлык инвариант программа һәм технологияләр эшләнде. Менә берничә мисал.

Барлык программалар да диярлек практикага юнәлтелде. Кейс технологияләре киң кулланыла. Компьютер сыйныфы җиһазландырылды, биредә укучылар тест һәм алынган белем, күнекмә, осталыкларының сыйфатын бәяләүне утә. Программадан соңгы контрольне кертү буенча эш башланды, ул мәктәп укучылары белән элемтә урнаштырырга һәм алынган белемнәрнең файдасын бәяләргә мөмкинлек бирә. Дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарында өйрәнү мәйданчыклары төзү, аларны аккредитацияләү буенча норматив хокукый актлар проектлары эшләнде. Күчмә стратегик сессияләр һәм түгәрәк өстәлләр технологияләре актив кулланыла. Министрлык һәм ведомстволар, җирле үзидарә органнары җитәкчеләре проектлы идарәгә, системалы анализга һәм тайпылышлы идарәгә юнәлтелгән тематика буенча укыды. Бу эш 2015 елда Сколково дәүләт һәм муниципаль идарә мәктәбе белгечләре катнашында үткәрелде.

Быел республикада тармак һәм муниципалитетлар үсешенең бишьеллык стратегияләрен эшләү буенча зур эш үткәрү зарур, һәм бу эштә шулай ук ДМИЮМнең укыту һәм технология ресурслары файдаланылачак. Хәзер республикада бу юнәлештә җирле администрация органнары, авыллардагы җирле үзидарә органнары җитәкчеләре, бизнес вәкиләре катнашында стратегик сессияләр үткәрү буенча эш тәгәлләнеп килә, аның нәтиҗәләренә таянып, муниципаль район составындагы барлык җирлекләр үзләренең социаль-икътисадый үсеш планын эшли. Нәкъ менә шул планнарны гамәлгә кертү Стратегиянең үтәлүен тәэмин итәргә тиеш.



Надил ГЫЙМАДЕТДИНОВ тексты.
Автор фотолары.

# Эш – уртак, өлеш – шәхси

ХАЛЫКНЫҢ ТОРМЫШ ДӘРӘҖӘСЕН ҺӘМ СЫЙФАТЫН КҮТӘРҮ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БИЛГЕЛӘҮЧЕ ТӨП КҮРСӘТКЕЧ БУЛДЫ ҺӘМ БУЛЫП КАЛА БИРӘ. ФЕДЕРАЛЬ, РЕСПУБЛИКА, МУНИЦИПАЛЬ ПРОЕКТЛАР ҺӘМ ПРОГРАММАЛАР ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛИТЕТЛАРЫ ӨЧЕН БУ ЭШТӘ ЗУР ЯРДӘМГӘ ӘЙЛӘНДЕ. ШУЛАРНЫҢ НӘТИҖӘСЕ БУЛАРАК, ШӘҺӘРЛӘРЕБЕЗ ҺӘМ АВЫЛЛАРЫБЫЗ КҮЗГӘ КҮРЕНЕП ҮЗГӘРӘ, КӨННӘН-КӨН БИРЕДӘ ГОМЕР ИТҮ УҢАЙЛЫРАККА ӘЙЛӘНӘ БАРА.

Үзсалым программасы республикада җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишүнең иң кулай ысулларының берсе булып тора, әлеге кысаларда муниципаль казнага халыктан кергән һәр 1 сум акчага республика бюджеты 4 сум өсти. Үзара салым программасы 2013 елда башланып китте һәм әкренләп муниципаль бюджетларны тутыру өчен өстәмә чыганак кына түгел, бәлки халыкның активлыгын күтәрүнең реаль чарасына әверелде. Бары тик 2015 елда гына да республиканың 41 районындагы 779 муниципаль берәмлектә үзара салым буенча референдумнар үткәрелде. Гражданнар тарафыннан 122,3 миллион сум акча җыелып, республика әлеге суммага 500 миллион сумга якын акча өстәде. Күләме кайбер республика программалары бюджетлары белән чагыштырырлык әлеге акчаларга муниципалларыбыз халыкны борчыган шактый проблемаларны хәл итүгә ирештеләр. Әйтик, узган елны референдум оештырган җирлекләрнең күпчелеге, атап әйткәндә, 28,2%ы акчаларны җирлекләрне төзекләндерүгә тотарга ниятләде, 26,7%ы – торак пункт эчендәге юлларны, шул исәптән күперләрне ремонтларга һәм карап торырга, 16,5%ы – зиратларны төзекләндерергә һәм карап торырга, 10,7%ы – су белән тәэмин ителешне оештырырга дип билгеләде. Калган акчалар муниципалитетларда янгын куркынычсызлыгын булдыруга, каты калдыклар полигонын карап тотуга, елга-күлләрне, чишмәләрне төзекләндерүгә, һәйкәлләр куюга һәм булганнарын төзәтүгә һәм башка чараларга тотылды.

**Татарстаннан тыш, үзара салым кертү турындагы референдумнар Пермь краенда һәм Киров өлкәсендә актив үткәрелә – мондый чаралар саныннан 70 проценты әлеге төбәкләргә туры килә. Халыктан җыелган бер сумга биш һәм бер сум ярым акча өстәлә. Әйтик, 2015 елда Киров өлкәсендә үзара салым 148 җирлектә кертелгән, шуның нәтиҗәсендә 11 миллион сум акча тупланган. Соңгы ике елда үзара салым буенча референдумнар шулай ук Алтай һәм Красноярск крайларында, Амур, Курган, Оренбург өлкәләрендә оештырылган. Быелның сентябреннән Чиләбе өлкәсендә дә ирекле түләүләр кертергә планлаштыралар.**

Урыннарда үзара салым тәҗрибәсен куллану агымдагы елда да дәвам ителәчәк. 1 майга республиканың 38 районында урнашкан 800гә якын муниципаль берәмлектә референдумнар инде үткәрелде. Тагын 5 район ел ахырына кадәр халык тавыш бирүләрен уздырырга җыена.

## БИТАРАФЛАРНЫ ЙӨГӘНЛӘҮ

Ләкин татарстанлыларның барысы да уртак эш өчен акчасын чыгарып бирү теләге белән янамы соң? Тормыш шуны раслый: һәркем һәм һәрвакытта да түгел. Республиканың аерым җирлекләрендә халык референдумнарны бар дип тә белми (әйтик, быел тавыш бирүчеләрнең аз санда килүләре аркасында Бөгелмә районы Кече Бөгелмә авылы җирлегендә, Биектау районы Усад һәм Дачное авылы җирлекләрендә, һәм шулай ук Тукай районы Кече Шилнә авылы җирлегендә референдумнарны үткән дип санап булмаган), яисә үз территорияләрендә үзара салымны кертүгә каршы тавыш бирүләр дә очрый. Ә инде референдумнар үткәрелгән дип танылган җирлекләрдә дә еш кына акча җыюлар белән проблемалар туып тора.

Гомумән алганда, республика буенча гражданнардан үзара салым акчаларын җыю планлаштырган сумманың 17дән 62 процентка чаклысын тәшкил итә. Мисалга, Баулы районында 2015 елда үзара салым планының 53 процентын (җыеп бетерелмәгән акча – 810 550 сум) җыюга ирешәләр, Биектау районында – 62 процент (2,18 миллион сум җыеп бетерелмәде), Яшел Үзән районында – 55 процент (3,21 миллион сум җыеп бетерелмәде), ә Спас районында – 48 процент (җыеп бетерелмәгән акча – 2,31 миллион сум).

Килеп туган вазгыятьтән чыгып, агымдагы елның 8 апрелендә Татарстан Хөкүмәте республика Дәүләт Советына «Административ хокук бозулар турында ТР Кодексының 2.6 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында» 222-5нче закон проектын кертте. Анда үзара салым акчаларын түләмәүчеләргә 1 мең сумнан алып 2,5 сумгача штраф салырга тәкъдим ителә. Әгәр хокук бозу ел дәвамында кабатлана икән, әлеге сумма 5 мең сумга кадәр үсә. Бу миңа кагылмый дип, кул кушырып утыручылар өчен административ җәзалар агымдагы елның ахырында ук гамәлгә кертелергә мөмкин.

Республика Административ хокук бозулар кодексына төзәтмәләр кертүнең авторлары муниципалитетларның үзләренең әлеге мәсьәләне җайлауны сорауларын аңлатып үтәләр: Биектау, Балык Бистәсе һәм Тәтеш районнары администрацияләре Татарстан Юстиция министрлыгына түләмәүчеләр өчен штрафлар кертүне сорап мөрәҗәгать иттеләр.

Закон проекты кабул ителгән очракта Татарстан Россиянең референдум карарларын үтәмәү административ хокук бозу дип саналган һәм моның өчен тиешле җәза бирелә торган төбәкләренә кушылачак. Алар арасында Ингуш Республикасы, Коми, Мари Эл, Хакасия, Волгоград, Киров, Түбән Новгород, Оренбург, Псков, Сахалин, Тверь, Орел, Чиләбе өлкәләре һәм Красноярск крае бар.

## ИРЕКЛЕМЕ ЯИСӘ МӘҖБҮРИМЕ?

Ләкин, дип саный Спас районы Болгар шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе Алексей Тюленев, штраф салулар Татарстанда үзара салым акчаларының җыелуын арттырмаячак, алай гына да түгел, гомумән программаның бөтен мәгънәсен югалттырачак.

– Үзсалым – ул ирекле муниципаль җыем, – ди Алексей Михайлович, – ә хәзерге вакытта республика Дәүләт Советына каралуга кертелгән закон проекты аны автомат рәвештә мәҗбүри салымнар дәрәҗәсенә күтәрәчәк. Нәтиҗәдә киләсе елда референдум үткәрү вакытларында без буш сайлау участокларына юлыгырга мөмкинбез. Бу яктан нинди дер финанс бурычлары бул-

Кама Тамагы Балтач авылы җирлегендәге юллар үзара салым нәтиҗәсендә барлыкка килде.



*Закон проекты кабул ителгән очракта Татарстан Россиянең референдум карарларын үтәмәү административ хокук бозу дип саналган һәм моның өчен тиешле җәза бирелә торган төбәкләренә кушылачак. Алар арасында Ингуш Республикасы, Коми, Мари Эл, Хакасия, Волгоград, Киров, Түбән Новгород, Оренбург, Псков, Сахалин, Тверь, Орел, Чиләбе өлкәләре һәм Красноярск крае бар.*

***Ләкин татарстанлыларның барысы да уртак эш өчен акчасын чыгарып бирергә әзерме соң? Һәркем һәм һәрвакытта да түгел. Республиканың аерым җирлекләрендә халык референдумнарны бар дип тә белми (әйтик, быел тавыш бирүчеләрнең аз санда килүләре аркасында Бөгелмә районы Кече Бөгелмә авылы җирлегендә, Биектау районы Усад һәм Дачное авылы җирлекләрендә, һәм шулай ук Тукай районы Кече Шилнә авылы җирлегендә референдумнарны үткән дип санап булмаган), яисә үз территорияләрендә үзара салымны кертүгә каршы тавыш бирүләр дә очрый. Ә инде референдумнар үткәрелгән дип танылган җирлекләрдә дә еш кына акча җыюлар белән проблемалар туып тора.***



Балтач районы үзәгендә «Балтач» ял итү паркы ачылышы. Парк үзара салым акчаларын кулланып төзелде.

ган гражданнар төрле белешмәләр сорап мөрәҗәгать иткәндә, аларга җирле үзидарә органнары тарафыннан белешмәләр бирмәүне (Болгар шәһәре башкарма комитеты елына 12 меңгә якын төрле белешмә бирә – авт.) закон белән рөхсәт итүне кертү тәэсирлерәк чара булыр иде.

Үзара салым кысаларында Болгарда беренче референдум узган елның гыйнварында оештырылган. Халыкка һәйкәлләрне, мөселман һәм православие зиратларының коймаларын ремонтлау, һәм шулай ук район үзәгенең ике урамына таш җәю өчен өчәр йөз сумнан акча җыеларга тәкъдим ителә. Ләкин кайдадыр җирле хакимиятләр эшләп җиткермәгәнме, әллә халык үзе, яраткан шәһәребез болай да бик матур күренә, дип хәл иткәнме, факт факт булып кала бирә: фаразланган 2,2 млн сум урынына шәһәр казнасына халыктан бары тик 485 мең сум гына акча кергән. Өстәвенә, программага шәһәрнең хәлле дип саналган гражданнары да битараф калганнар.

Һәм монда гаҗәпләнергә урын юк кебек: үзара салым ул – халык бер-берсен яхшы белгән һәм акчаларның нәрсә өчен тотылуы шундук күренгән авыл җирлекләре өчен гадәти хәл. Шәһәрдә исә, бигрәк тә эреләрендә, кешеләр бер-берсеннән ераграк, үзе бик сирәк үтеп йөргән чит урамны матурлау яисә андагы юлны төзекләндерү өчен акча бирергә атлыгып торучыларның аз булуы аңлашыла да. Шуңа күрә үзара салым кебек күркәм эш шәһәрлеләрдә битарафлыктан башка бернәрсә дә уятмаска мөмкин.

Шуңа да карамастан, быелның 17 гыйнварында Спас районы үзәгендә яңа референдум үткәрелгән, анда шәһәрдә теркәлгән балигълык яшендәге һәр кешедән шул ук 300 сум акча җыярга карар кылынган. Акчаларны «Революция көрәшчеләренә» һәм В.И. Ленин һәйкәлләрен төзекләндерүгә, һәм шулай ук паркларны матурлауга тотарга ниятлиләр. Муниципаль берәмлек администрациясендә гражданнар, бу юлы референдум карарының файдасын аңлап, үз шәһәрләрен төзекләндерүгә булдыра алганча өлеш кертерләр, дип ышаналар.

– Дөресен генә әйткәндә, үзара салым акчаларының җыелуына карата без әллә ни зур өметләр багламадык, – дип, дәвам итә сүзен Алексей Тюленев. – Ләкин барыбер программада катнашырга уйладык, чөнки халыкны кузгатырга, авыл җирлекләрендәге кебек үк, җирле әһәмияттәге көнүзәк проблемаларны хәл итү эшенә аларны да җәлеп итәргә телибез. Быел халык активрак булыр дигән өметне әле җуймыйм. Узган ел референдумы карарында язылган барлык диярлек бурычларны без хәл итәргә өлгердек бит.

## ХУҖА ТӘРБИЯЛӘҮ

Исегезгә төшерик, үзсалым программасы буенча республика акчалары Татарстан муниципалитетларына ярты елга бер мәртәбә күчерелә. Шуңа күрә барлык билгеләнгән бурычларны кыска вакыт эчендә тулы күләмдә хәл итеп бетерү өчен, муниципаль берәмлекләргә халыктан барлык акчаларны да беренче яртыеллыкта җыеп бетерү максатка ярашлы булыр иде.

Болгар белән күршедә генә яши торган Три озера авыл җирлеге җитәкчелеге дә моны яхшы аңлый, биредә үзсалым акчаларына юлсызлык проблемасын хәл итәргә тырышалар икән. Хәзерге вакытта Три озера авылы һәм Үрнәк бистәсен берләштергән муниципаль берәмлектә гомумән алганда 760 кеше гомер итә. «Сум белән тавыш бирүне» биредә 2015 елдан башлыйлар, ләкин әлегә бу эштә әллә ни уңышка ирешмәгәннәр. Узган ел халыктан акчаны зур авырлык белән генә җыйганнар, быел да бу эш бик акрын бара. Авыл җирлеге башлыгы Сергей Рыжев сүзләренә караганда, пассивлык гомумән алганда Три озера авылы халкында күзәтелә, алар арасында күченеп килгәннәр күп икән, әйтик, күрше Ульяновск өлкәсеннән.

– Алар безнең авылны үзләренең туган нигезләре санамыйлар, аңа бары тик тору урыны итеп кенә карыйлар, – дип борчыла Сергей Владимирович. – Җитмәсә





Спас районы Иске Рәҗәп авылы җирлеге башлыгы Мансур Нугаев үзара салымның алар өчен инде таныш булуын әйтеп үтте.




Иске Рәҗәп авылында Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 65 еллыгына гражданнар һәм спонсорлар акчаларына сугыш елларында һәлак булганнар һәм сәяси репрессия корбаннары истәлегенә мемориал ачылган. Проектның инициаторы булып сугыш ветераны Зиннәтулла ага Гыйззәтуллин тора.

Три озера авылында аз керемле күп балалы гаиләләр бар, аларның кайберләре социаль яктан куркыныч булган төркемгә керәләр һәм хәтта коммуналь чыгымнарны да күтәрә алмыйлар. Шуңа күрә без гражданнардан 200 сумнан да артыграк акча җыя алмыйбыз. Күктәге торнага караганда, кулдагы песнәк яхшырак бит.

Биектау районы Чыпчык авылы җирлеге башлыгы Илшат Җиһаншин да шундый ук сәбәпләр аркасында үз эшендә әлеге принципны куллана. Ул җитәкләгән муниципаль җирлеккә Иске һәм Яңа Бөреле, Чыпчык һәм Байкал авыллары керә. Биредә 2078 кеше гомер сөрә. Өстәвенә, бу бары тик теркәлгән гражданнар саны гына. Муниципалитет территориясендә яшәүче халыкның бер өлеше ел әйләнәсе биредә яшәсә дә, алар теркәлмәгәннәр.

– Мондый кешеләрне мин «дачниклар» дип атыйм, – дип аңлатма кертә авыл җирелеге башлыгы. – Алар безнең җирлек тормышында катнашмыйлар, ләкин теркәлеп яшәгән күршеләре файдаланган уңайлылыклардан файдаланалар. Үзара салымга аларны җәлеп итеп булмый, сайлауларга да. Ярар инде су һәм каты калдыкларны чыгару өчен булса да түлиләр.

Хезмәткә яраклы барлык халкы диярлек Казанда эшләүче Чыпчык авыл җирлегендә соңгы референдум 2015 елның декабрендә үткәрелгән. Һәр балигъ булган сайлаучыдан (алар биредә – 1400 кеше) урам яктырткычларын реконструкцияләү максатына 100әр сум акча җыярга карар кылынган. Әмма уңышка гарантия юк. Май башына планлаштырылган 140 мең сум акчадан халык уртак казанга әлегә 30 проценттан аз гына күбрәк күләмдә акча керткән.

Шулай да республикада халкы үзенең хуҗа булу хисен югалтмаган авыл җирлекләре дә җитәрлек. Менә бер мисал – Спас районы Иске Рәҗәп авылы, биредәге халык совет чорыннан ук җирле әһәмияттәге сорауларны хәл итүдә актив катнаша. Мәсәлән, халык акчалары хисабына үз вакытында биредә бер генә кое казылмаган, шул ук юл белән күпме юл төзекләндерелгән, урам яктырткычлары автоматлаштырылган системага күчерелгән, үз хаҗәтләре өчен ике янгын сүндерү машинасы, ДТ-75 тракторы сатып алынган. Моннан тыш, Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 65 еллыгына гражданнар һәм спонсорлар акчаларына сугыш елларында һәлак булганнар һәм сәяси репрессия корбаннары истәлегенә мемориал ачылган. Проектның инициаторы булып сугыш ветераны, РСФСР халык мәгарифе отличнигы һәм ТРның атказанган укытучысы Зиннәтулла ага Гыйззәтуллин тора.

Иске Рәҗәп авыл җирлеге башлыгы Мансур Нугаев сүзләренә караганда, республикада үзсалым программасы старт алганнан бирле, муниципаль берәмлек составындагы бердәнбер авыл җирлеген төзекләндерүгә кертелгән акчалар күләме шактыйга арткан. Бигрәк тә референдумда тавыш бирү хокукына ия һәркем җәмәгать ихтыяҗлары өчен үз кесәсеннән бер мең сум акча чыгарып биргәндә. Шуның нәтиҗәсендә торак пунктта бүген әкренләп урам яктырту системасы һәм юл челтәре яңартылган, авылның өч инеше аркылы утеп йөрү өчен 9 җәяүле күпере төзелгән, авыл радио үзәге карап тотыла, зиярат яңа койма белән әйләндереп алынган. Быел биредә программа кысаларында, атап әйткәндә, Сабантуй үткәрү мәйданын матурларга, өстәмә су скважинасын борауларга һәм шул юл белән җәйге чорда кайбер урамнарга су җитмәү проблемасын хәл итәргә, туфрактан өелгән ике плотинакүпер төзергә, зиратны төзекләндерүне тәгәлләргә уйлыйлар.


– Үзсалым – бик кирәкле эш, – дип, үз фикере белән уртаклаша Иске Рәҗәп ФАП мөдире Фәйрүзә Миңсадыйкова. – Кайбер авылдашларымның әлегә кадәр моны аңлап җиткермәүләре кызганыч. Акчаларның күләменә килгәндә исә, елга бер мәртәбә бер мең генә бирү мөмкин эштер. Бу акчалар кемнеңдер кесәсенә керми бит, авылыбызны матурлау һәм төзекләндерү өчен тотыла. Үзебез кайгыртмасак, моны безнең өчен беркем дә эшләмәячәк бит.



**10 млрд 702 млн сум Татарстанда юл челтәрен төзүгә һәм аны ремонтлауга бүлеп бирелә.** Шулардан ремонтка дип, 4 млрд 368 млн сум билгеләнгән, карап тотуга – 3 млрд 431 млн, төзүгә һәм реконструкцияләүгә – 1 млрд 717 млн сум.



**17 млрд сумга якын – республикада быелгы чәчү кампаниясенә әнә шулкадәр акча тотыла.** Сезонлы эшләрне исәпкә алганда чыгымнар 30 млрд сумнан артыкны тәшкил итәчәк. Быелгы чәчү кампаниясенә 11 мең трактор, 6 мең чәчкеч, 620 чәчү комплексы, 6,5 мең культиватор һәм башка техника җәлеп ителгән.



**70%ка – 2015 елның шул ук чоры белән чагыштырганда, быелның беренче кварталында республикада законсыз әйләнештән алынган алкоголь күләме әнә шулкадәргә арткан.** Ел башыннан барлыгы 69 литрдан артык алкогольнең законсыз әйләнеше туктатылган. Салынган штрафларның гомуми суммасы 6 млн сумга якын булган.



**101,9 процент – 2016 елның 1 кварталында Татарстанның тулай төбәк продукты күләменең үсеше,** узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, шулкадәрне тәшкил итә, сәнәгать җитештерүе индексы – 102,1 процент, төзелеш күләме – 104,2 процент. Ваклап сатуда товар әйләнеше күләменең кимүе 1,4 процентны тәшкил итә.




**85 млрд сум – узган елны «Татнефть» ГАҖ шулкадәр күләмдәге чиста табыш алган.** Барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларга күчерелгән салым һәм түләүләрнең гомуми суммасы 263 миллиард сумны тәшкил иткән.

**29 – халыкка социаль хезмәт күрсәтүче шул сандагы учреждение агымдагы елга капиталь ремонт программасына кертелгән.** Программаны финанслау күләме – 121,15 млн сум.



**18 административ-торак комплексы – полициянең участок уполномоченныйлары өчен Татарстанда** хезмәт торагы төзү программасы кысаларында әнә шулкадәр санда төзеләчәк.




**12,4 млрд сум – узган ел «Алабуга» МИЗнда резидентлар шулкадәр күләмдәге инвестицияләр кертkәннәр.** Резидентларның керемнәре – 40,1 млрд сум. 2015 елда МИЗ предприятиеләре түләгән салым күләме 3,2 млрд сумны тәшкил иткән.




**4,2 млрд сумга республиканың федераль акчалар хисабына** (2015 елның 1 кварталында – 8,1 млрд сум, 2016 елның 1 кварталында – 3,9 млрд сум) башкарыла торган чыгымнары кимегән.



**9,7 млрд сум 2016 елның 1 кварталында бюджетара трансфертлар формасында җирле бюджетларга** (республиканың муниципаль берәмлекләренә) күчерелгән.





Линар ЗАКИРОВ тексты.
Андрей ТИТОВ фотолары.

# АВЫЛ язмалары

«БЕЗНЕҢ АВЫЛДАГЫ ИСКЕ КҮПЕРНЕ ЯЗГЫ ТАШУ МОННАН УТЫЗ ЕЛЛАП ЭЛЕК АЛЫП КИТКӘН ИДЕ. ЯҢАСЫН САЛДЫЛАР, АНЫСЫ УН ЕЛДАН ӘЗ ГЕНӘ АРТЫГРАККА ЧЫДАДЫ. АНЫҢ АША АВЫР ТЕХНИКА ҮТӘ АЛМЫЙ ИДЕ. БӘХЕТКӘ, 2015 ЕЛДА БЕР ЯРДАН ИКЕНЧЕ ЯРГА ЯҢА КҮПЕР САЛДЫЛАР. БОРЫНГЫДАН КИЛГӘН ГАДӘТ БУЕНЧА, АННАН БЕРЕНЧЕ БУЛЫП МӘЧЕ, АНЫҢ АРТЫННАН ИСӘ КАМАЗ ЧЫКТЫ», – ДИП СӨЙЛӘДЕЛӘР БЕЗГӘ РЕСПУБЛИКАБЫЗНЫҢ АПАС РАЙОНЫ КАРАБАЙ АВЫЛЫНДА ЯШӘҮЧЕЛӘР.

## АВЫЛ КҮПЕРЛӘРЕ

Карабайда безне бик күңелле әбиләр каршы алды, алар гел елмаеп кына торалар. Мөгаен, аларга яңа күпер шулай тәэсир итәдер. Күперне авыл җирлеге, республика бәйгесендә җиңеп, миллион сумлык грант алгач төзегәннәр.

– Элек язгы ташу вакытында күпер янына зур боз кисәкләре килеп бөялә иде. Аларны багор белән тарттырып, бик азаплана идек! Моннан 11 ел элек иске күпер агып киткәч, авыл фельдшеры Земфира Зарипова яңасын төзеттерә алды. Тик соңгы елларда аның аша машиналар түгел, инде кешеләр дә чыгарга курка иде. Машиналар ерактан әйләнеп йөрде. Яңа күпер исә авырлыгы өч тоннага кадәр булган техникага исәпләнгән. Күрәсезме, хәтта махсус билге дә куйды-

Үләмә елгасы язгы ташу вакытында авыл халкына күп проблема тудыра. (Новопоселенное Ишеево авылы күпере).





Алсу Хәйруллина җирлекне үткән елның маенда җитәкли башлаган.





Иске Йомралы мәктәбенә илтүче юлны ремонтлау вакытында.

лар. Быел кар аз яуганга, язгы ташу да булмады, – дип сөйли Оркыя апа Гайнетдинова.

Без күпергә хозурланып торганда, яныбызга биредә яшәүче Рәфыйк абый Ибраһимов килде һәм авылда кибет булмауга зарланды.

– Атнага ике тапкыр автолавка килә. Тик аннан теләгән бөтен нәрсәне дә алып булмый. Кайвакыт бит туңдырма белән дә сыйланасы килә. Кайчагында исә өйгә кайтып җиткәч кирәкле әйберне алмаганың искә төшә, ә бу вакытта инде кибетле машина киткән була. Безнең үзебезнең дә авыл кибете бар иде анысы, тик бина арендасының кыйбатлыгын сылтау итеп, сатучылар киттеләр, – ди ул.

Иске Йомралы авыл җирлеге башлыгы Алсу Хәйруллина әйтүенчә, район җитәкчелеге әлеге проблемадан хәбәрдар, һәм якын арада ул хәл ителергә тиеш.

Миллион сум грант акчасын ике авылга бүлергә булалар. Карабайдагы кебек үк, Новопоселенное Ишеево авылындагы күпер дә 500 мең сумга төшкән.

Бу авылда нибары 56 кеше яши. Аз халык яшәгәнгә, ул республика һәм федераль программаларның берсенә дә эләкми. Бу аңлашыла да, зурларында да хәл ителмәгән проблемалар бихисап булганда, мондый бәләкәй авылларга акча бүлү мөмкинлеге юк. Әмма авыл халкы бер дә күңелен төшерми.

Үләмә елгасы язгы ташу вакытында авыл халкына күп проблема тудыра. Иске күпернең файдалану срогы күптән чыккан инде. Соңгы вакытка кадәр машиналар, авылга керер өчен, ерактан әйләнеп йөргән.

Без Новопоселенное Ишеево авылына килеп җиткәч, яңа күпер янында бик күп таш һәм кирпеч ватыклары ятканын күрдек.

– Ташу вакытында су ташларны юды, – дип аңлата Алсу Эдуард кызы. – Күпер астына без иске товар вагоны нигезен урнаштырдык. Бездән ерак булмаган Каратун тимер юл станциясенә мөрәҗәгать иттек. Вагон төбенә тагын бер кат калай эретеп ябыштырдык. Күпернең кырыйларына ак «Жигули» ташлары җәйдек. Култыксалар куймаска булдык. Игътибар итегез, күпер кырыйларын тишеп, без анда таяклар тыктык. Ташу вакытында машиналар аларга карап юлны таба. Җәяүлеләр исә 2–3 атна буе асылмалы күпердән йөрде.

– Ә бит туфракны күбрәк ташып, күперне биегрәк итеп тә булыр иде, – дим мин.

– Теләк булса, барысын да эшләп була, әмма 500 мең сум гына җитмәс иде.

## ТРАНСПОРТ МӘСЬӘЛӘСЕ

Алсу Хәйруллина җирлекне үткән елның маенда җитәкли башлаган. Августта аңа өр-яңа «Шевроле-Нива» машинасын биргәннәр. Автомобиль авыл җирлекләре арасында үткәрелгән республика бәйгесендә җиңгән өчен бирелгән. Иске Йомралы авыл җирлеге күп кенә күрсәткечләр буенча районда беренче урынга чыккан. Җиңүчеләрне билгеләгәндә, шактый фактор исәпкә алынган: халык саны, пенсионерлар һәм хезмәт яшендәге халык нисбәте, социаль объектлар саны һ.б.

Машина йөртергә әллә кайчан өйрәнсә дә, Алсу Хәйруллинага моңарчы рульгә утырырга туры килмәгән булган. Район мәгариф бүлеге җитәкчесе һәм район мәшгульлек үзәге директоры вазыйфасында эшләгәндә, аны эш машинасында йөрткәннәр.

– Бу вазыйфага керешүгә үк, район җитәкчелегеннән эш машинасы сорадым. Баштарак миңа иске «Нива» бирделәр, майдан августка кадәр шуңарда йөрдем. Иска машинада яхшылап йөрергә өйрәндем, шуңа инде яңасына утырырга курыкмадым, – дип сөйли ханым.

## ИСКЕ ЮЛНЫҢ ЯҢА ГОМЕРЕ

Иске Йомралы мәктәбенә алып бара торган урамда эш кайный. «Юл-урам челтәрен норма хәленә китерү» республика программасы кысаларында җирлеккә юл полотносының 586 метрын ремонтлауга акча бүленгән. Җимерелеп бетә язган иске юл инде мон-



«Әнием сугыш вакытында дүрт бала белән ялгыз калган, сыер асраган, шуңа безнең табында һәрвакыт сөт булды», – дип искә ала Фәния апа Галиуллина.




«Безнең Иске Йомралы клубы, иске булса да, матур», – дип сөйли Резеда Гайнетдинова.

нан егерме ел элек үк салынган. Әлбәттә, аны хәлдән килгәнчә ремонтлап торганнар. Мәсәлән, үзара салым акчасына аңа таш җәйгәннәр. Тик ул озакка бармаган.

Былтыр Карабайда да бер бик начар юлны яңарткannaр. «Хәзерге йөкләнеш вакытында бер кат асфальт белән генә булмый, шунлыктан биредә ике кат асфальт түшәячәкләр», – дип сөйли авыл җирлеге башлыгы.

Мәктәп директоры Радик Газизов әйтүенчә, язгы пычракта бу юлдан мәктәп автобусы үтә алмаган, укучыларга бинага кадәр җәяү барырга туры килгән.

Бүген биредә биш авылдан 63 бала укый, 20 укытучы эшли. Киләсе елда беренче сыйныфка 18 бала укырга керәчәк. Күрше авыл балаларын автобус иртәнге сәгать 7гә китерә, ә мәктәптән иң ерак урнашкан Иске Әнәле авылына автобус 6.30 да килеп җитә.

– Бик иртә түгелме соң? – дип аптырыйм мин.

– Әйе, иртә, тик барысы да әти-әниләр белән килештерелгән, беркем дә каршы түгел, – ди директор.

Бу мәктәп районда үзенең көчле хоккей командасы белән данлыклы. Берничә тапкыр районда беренче урынны да алганнар. Әмма быел яшь спортчылар өченче урынга төшкән. Радик Газизов әйтүенчә, биш ел элек мәктәп янына хоккей тартмасы куйганнар, тренерлары да яхшы, тик авылда малайлар гына азая бара.

## ХӘТЕР СТЕЛАСЫ

Иске Йомралы авыл җирлегендә өч тапкыр үзара салым буенча референдум үткәрелгән. 2015 ел азагында 190 мең сум акча җыйганнар. Дәүләттән дүрт тапкыр күбрәк кергән. Барлыгы 950 мең сум акча җыелган.

Авылдашлар эшләнәсе эшләр исемлеген алдан ук билгеләп куйган. 9 майга клуб каршында яңа мемориал комплекс төзегәннәр, анда сугыш һәм тыл ветераннарының исемнәре мәңгеләштерелгән, мәйданчыкка таш түшәгәннәр, эскәмияләр куйганнар. Элеккерәк елларда шундый ук хәтер стелалары Карабай һәм Новопоселенное Ишеево авылларында да урнаштырылган.

77 яшьлек Фәния апа Галиуллина әтисе – Гыйниятуллин Хәбибулла Гыйният улының исеме язылган мемориалны бик бирелеп карый. Сугыш вакытында аның һәлак булуы турында хәбәр килгән, ә менә кайда икәне – билгесез.

– Әтием фронтка киткәндә, миңа 2,5 яшь, энемә 9 ай булган. Әтиемнең апасы сөйләвенчә, ул сугышка җыенганда мин чоланда йоклаган булганмын. Әти минем яныма кереп, үпкән дә китеп барган. Мин шуннан соң бер генә тапкыр да «әти» дип әйтә алмадым... Ә бит бик әйтәсе килгән чакларым күп булды! Менә минем улларым да әтисез калды, ирем фаҗигале төстә гүр иясе булды. Бишесен дә тәрбияләп үстердем, киленнәрем дә яхшы, сөенеп яшим. Әнием исә дүрт бала белән ялгыз калган, сыер асраган, шуңа безнең табында һәрвакыт сөт булды, – дип искә ала Фәния апа.

Хәбибулла абзый өендәгеләргә берничә хат язган, сыерны сатмаска кушкан. Фәния апа да фермада 40 ел буе сыер савучы булып эшләгән.

Ел саен Җиңү көне алдыннан, 8 майда, әтиләре сугышта үлеп калган балалар өчен район үзәгендә бәйрәм оештырылган, аларга күчтәнәчләр бирелгән.

## КЛУБТА ТОРМЫШ КАЙНЫЙ

– Безнең Иске Йомралы клубы, иске булса да, матур. Безгә яңа бина кирәкми, әмма бусын ремонтларга кирәк. Кышын биредә җылы, әгәр тәрәзәләрне, пәрдәне алыштырсалар, бик сөенер идек, – ди клуб мөдире Резеда Гайнетдинова. 26 ел дәвамында клуб бер тапкыр да ремонтланмаган. Авылда, киләсе елда капиталь ремонт үткәрелер, дип өметләнәләр.

– Клуб 1990 елда ачылды. Педагогика училищесында беренче курста укый идем, башка егет-кызлар белән ноябрьдә авылга кайттык һәм клуб ачылу хөрмәтенә



Яшь белгеч өчен 12 чакрым зур ара түгел. Мал табибы Радик Госманов көн саен район үзәгеннән эш машинасында килеп йөри.

аншлаг белән концерт куйдык. Ул чакта Әкрамисә апа Абдуллина мөдир иде. Мәктәптә укыганда мин Кар кызы була идем, аннары Кыш бабай да булдым. Үз акчама Кыш бабай костюмы сатып алдым. Яңа ел алдыннан капчык асам да балаларны сөендерәм. Былтыр авыл җирлеге инициативасы белән аз керемле гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларына бүләкләр өләштек... Башкала артистларын чакырырга вакыт юк, без үзебез дә күп чаралар үткәрәбез, – дип елмая мөдир.

Клубка кергәч, без сәхнәнең бик бай күренгән бәрхет пәрдәсенә игътибар иттек. Биредә чынлап та бик уңайлы иде.

– Мәктәп балалары белән Яңа ел, Нәүрүз бәйрәмнәрен оештырабыз. Сабан туе алдыннан йомырка, яулык җыябыз. Гадәттә ике ат җигәбез: берсендә – бала-чага, икенчесендә – без, өлкәннәр, тагын ике гармунчы, – дип мавыгып сөйли мөдир.

## ВЕЛОСИПЕДЛЫ ФЕЛЬДШЕР

Клуб почмагыннан мультфильмдагы хат ташучы Печкинның алыштыргысыз атрибуты – велосипед күренде. Тик анда хат ташучы түгел, авыл фельдшеры Рәйханә Гашыйгуллина булып чыкты. Апас районының күп кенә авылларында фельдшерлар күптән велосипед белән дус икән.

Рәйханә Гашыйгуллина инде 35 елдан артык медицина өлкәсендә хезмәт куя, велосипедны исә балачагыннан ук үз итә икән. Соңгы ун елда берничәне алыштырган инде.

– Миңа карап, ярты авыл халкы велосипедка күчте. Менә бу икесен генә берничек тә ышандыра алмыйм әле, – ди фельдшер, авыл җирлеге башлыгы һәм клуб мөдиренә күрсәтеп.

– Безне үгетләүдән ни файда, барыбер машинада йөрибез бит, – дип аклана тегеләре.

– Авыл халкының сәламәтлеге ничек? Нидән зарланалар? – дип кызыксынам мин.

– Йөрәккә һәм кан басымына. Соңгы елларда онкологик авырулар да күренә башлады. Аларны башлангыч стадиядә ачыкларга тырышабыз. Көн саен авылны әйләнеп чыгам. Күптән түгел барлык тыл ветераннарының, балаларның хәлен белеп йөрдем. Без бит, иң әүвәл, психолог булырга тиеш. Кеше уколдан гына сихәтләнми, аңа җылы сүз дә кирәк, – ди фельдшер.

Рәйханә апа түземсезлек белән киләсе елны көтә, чөнки җирле ФАПны ремонтларга тиешләр.

## ДОКТОР АЙБОЛИТ

Үткән җәй Иске Йомралыда яңа ветеринария пункты эшли башлаган. Бу райондагы шундый тәүге объектларның берсе. Элегрәк шул ук урындагы иске йортта ветеринария участогы урнашкан булган. Килеп җиткәндә, без яшь табиб Радик Госмановның, мәш килеп, чәчәк утырту өчен җир казып йөрүен күрдек. Былтыр авылның мал табибы Таһир абый пенсиягә чыккан, һәм ул чакта район үзәгендә эшләгән Радикны вакантлы урынга чакырганнар. Яшь белгеч өчен 12 чакрым зур ара түгел. Көн саен район үзәгеннән эш машинасында килеп йөри.

Радик безгә эт һәм мәчеләр өчен операция өстәлен күрсәтә. Мөгезле эре терлекне монда кертеп булмый, шуңа операцияләрне асралган урыннарында ясыйлар.

– Авыл халкының эт һәм мәчеләр белән кайнашырга вакыты бармыни?

– Әлбәттә, – ди Алсу Хәйруллина.

– Көндез дә, төнлә дә чакыралар, – ди Радик Госманов. – Минем хезмәт күрсәтү зонасына тугыз авыл һәм «Свияга» АХП керә.

## МӘДӘНИЯТ УЧАГЫ

2013 ел азагында Карабайда яңа клуб төзелеп беткән.

– Ә аның янында нинди йорт тора анда? – дип, гаҗәпләнеп сорыйм клуб мөдире Гөлсинә Хәмзинадан.

– Элек анда балалар бакчасы, мәктәп, соңрак клуб урнашкан иде. Янәшәдә яңа бина салына башлагач, иске клубны кызгандым хәтта. Мин бит анда алты ел эшләдем. Аңа сигез дистәләп кеше сыя иде, сәхнәсе генә булмады. Яңа елны да, башка бәйрәмнәрне дә бик күңелле үткәрә идек. Яңа клуб 75 кешегә исәпләнгән. Аны шулкадәр тиз төзеделәр, без үзебез дә таң калдык. Хәзер клубта гарәп теле, Коръән укырга өйрәнәләр, – дип сөйли ул.

Гөлсинә Хәмзина авылда яшьләрнең аз калуыннан, барысының да Казанга китәсе килүеннән зарлана. Ә менә бала-чага күп, алар дискотекаларда бик рәхәтләнеп бии.

– Ә бу – Габделхак абый, безнең авылның талисманы, – дип горурланып күрсәтә ул дивардагы фотосурәтне. – Ул – район Сабан туеның баш тальянчысы.

КАМА ЯРЫНА ҺӘР КӨН ИРТӘН, СӨЛГЕСЕН ИҢЕНӘ САЛЫП, НЫКЛЫ АДЫМНАР БЕЛӘН БЕР ИР ЧЫГЫП БАСА. УЛ, НИНДИ ҺАВА ТОРЫШЫ, КАЙСЫ ЕЛ ФАСЫЛЫ БУЛУЫНА ДА КАРАМЫЙЧА, СУГА ЧУМЫП АЛА, БАРЫ ТИК ЕЛГА БОЗ АСТЫНА ЯШЕРЕНГӘН ЧОРДА ГЫНА КҮРМӘССЕҢ АНЫ. ОЗАК ТА ҮТМИ, СУГА КЕРҮЕННӘН ТӘМЛӘЗЗӘТ ТАПКАН БУ КЕШЕ, ЮЕШ ЧӘЧЛӘРЕН СӨРТӘ-СӨРТӘ, ҖИҢЕЛ АДЫМНАР БЕЛӘН ӨЕНӘ ТАБА ЮНӘЛӘ. АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ ВЛАДИМИР КОНСТАНТИНОВИЧ КОЗОНКОВ ҮЗЕНЕҢ ҺӘР ЭШ ИРТӘСЕН ӘНӘ ШУЛАЙРАК БАШЛАП ҖИБӘРӘ. ИНДЕ КҮП ЕЛЛАР ДӘВАМЫНДА КАМА АНЫҢ КҮҢЕЛЕН КҮТӘРЕП, КӨНЕ БУЕНА ҖИТӘРЛЕК ЯХШЫ КӘЕФ БИРӘ, ДИП САНЫЙ УЛ. ВАКЫТ ҮЗ ЮЛЫННАН АГА – ВЛАДИМИР КОЗОНКОВ ТА 2016 ЕЛНЫҢ 4 ИЮНЕНДӘ 60 ЯШЬЛЕК ЮБИЛЕЕН БИЛГЕЛӘП ҮТТЕ, ОЛЫ УҢЫШЛАРГА ИРЕШКӘН КЕШЕЛӘР УЗГАН ГОМЕРЛӘРЕН ЗУР БАЙЛЫККА ТИҢЛИЛӘР.

**Людмила КАРТАШОВА тексты.**
**Фотолар авторныкы һәм В.К. Козонков архивыннан.**



# *ТУГАН җир тарта*

**ЯШӘГӘННӘР, ДИ, АЛЕКСЕЕВСКИДА**

Бервакыт альбомдагы фоторәсемнәрне карап утырганда, Владимир Константинович таушалып беткән бер фотога тап була. Кызыксынып, әнисе Клавдия Емельяновнадан моның кем сурәте булуы турында сораштыра башлый. Баксаң, бу 1905 елда төшерелгән фотода бабасының әтисе Алексей Гаврилович Козонков үзенең олы улларының берсе белән булып чыга. Аның барлыгы дүрт улы булган: Николай, Федор, Павел һәм Петр. Соңгысы, 1901 елда туганы, Владимир Константиновичның бабасы була.

Козонковларның барысы да Алексеевскида туганнар, монда яшәгәннәр һәм эшләгәннәр. Әнисе ягыннан Денисовлар да Алексеевск районыннан – Гурьевка авылыннан. Клавдия Емельяновна туган гаилә ишле булган, анда ун бала тәрбияләнеп үскән. Ул гомер буе бизәкле туку фабрикасында тукучы булып эшләгән – киндер тукыган. Элек заманнардан бирле эшләп килгән предприятие Алексеевскида хәзер дә бар, бик матур ашъяулыклар, сөлгеләр, эскәтерләр җитештерә. Аның ире, танкист булып хезмәт иткән Константин Петрович Козонков, шул ук фабрикада механик булып эшләгән. Тирә-юньдә юллар булмаганга күрә, ул, районның торак пунктларына почта илтеп, районның элемтә үзәгенеке дип исәпләнгән танкеткада йөри торган булган. Танк белгече Костяга танкетка очраклы бирелмәгән, дип шаярта торган булганнар. Константин Козонков 38 яшендә автоһәлакәткә эләгеп вафат була. Гаиләдәге иң өлкән ир-ат булып Владимир кала, әнисе һәм энесе турында кайгырту аның җилкәсенә төшә.

Козонковлар бистә уртасында урнашкан Калинин урамында яшәгәннәр. Малайлар, өер-өер, иртәдән кичкә кадәр ишегалдында йә атыш уйнаганнар, йә туп типкәннәр, йә яңа велосипедлары һәм мопедлары белән мактанышканнар. Башта алар балалар бакчасына бергә йөргәннәр, аннары бергә мәктәптә укыганнар, соңыннан армия сафларына да бергә киткәннәр. Аларның дуслыклары хәзер дә дәвам итә.

– Без балачакта ни турында хыялландыкмы? Мин үзем, әлбәттә, велосипед турында хыялландым, – дип

**Козонков үзенә бирелгән бүләкләрнең иң кадерлесе дип, «Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» Почет билгесен саный. Аңа ул «Сельхозтехника» директоры булып эшләгәндә лаек була. Моны: «Мин бит авыл башлыгы!» – дип, гади генә аңлата. Иң абруйлысы дип Минтимер Шәрип улы Шәймиев кулыннан алган «Фидакарь хезмәт өчен» медален атый. Бүләкләренең иң үзенчәлеклесе – православиене үстерүгә зур өлеш керткәне өчен бирелгән Святой благоверный князь Даниил Московский ордены.**

көлемсерәп искә ала Владимир Константинович. – Миңа аны алып бирделәр, аннары мопедлы да булдым, соңыннан аны ИЖ-49 мотоциклы алыштырды, соңгысын әтием армиядән кайткач алып бирде. Ул бистәдәге өченче мотоцикл булды. Мин анда әти исән чакта да, ул гүр иясе булгач та йөрдем әле. Үзем армиядән әйләнеп кайткач кына, аны яңага алмаштырдым.

Кеше күп нәрсәне гаиләдә ала. Гаилә аның холкына, гадәтләренә, яшәү принципларына башлангыч бирә. Әгәр гаилә дус һәм көчле икән, андагы мөнәсәбәтләр яхшылыкка, үзара аңлашуга һәм әхлакыйлыкка корыла икән, балалар да, ата-аналарына охшап, көчле шәхесләр булып җитешәләр. Бу – табигать кануны, ә авыл җирендә ул бигрәк тә көчле була.

– Минем әти-әниләрем бик тату яшәделәр, – дип сөйли Владимир Козонков. – Бездә эш ир-атныкына һәм хатын-кызныкына беркайчан да бүленмәде, һәр эш бергәләп эшләнде. Әтием төймәне дә тагып куя, чалбарын да үтүкләп ала иде, энем белән мине дә шуңа өйрәтте. Хуҗалык эшләрендә без кечкенәдән үк теләп катнаша идек. Без бакчаны карау, аны тәртиптә тоту өчен җавап бирдек, икенче зур эшебез – кышка утын хәзерләү иде. Өйгә һәм мунчага ягу өчен гадәттә өч машина утын алып кайта идек. Үлчәп киселгән кебек тип-тигез озынлыктагы усак пүләннәре хәзергә кадәр күз алдымда тора. Усак пүләннәрен яңа гына киселгән чагында ватарга бик җиңел, аларны ватканнан соң утыннар да тигез килеп чыга, без аларны сарай кырыена матур итеп өеп куя идек. Гаиләбездә тагын бер күркәм гадәт бар иде, 7 ноябрьдә дуңгыз чалганнан соң, иттән бергәләп пилмән һәм пәрәмәчләр ясый идек. Монда һәркем үз эше өчен

***– Без балачакта ни турында хыялландыкмы? Мин үзем, әлбәттә, велосипед турында хыялландым, – дип көлемсерәп искә ала Владимир Константинович. – Миңа аны алып бирделәр, аннары мопедлы да булдым, соңыннан аны ИЖ-49 мотоциклы алыштырды, соңгысын әтием армиядән кайткач алып бирде. Ул бистәдәге өченче мотоцикл булды. Мин анда әти исән чакта да, ул гүр иясе булгач та йөрдем әле. Үзем армиядән әйләнеп кайткач кына, аны яңага алмаштырдым.***

җаваплы була. Мин, олы бала буларак, тагаракта махсус балта белән ит чаба идем, әнием камыр җәя, әтием энем белән пилмәннәрне һәм пәрәмәчләрне ясыйлар иде. Әти бөккән пилмәннәр соклангыч матур булырлар иде, күрәмсең, бөтен җылылыгын биреп башкарган ул бу эшне. Пәрәмәчләрне табада кыздыруны да ул бик оста башкара иде. Шул яңа пешеп чыккан кайнар пәрәмәчне эләктереп, кулларны һәм авызны пешерә-пешерә, кыш көне чана шуарга чыгып йөгерү нинди зур бәхет иде бит!

## КҮҢЕЛЕМ СИНДӘ, АВЫЛ, МИН – АВЫЛ ЕГЕТЕ

Унъеллык авыл мәктәбе артта калды, нинди һөнәр сайларга – бернинди икеләнү дә юк. Владимир Козонков әле бала чагында ук хәл итеп куйган була: ул авылдан беркая да китмәячәк, гомерен туган җиренә багышлаячак, әнисе белән энесенә дә терәк булачак. Чистай авыл хуҗалыгы техникумына укырга керә, механика белгечлеген сайлый, ел ярым укып кала – армия сафларына китү яше җитә. Шатлана-шатлана армиягә китә, хезмәттән качып калу уенда да булмый. Ул заманда бит, бу узган гасырның 70нче еллары, егетләр армиягә барырга дип атлыгып торалар, чөнки нәкъ шуннан чын көчле ир-ат булып җитлегеп кайталар иде бит.

– Мин башта Мәскәү янындагы Руза шәһәрендә, сержантлар мәктәбендә хезмәт иттем, аны, өч тулы сержант билгесен алып, бик яхшы билгеләренә генә тәмамладым, – дип искә ала Владимир Константинович. – Аннары мине Карелиягә җибәрделәр, анда һава һөҗүмнәренә каршы гаскәрләрдә старшина буларак хезмәт иттем. Нәкъ шул җирләрдән танылган Маннергейм линиясе – элеккеге фин территориясе узган, финнар белән булган сугыштан соң ул җирләр Советлар Союзына күчкән. Бу урыннарда «А зори здесь тихие» фильмы төшерелгән. Миннән: «Армиядә кыен булдымы?» – дип сорасалар, мин һәрвакытта да: «Юк», – дип җавап бирәм. Без армиягә физик яктан әзерлек узып бара идек бит. Әйтик, мин мәктәптә укыганда чаңгы секциясенә йөрдем, баскетбол уйнадым. Чистайда техникумда укыганда, көрәш секциясендә шөгыльләндем. Бездә ДОСААФ та, спорт түгәрәкләре дә бар иде.

Армия сафларыннан кайтканнан соң, Козонков техникумда укуын тәмамлый, районның авыл хуҗалыгы идарәсендә эшли башлый һәм шул ук вакытта Казан авыл хуҗалыгы институтының агрономия факультетына читтән торып уку бүлегенә керә.

«Сельхозхимия»дә эшләү хезмәт баскычының яңа этабы була. Яшь егетнең эшлеклелеген, тирән белемен, кешеләр белән дөрес аралаша алуын җитәкчелек институтның өченче курсында укыганда ук күреп ала. 27 яшендә аны Алексеевск районының Кызыл Яр авылындагы XXII партсъезд исемендәге колхозга рәис итеп билгеләп куялар. Үзе әйткәнчә, ул чорда аңа эшләве бик кызык булган. Беренчедән, яшьлектә, ару-талуны белмичә, көннәр-төннәр буе эшләргә әзер булган. Икенчедән, аңа шундый зур эшне ышанып тапшырулары белән горурланган ул.

Кызыл Ярдагы хуҗалык һәркайсы авыл җирендәгечә булган: икмәк тә үстергәннәр, эре терлек тә үрчеткәннәр, дуңгыз да асраганнар. Колхоз традицияләргә дә бай булган, шулай итеп, Владимир Козонков үзенең рәислек итү елларында саллы тәҗрибә туплаган.

1985 елда ул Алексеевскига кайта, өч ел дәвамында

***Аннары мине Карелиягә җибәрделәр, анда һава һөҗүмнәренә каршы гаскәрләрдә старшина буларак хезмәт иттем. Нәкъ шул җирләрдән танылган Маннергейм линиясе – элеккеге фин территориясе узган, финнар белән булган сугыштан соң ул җирләр Советлар Союзына күчкән. Бу урыннарда «А зори здесь тихие» фильмы төшерелгән. Миннән: «Армиядә кыен булдымы?» – дип сорасалар, мин һәрвакытта да: «Юк», – дип җавап бирәм. Без армиягә физик яктан әзерлек узып бара идек бит. Әйтик, мин мәктәптә укыганда чаңгы секциясенә йөрдем, баскетбол уйнадым. Чистайда техникумда укыганда, көрәш секциясендә шөгыльләндем. Бездә ДОСААФ та, спорт түгәрәкләре дә бар иде.***



Ел саен уздырыла торган «Алексеевские перезвоны» чаң фестиваленең даны район һәм республика чикләрен узган.

4нче ПМК җитәкчесе була. Бу – авыл җирендә төзелешләр алып баруга өстенлек бирелгән чор. Фермалар, торак, социаль, мәдәният көнкүреш объектлары төзелгән. Районга 1981 елдан башлап 23 ел җитәкчелек иткән Алексеевск районының яшь җитәкчесе Алексей Иванович Демидов төзелешкә зур игътибар бирелүне шулай ук хуплаган.

Демидов белән Козонков арасындагы яшь аермасы зур түгел, холыкларында да, яшәү рәвешләрендә дә уртаклыклар бар, шуңа күрә аларның тиз арада фикердәшләр булып китүләре бер дә гаҗәп түгел.

Алексеевск райком партиясе пленумында Козонковны башта райкомның икенче секретаре итеп (ул авыл хуҗалыгы өчен җаваплы була), аннары беренче секретаре итеп сайлап куялар. Ә истәлекле 1991 елдан соң, үзгәртеп корудан соңгы болгавыр заманда, Владимир Константинович Алексеевскиның «Сельхозтехника» идарәчесе була, монда 12 ел хезмәт куя.

## КЫЙБЛА ҮЗГӘРМИ

Алексей Демидов Казанга республиканың Хисап палатасын җитәкләргә китә, дигән хәбәр бистәдә тиз тарала. Кешеләр моны ишетеп, бик борчылалар – көчле җитәкче урынына кем килер?

Район башлыгы итеп Владимир Козонковны билгеләргә мөмкиннәр икәнен белгәч, халык тынычлана: ни дисәң дә, үз кешебез, кайда туса – шунда кирәк булды, ташламас, элеккечә яшәвебезне дәвам итәрбез, дип уйлыйлар. Алексей Иванович үзенең 23 ел эшләү дәверендә Алексеевск халкы өчен күп нәрсә эшләгән. Ул идарә иткән чорда район тулысынча газлаштырылган, торак пунктлар асфальт юл белән 90 процентка тәэмин ителгән, елгалар һәм чокырлар аша утызлап күпер салынган, клублар, балалар бакчалары, мәктәпләр төзелгән.

– Алексей Ивановичның үз хезмәтен яратып башкаруы мине һәрвакыт сокландырды. Ул тормышның ачысын татып, күп балалы гаиләдә үскән, һәр телем икмәкнең кадерен аңлаган, техниканы яхшы белгән кеше. Гап-гади хезмәтчәнгә карата да гадел мөнәсәбәттә иде. Район башлыгы булып эшләвемнең беренче көнендә үк миндәге җаваплылыкның элеккегә караганда күбрәк булуын аңладым, – дип искә төшерә Козонков.

Яңа башлыкка көчле район җитәкчесе урынына килү, район ирешкән уңышларны саклап калу һәм алга таба үстерү җиңел генә булмый. Әмма ул моны башкарып чыга. Бүген без Алексеевск районының уңышлы үсүе турында сүз алып барганда, аның элеккеге башлыгы Алексей Демидовның гына түгел, ә хәзерге башлыгы Владимир Козонковның да керткән өлешен күз алдында тотабыз.

2008 елда Алексеевск бистәсе үзенең 300 еллыгын билгеләп үтә. Юбилейга Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев та килә. Халык алдында чыгыш ясап, ул Алексеевск районына «ышанычлы район» дип бәя бирә.

– Ягъни без республикага артык кашык түгел. Тулы мәгънәсендә лидер булмасак та, без – ышанычлы, моның белән барысы да әйтелде, – дип тәгаенләде Владимир Козонков.

Алексеевскига килеп-китеп йөргән һәркем бистәдә

***2008 елда Алексеевск бистәсе үзенең 300 еллыгын билгеләп үтә. Юбилейга Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев та килә. Халык алдында чыгыш ясап, ул Алексеевск районына «ышанычлы район» дип бәя бирә. «Ягъни без республикага артык кашык түгел. Тулы мәгънәсендә лидер булмасак та, без – ышанычлы, моның белән барысы да әйтелде», – дип тәгаенләде Владимир Козонков.***




***– Әгәр минем янга килгән кешеләр тегe яки бу структурага кагылышлы сораулар бирмиләр икән, димәк, ул өлкәдә барысы да әйбәт бара, – дип сөйли Владимир Константинович. – Бернечә ел элек без «бер тәрәзә» принципы буенча эшли торган күпфункцияле үзәк ачкан идек. Аның проблемаларны хәл итүдәге ярдәме зур. Кешеләр күп очракта матди ярдәм сорап мөрәҗәгать итәләр, бу аларның хакимияткә ышанычлары барлыгын күрсәтә. Әгәр кешенең проблеманы мөстәкыйль хәл итәргә мөмкинлеге юк икән, ул, ярдәм сорап, администрациягә килә.***

бара торган үзгәрешләрне күрми калмый, хәзерге вакытта 12 мең кеше яши торган район үзәгенең чисталыгына һәм төзеклегенә һәр кеше соклана.

Козонков үзенең командасы белән предприятиеләрне яңарта, һәркайсы, әйтик, «Сельхозхимия» дә, мелиораторлар – «РАФ» ҖЧҖ дә, Алексеевск юл төзүчеләре дә («Алексеевскдорстрой» ААҖ – республиканың иң куәтле предприятиеләренең берсе), яңа технологияләрне кертә һәм үсә бара торган кирпеч заводы да, төзелеш оешмалары да, узган елда эш нәтиҗәләре буенча республикада тиңнәр табылмаган кулланучылар кооперациясе дә, борынгы бизәкле туку фабрикасы да яхшы гына эшләп килә.

Бистә күзгә күренеп үсә, чөнки монда һәрвакытта да эш урыннары бар, хезмәт хаклары вакытында түләнә, инфраструктура төзелә һәм, иң мөһиме, туасы көнгә ышаныч бар. Соңгы биш елда Алексеевскида ветераннар бистәсе үсеп чыкты, ипотека буенча торак төзелеп, 12 күпфатирлы йортны үз эченә алган яңа микрорайон барлыкка килде. 220 һәм 60 урынлык ике яңа балалар бакчасы ачылды. Кайчандыр Алексеевск халкын торак-коммуналь хуҗалык өлкәсенә караган проблема – җылылык өчен түләү бәяләренең югары булуы борчып килде. Бу мәсьәлә барлык торакны ике контурлы казаннарга күчерү юлы белән хәл ителде, хәзерге вакытта Алексеевскида котельнялар да, җылылык трассалары да юк, һәркем үз фатирындагы җылылыкны үзе көйли һәм акчаны да җылылыкны күпме ягуына карап түли.

– Әгәр минем янга килгән кешеләр тегe яки бу структурага кагылышлы сораулар бирмиләр икән, димәк, ул өлкәдә барысы да әйбәт бара, – дип сөйли Владимир Константинович. – Бернечә ел элек без «бер тәрәзә» принципы буенча эшли торган күпфункцияле үзәк ачкан идек. Аның проблемаларны хәл итүдәге ярдәме зур. Кешеләр күп очракта матди ярдәм сорап мөрәҗәгать итәләр, бу аларның хакимияткә ышанычлары барлыгын күрсәтә. Әгәр кешенең проблеманы мөстәкыйль хәл итәргә мөмкинлеге юк икән, ул, ярдәм сорап, администрациягә килә. Мондый ышаныч безгә бик кадерле, авыр тормыш хәлләренә юлыкканнарга мөмкин булган кадәр ярдәм күрсәтәбез.

## АҢЛАП ЭШЛӘСӘҢ, БАШЛЫК БУЛУ ҖИҢЕЛ

Быелгы ел Алексеевск районы өчен истәлекле булды – монда яңа инвестор – Мари Элдан «Звениговское» халык предприятиесе килде. 18 мартта районда «Алексеевское» халык предприятиесе төзелде, бу – 6,5 мең баш мөгезле эре терлек, 1000 пайчы, 22 мең га җир (барлык район территориясенең 30 проценты) дигән сүз ул.

– Без авыл хуҗалыгы эшләрендә алга китеш булыр дип өметләнәбез, – дип планнары белән уртаклашты Владимир Константинович. – Бездә кара туфрак бит. Районда 110 фермер хуҗалыгы эшли, гаилә фермалары үсә. Планнарыбыз исә республика планнарыннан бернәрсәсе белән дә аерылмый. Әйтик, шул ук мәктәпләрне, балалар бакчаларын төзекләндерү, ФАПлар төзү һәм башкалар. Ә авыл җирлекләренә ярдәм өчен күпме грант алабыз без бүген! Әгәр моннан 5–10 ел элек авыл җирлекләре җитәкчеләрен «тәгәрмәчкә» ничек утыртыйк икән дип баш ваткан булсак, бүген әлеге мәсьәлә хәл ителде – республика муниципаллары ТР Президентыннан 1200дән артык машина алды. Шулай итеп, бернәрсә дә уйлап табасы юк, бары тик республика кабул иткән карарларны гына үтәргә кирәк. Һәм барысы да әйбәт булачак!

Козонковтан, район башлыгы булу авырмы, дип сорасалар, ул елмаеп җавап бирә: халык алдында җаваплы булуы гына авыр, әгәр син монда туып-үскән булсаң, мондый җаваплылык тагын да зуррак. Әгәр дә син эшеңне аңлап башкарсаң, тылың ышанычлы булса – җиңел.

Алексеевск районы башлыгында боларның барсы да бар. Аның хатыны – терәге, ике олы кызы бар, өч оныгы үсеп килә.

– Табигатьне яратам мин. Бездә киңлеге 18 километр булган Кама ага, аның су акваториясе гаҗәп матур. Урманнары, киң кырлары – үзе бер хозурлык, икмәкнең мул үсүен күреп сөенәсең.

Райондашларыгызга нинди теләкләр теләр идегез, дигән соравыма ул аерым бер җылылык белән болай дип җавап бирде: «Мин теләк урынына Алексеевск халкына тырыш хезмәтләре өчен рәхмәтемне белдерәм».

# САБАНТУЙ-2016














Фото: www.tatarstan.ru сайтыннан һәм Андрея Титовтан алынды.



Май аеның соңгы шимбәсендә Казанда халкыбызның милли бәйрәме – Сабантуй булып узды. Ул күптән инде Татарстанны таныта торган брендларның берсенә әверелде. Бүген бу бик күңелле һәм төрле төсләр белән балкый торган бәйрәм Россиянең 57 төбәгендә һәм дөньяның 27 илендә үткәрелә.

Быел Сабантуй өчен төп мәйдан – Каенлык булды. Анда концерт сәхнәләре, республика районнарыннан килгән декорацияләрдән авыллар корылган иде, Сабантуй кунаклары төп сәхнәдән күңелле концерт тамаша кылды.

Бәйрәмнең мактаулы кунаклары төрле ислам дәүләтләреннән Казанга «Россия – Ислам дөньясы» Стратегик күзаллау төркемендә катнашырга килгән делегатлар булды. Кунакларны милли ризык – чәкчәк һәм ипи-тоз белән каршы алдылар.

Ә күпсанлы мәйданчыкларда һәм спорт ареналарында башкала кунаклары һәм анда яшәүчеләр Сабантуйның традицион ярышларында көч сынашты – капчык киеп, кашыкка йомырка салып йөгерде, капчык сугышында катнашты, баганага менде һ.б. Һөнәр осталары милли көрәштә аерым көч сынашты. Шат йөзләр, көлү авазлары, шаян такмаклар, дәртле биюләр, урман һәм үлән катыш күчтәнәч исләре – боларның барысы да чагыштыргысыз атмосфера, кабатланмас бәйрәм рухы тудырды. Шуңа күрә әлеге бәйрәмне өлкәннәр дә ярата, яшьләр дә үз итә, Татарстанда яшәүче барлык халыклар өчен уртак бәйрәмгә әйләнгән Сабантуйны анда беренче тапкыр катнашкан кунаклар да истә калдырачак.



Людмила КАРТАШОВА тексты.
Фотолар автордан һәм ТР Экология һәм табигый байлыклар министрлыгыннан алынды.

# ЯРЛАРНЫ югалтмыйк

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Сулыкларны саклау елы дип игълан ителгән 2016 ел үзенең «экваторына» якынлаша. Язын Казанда муниципаль районнар, министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре, һөнәри җәмгыятьләр вәкилләре өчен уку-укыту семинары оештырылды, анда республика җитәкчесе дә катнашты. Чарада иҗтимагый киңлекләрен төзү буенча проектларны әзерләү һәм гамәлгә ашыруга максималь рәвештә халыкны җәлеп итүгә аерым басым ясалырга тиешлеге билгеләп үтелде. «Без башкарган гамәлләр халык мәнфәгатьләре өчен кулланылмаса, барысы да бушка булачак», – дип ассызыклады ТР Президенты.


Апрель ахырында РФ Табигать ресурслары һәм экология министрлыгы каршындагы Федераль экология советы сессиясе Россия төбәкләренең «яшел» проектларына багышланган иде. Утырышта катнашучылар каршында ТР экология һәм табигый ресурслар министры Фәрит Әбделганиев чыгыш ясады – ул Сулыкларны саклау елында бездә уздырыла торган чаралар турында сөйләде. Аның сүзләренә караганда, су объектлары буйлап рекреация зоналары төзүне финанслау максатына республика бюджетыннан ике миллиард сум акча бүленгән.

Татарстанда сулыкларны саклауга кагылышлы законнарны бозуны кисәтү, ачыклау һәм киртә кую буенча эш көчәйтелде, дип белдерде ведомство башлыгы. Су объектларына каршылыксыз үтеп керә алуны тәэмин итү буенча уңай суд тәҗрибәсе тупланган. Шул ук вакытта хокук бозучыларның 80%ы әлеге киртәләрне үз ихтыярлары белән сүтәләр. Республикада стационар чыганакларны ташланган калдыкларның санын һәм күләмен автомат рәвештә даими тикшереп тору приборлары белән җиһазлау киң колачта алып барыла. Агымдагы ел казанышлары арасында министр түбәндәге фактны аерып күрсәтте: республика масштабларында ягулык салу станцияләрендә судно моторы маен сатуны тулысынча тыюга ирешелде. Нәрсәләр эшлисе бар әле? «2016 һәм 2017 елларда без су саклау зоналарын комплекслы рәвештә тикшерергә, гамәлдәге чистарту корылмалары һәм калдыкларны җыю объектлары торышына бәя бирергә ниятлибез, – диде Фәрит Әбделганиев. – Шулай ук 2017 елда Татарстанда җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүнең территориаль схемасы кертеләчәк, төбәк операторлары эшкә керешәчәк».

## ТАБИГАТЬ САКЧЫЛАРЫНЫҢ ЭШ КӨНЕ

...Бу көннәрдә Федераль су ресурслары агентлыгының Түбән Идел су бассейны идарәсе җитәкчесе урынбасары – ТР буенча су ресурслары бүлеге башлыгы Артем Филипповның телефоны тынып тормый. Бирегә бөтен республикадан су объектларының торышы һәм ихтимал булган гадәттән тыш хәлләр турында мәгълүмат агыла.

Бүлекнең төп функцияләренең берсе – Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларында су саклау зона-





Куйбышев сусаклагычы яр буйларындагы корылмалар.



рын билгеләү. Республиканың башка су объектлары буенча әлеге вәкаләтләр ТР Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына тапшырылган. Кызганычка каршы, әлегә су саклау зоналары каралмаган сулык төркемнәре дә бар – бу мәйданы 0,5 кв. км дан ким булган сазлыклар һәм күлләр.

«Су саклау зоналарын билгеләү өчен, таяк кадап, тиешле сүзләр язылган язу элеп кую гына аз. Процесс катлаулы: башта проект эшләнә, аннан соң ул Мәскәүдә яклана, чөнки эш өчен финанслар федераль бюджеттан алына. Соңгы ике-өч елда республикада бу юнәлештә зур эш алып барылды, шуның нәтиҗәсендә күп елгалар су саклау зоналарына ия булдылар. Мәсәлән, авыл җирлеге буенча ага, дистәләгән кушылдыгы булган Мишә, Дала Зәе кебек эре су артерияләре. Су саклау зоналарында терлекләрне көтү, агулы химикатлар, органик һәм минераль ашламалар складларын урнаштыру тыела, сөрүлекләр дә булмаска тиеш. Әйтик, Идел елгасы, яисә Куйбышев сусаклагычы, 200 метрлы су саклау зонасына ия булса да, күпме бакча кишәрлеге урнашкан биредә! Займище, Боровое Матюшиноны алыйк – тарихи яктан шулай килеп чыккан ки, кешеләр елга буена урнашканнар, шәхси ярдәмче хуҗалыкларын булдырганнар. Ләкин шул ук вакытта су саклау зонасында җир эшкәртү закон буенча тыелган. Нишләргә? Сорау катлаулы, санкцияләрне бөтен халыкка карата кулланып булмый бит», – дип сөйли Артем Филиппов.

Сүз уңаеннан, закон су саклау зоналарын билгеләгәндә дәүләт органнары аларны кадастр исәбенә куярга, карталарын, схемаларын төзергә тиеш. Аерым формадагы билгеләр халык күрә торган урыннарга куела, һәр сулык өчен индивидуаль чикләр билгелә. Әлеге җаваплы эшне геодезистлар башкара. 2007 елда Россиядә яңа Су кодексын кабул иткәнчегә кадәр су саклау зонасында нинди дә булса төзелеш (йортлар, хуҗалык объектлары) алып бару тыела иде. Хәзерге вакытта бу аның кадәр катгый түгел, гәрчә йорт төзү өчен кишәрлек бүлеп биргәндә, кадастр паспортына әлеге территориянең су саклау зонасына керүе һәм кайбер чикләүләр гамәлдә булуы мәҗбүри рәвештә күрсәтелсә дә.

Табигатьне саклау инспекторларына зур суга чыгарга гына кирәк: шундук хокук бозуларга юлыгалар – су акваториясен күмүдән алып, территорияне көнкүреш чүпчарлары белән пычратуга кадәр, машиналарны су объектына кертеп юудан алып, яр буе зонасында законсыз корылмалар төзүгә кадәр. Рейдлар вакытында районара табигать саклау прокуратуралары (Казан һәм Татарстан) вәкилләре экологлар белән тыгыз элемтәдә эшли. Алар хосусыйлаштыру һәм халыкның үтеп керүенә каршылык тудыру тыелган, гомуми кулланышта булырга тиешле 20 метр киңлектәге яр буен законсыз рәвештә биләп алу фактларын ачыклыйлар. Аннан соң суд тикшерүләре башлана – кайчак берүк вакытта 10–15әр эш карала. Мәсәлән, Яшел Үзән районында кишәрлекләрнең берсе өлешчә күл территориясен били, Мишә елгасында коттедж бистәләре елга яры буйлап салынган, Тукай районының Белоус авылында, 20 метрлы зонаны биләп, су фондын җир белән күмү фактлары (бу исә катгый рәвештә тыела) ачыкланды. Гомумән, гражданнарның суга якын килә алуы – авыр тема. Әгәр яр буе зонасын тоташ корылмалар каплап алган булсалар нишләргә? Димәк, аларны сүтәргәме? Ләкин аларның хуҗалары каршылык күрсәтә…

Артем Филиппов үз тәҗрибәсендә суд карарыннан соң яр буе зонасындагы нинди дә булса капиталь корылмаларның сүтелү очрагын хәтерли алмавын таныды.

– Коймаларны, ниндидер сарайларны сүтү очраклары булды, ә менә йортларны – юк, – дип сөйләде ул. –

Суд карарлары күп булса да, кызганычка каршы, алар үтәлмиләр. Бәлки, суд приставлары эшләп җиткермидер, мөгаен, законда да җитешсезлекләр табыладыр. Мәсәлән, суд яр буе зонасындагы корылманы милек иясенә үз көченә таянып юкка чыгаруны йөкли. Тегесе, әлбәттә, моны үтәмәс өчен тау кадәр сәбәп таба: үзенең мөмкинлекләре булмавын күрсәтә, төрле язулар язу белән генә шөгыльләнә. Шулай итеп йөк һаман бер урында торуын дәвам итә.

**ФАКТЛАР ГЫНА**

**Түбән Кама районындагы Соболеково күленең яр буйларын тикшергәннән соң, ТР Экология министрлыгының Кама аръягы территориаль идарәсе инспекторлары РФ Административ хокук бозу кодексының 8.12 маддәсе буенча дүрт беркетмә төзеделәр. Якын-тирәдәге кишәрлекләр хуҗалары су объектына керү мөмкинлеген законсыз корылмалар белән каплап алганнар, 20дән артык очрак теркәлгән.**

**Чистай районында Просто елгасына мониторинг үткәрелгән. Четырчы авыл җирлегендә дә хокук бозулар табылган – гомуми куллanyштагы яр буе полосасы киртәләп алынган, кишәрлектә төзелгән мунча судан 6 метр ераклыкта тора. Олы Талкыш авыл җирлегенә караган җир кишәрлегендә гражданнар Просто елгасына ирекле үтә алмый – бер кишәрлекнең хуҗасы яр буе линиясен киртәләп алган. Административ беркетмәләр төзелгән, законсыз корылмаларны юкка чыгару турында боерык чыгарылган.**

**Лаеш районында Архирей күле һәм Мишә елгасының яр буе полосаларын законсыз рәвештә биләүгә караган 30дан артык факт ачыкланган. Капиталь төзелеш объектлары – беседкалар, коймалар, яр ныгыту корылмалары – су саклау зонасында ук урнашкан. Шул ук вакытта РФ Су кодексының 6 маддәсенә ярашлы рәвештә, су объектының 20 метр киңлектәге яр буе полосасы гомуми куллану өчен билгеләнгән.**

Су саклау зоналары юкка гына яклауны таләп итми – яшерен-батырын түгел, безнең сулыкларның күбесенең торышы белән мактанып булмый. Казансуны алыйк: аның үрге агымында, Арча районында, елга башланган урында суның сыйфатын чиста дип әйтергә була, ә инде Казанда Иделгә койган җирендә эш шуңа килеп җитә ки, санитар табиблар анда тотылган балыкны ашарга да кушмыйлар.

Су объектларының чисталыгы еш кына халыкның үз-үзен тотышына, аның экологик яктан мәгълүматлы булуына, сулыкларга пычрак агынтыларны агызу белән шөгыльләнгән предприятие җитәкчеләренә бәйле. Кешеләр суга ни генә ыргытмый: гап-гади пакет һәм пластик савытлардан башлап, диван һәм башка җиһазларга, металл, машина әйберләренә кадәр. Сүз дә юк, халык белән эшләргә, агартырга, аңлатырга, кече яшьтән үк табигатькә сакчыл караш, мәхәббәт



Республикада сулык яр буйларын тәртипкә китерү буенча һәртөрле акцияләр үткәрү гадәти күренешкә әйләнде.

тәрбияләргә кирәк. Шуңа күрә республикада сулык яр буйларын тәртипкә китерү буенча һәртөрле акцияләр үткәрү гадәти күренешкә әйләнде. Мәсәлән, май бәйрәмнәре алдыннан энтузиастлар Түбән Камада Кама елгасы ярында булачак экопарк территориясен төзекләндерделәр. 16 кубометрга якын көнкүреш һәм төзелеш чүп-чары җыелды. Бу яктан Казан да калышмый, биредә яр буе зоналарын чүп-чардан чистарту буенча чаралар системалы рәвештә үткәрелә. Апрель ахырында, әйтик, Аккош һәм Тирән күлләр ярларын чистарту буенча киң күләмле эш башкарылды.

Су объектларын терлекчелек калдыклары белән пычрату бик зур проблема булып тора. Су саклау зонасында терлек көтү очраклы рәвештә генә тыелмаган, һәм терлекчелек, һәм продукция эшкәртү белән шөгыльләнүчеләрне чистарту корылмаларын төзергә мәҗбүр итәргә кирәк. Әйе, бу арзан түгел, ләкин табигатькә китерелгән зыян тагын да кыйммәтрәккә төшә.

Тагын бер проблема – гидротехник корылмалар (дамбалар, буалар, чыгару корылмалары, торбалар, коллекторлар) торышының канәгатьләнерлек булмавы. Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары ел саен гидротехник корылмалар буенча хисап тотарга тиеш. Кызганычка, Татарстанда бер генә район да йөз процентка бу бурычны үтәми. Ул катлаулы да түгел кебек, ләкин нигәдер буалар турында мәгълүмат урынына инешләр, чишмәләр турындагысы килә – ни генә булмасын, барыбер гидротехник корылмалар турында түгел. Урыннарда нәрсәнең нәрсә булуын бигүк аңлап бетермиләр кебек тоела.

Муниципаллар үз территорияләрендә сулыкларга үтеп керә алуны контрольдә тотарга тиеш. Нәкъ менә урыннарда кайда җирне бүлеп бирергә мөмкин, кайда юк икәнлеген беләләр, әлеге мәсьәлә буенча тулы мәгълүматка ия булалар. Кадастр инженерына зур җаваплылык йөкләнә, ул, кагыйдә буларак, лицензиягә ия шәхси зат. Нәкъ менә кадастр инженеры кишәрлек



«Сусаклагыч ярында парк төзүгә инде 20 миллион сум кертелде», – дип сөйли Анатолий Абакумов.



Хәзерге вакытта Алексеевскида 8 Март күле (күл шул исемдәге урамда урнашкан) буйлары төзекләндерелә.

чикләрен ызанлый, һәм аңардан закон таләпләрен үтәү сорала – кишәрлекнең чиге су яныннан 20 метрдан ким узмаска тиеш. Кызганычка, әлеге кагыйдә еш кына бозыла.

Сулыкларны саклау елы кысаларында яр буйларын төзүгә мөһим роль бирелә – һәм алар республиканың күп кенә торак пунктларында инде барлыкка килде. Мамадышта, Лаешта, Балык Бистәсендә бик матур яр буйлары пәйда булды. Хәер, ниһаять, Казан да күркәм генә яр буена тиенде, инде яр буйлап рәхәтләнеп ял итеп йөрергә дә була.

Республикада су саклау зоналары тәртиптә тота һәм даими рәвештә төзекләндерелә торган үрнәк алырлык территорияләр бармы соң? Күптән түгел генә әлеге юллар авторына Куйбышев сусаклагычы ярларында урнашкан Алексеевск районы үзәгендә булырга туры килде. Бирегә су объектының киңлеге 18 километрны тәшкил итә! Шуңа да диңгездәй киң елга манзарасы белән хозурланырга нәкъ менә бирегә киләләр. Өстәвенә, сусаклагыч ярында тулы бер мәдәни шәһәрчек – Юлчылар паркы үсеп чыкты.

Су акваториясен күмү – еш күзәтелә торган хокук бозу.



Анатолий Абакумов, Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары:

– Мәйданы дүрт гектардан артык булган әлеге паркны нигездә «Алексеевскдорстрой» төзеде, шуңа күрә ул «Юлчы» дип атала да. Монда хоккей тартмасы бар, янәшәдә балалар өчен шугалак булачак, волейбол һәм баскетбол мәйданчыклары төзекләндерелде, велосипед юллары, балалар өчен таган-карусельләр урнаштырылды. Периметр буйлап меңгә якын агач утыртылды: миләш, юкә, каен. Сусаклагыч ярында парк төзүгә инде 20 миллион сум кертелде – акчалар республика һәм муниципаль бюджетлардан бүленде, күп өлеше «Алексеевскдорстройга» туры килә. Агымдагы елда бюджеттан паркка тагын 8,5 млн сум салырга ниятлибез, шулкадәр үк сумманы инвестор да бирергә вәгъдә итә. Сез бәлки ышанмассыз да, әмма узган җәйдә генә дә биредә әле бернәрсә дә юк иде, ә хәзер тормыш гөрли. Кызганычка, биредә су коенырга ярамый – сусаклагычтагы суның сыйфаты мактанырлык түгел. Без бүген Алексеевскидагы тагын бер сулык – 8 Март күлен (күл шул исемдәге урамда урнашкан) матурлыйбыз. Бу күл безнең бистәдә күптәнге санала, элек бөтен агынтылар да күлгә агызыла иде. 15 еллап элек без күл ярларын ныгыттык, быел парк зонасы ясарга уйлыйбыз. Монда фонтан да, эскәмияләр дә, яктылык та булыр, дип ниятлибез. Быелның язында күлне чистарттык, шуңа күрә су чиста, коеныр өчен яраклы.

**Быелгы ел программасына түбәндәге принциплар салынган: яр ныгытуның бетон конструкцияләрдән читләшергә мөмкинлек бирүче гидрологик концепциясен киң куллану; табигать каркасларын максималь куллану; «тере елга», «тере ландшафт» һәм «яшел каркас» принципларын гамәлгә ашыру.**



Лилия НУРМӨХӘММӘТОВА тексты.
Фотолар автордан алынды.

# БӨРБАШ аксакаллары

«БӨРБАШТАГЫ КЕБЕК ХОККЕЙ МӘЙДАНЧЫГЫ РАЙОНДА ЮК», «ЗАМАНЧА ТӨЗЕЛГӘН МӘКТӘБЕБЕЗ ҮЗЕ ГЕНӘ ДӘ НИ ТОРА», «БЕЗДӘГЕ ЧИШМӘЛӘРНЕ КАРАРГА ДИП ӘЛЛӘ КАЙЛАРДАН КИЛӘЛӘР». ӘЛЕГЕ СҮЗЛӘРНЕ БӨРБАШЛЫЛАР ГОРУРЛАНЫП ТА, СӨЕНЕП ТӘ ӘЙТӘ. БУ ЮККА ТҮГЕЛ, ЧӨНКИ СОҢГЫ ЕЛЛАРДА БАЛТАЧ РАЙОНЫНЫҢ БӨРБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНДӘ ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ ЭШЛӘРЕ ШАКТЫЙ БУЛГАН. ӘЛЕГЕ ЭШЛӘРНЕҢ БАШЫНДА АВЫЛ МУЛЛАСЫ ҖӘЛИЛ ХӘЗРӘТ ФАЗЛЫЕВ БЕЛӘН ҖИРЛЕК БАШЛЫГЫ СӘЙДӘШ ХӘКИМОВ ТОРУЫН БЕЛГӘЧ, ҮЗЕБЕЗГӘ ДӘ КЫЗЫК БУЛЫП КИТТЕ.

## МОНДЫЙ ХӘЗРӘТЕҢ БУЛСА

Бу хәлләр ничек башланганмы? Заманында Бөрбаш сазлыклы урамнары белән районда дан казанган була. Аз гына яңгыр яуса да, аяктан резин итек төшми иде, дип искә ала бүген авыл халкы. Гомер яхшырмас, дип уйлаган урамнарына моннан ун еллар элек асфальт салына башлаган. Ничекме? Исемнәре районга билгеле ике җитәкче Сәйдәш Хәкимов белән Хәмит Кәримуллин берничә урамны булса да тәртипкә китерү нияте белән төрле оешмаларның ишекләрен шакый башлый. Документлар да әзер, вәгъдәләр дә бар, әмма гел сузып киләләр. Авыл мулласы Җәлил хәзрәт Фазлыев белән киңәшләшергә булалар. Ул исә билгеле шәхес, республиканың баш казые, шактый гына җитәкчеләрне белә. Юл министры Владимир Швецовның кызына никах укырга да барганы бар. Фикерләшәләр дә, тәвәккәлләп, министрның ишеген шакыйлар. Сүзләрен аяк астына таптамый Владимир Александрович: бер урамга асфальт җәелә, икенчесенә таш түшәлә. Авыл халкында өмет уяна. Менә шуннан соң авыл җирлеге башлыгына кулдан килгән кадәр ярдәм итәргә кирәк, дигән уй туа хәзрәттә. Җәлил хәзрәт 2009 елда Минтимер Шәймиевтән башка урамнарны тәртипкә китерүдә ярдәм итүен сорый. «Киләсе елга булыр», – дигән җылы сүз ишетә. Тик Минтимер Шәрипович вазыйфасыннан киткәч, бөрбашлыларга «акча юк» дигән коры җавап килә. Инде нишләргә? Бәхеткә, икенче Президент Рөстәм Миңнеханов хәзрәтне кабул итә. Форсаттан файдаланып, беренче Президент белән булган сөйләшүне җиткерә. Вәгъдә – иман, диләр. Авылда заманча дүрт күпер төзелә, урамнарга 2 чакрымнан артык асфальт, шулкадәр үк күләмдә таш түшәлә. Ниһаять, халык резин итекнең ни икәнлеген оныта.

Юллы булгач, мәктәпле буласы килә башлый. Ник дисәң, 1960нчы еллар уртасында ук төзелгән урта мәктәп бинасы бер дә мактанырлык түгел. Хәзрәт үзе дә шул бинада белем алган кеше. Юл сорап кергән вакытта ук Президентка мәктәпнең авария хәлендә булуын әйтә. Мәктәп артыннан йөри башлаган елда, үч



Бөрбаш авыл җирлеге башлыгы Сәйдәш Хәкимов.



Бөрбаш аксакаллары. Уңнан беренче – Җәлил хәзрәт Фазлыев.

иткәндәй, Бөрбашта нибары 3 бала укырга керәсе, Сәрдегәндә берәү дә булмаган ел туры килә. «Мәктәп җимерелә, балалар начар шартларда укыйлар», – дип, югары даирәләр ишеген шакый торгач, ниһаять, хәзрәтнең сүзен ишетәләр, ике катлы бина калкып чыга. 2012 елның декабрендә яңа мәктәп ачыла. Моның өчен дәүләттән 78 миллион сум акча бирелә.

– Иске мәктәп белән яңасын чагыштыра торган түгел инде, – ди укыту буенча директор урынбасары Әнисә Гобәйдуллина. – Шәһәр мәктәпләрендә дә бездәге кебек уңайлыклар юк. Һәр фән өчен заманча сыйныфлар. Балалар бакчасыннан килгән укучылар мәктәпкә тизрәк ияләнсен өчен йокы, уен, уку бүлмәсенә кадәр эшләнде.

ТР Президентының Рәхмәт хаты.



Балалар бакчасы дигәннән, анысы да 1970нче еллар ахырында ук төзелгән, яңартырга кирәк. Максатына ирешә хәзрәт, бакчаны танымаслык итеп үзгәртә. Бүген сабыйлар яңартылган бакчага йөри.

Авыл уртасындагы хоккей мәйданчыгы да хәзрәт аркасында барлыкка килгән. Яктырткычлары гына да 500 мең сумга төшкән. Хәзер мәктәп балалары гына түгел, авыл яшьләре, өлкәннәре кыш көннәрендә биредән кайтып керми. Җанатарлар мәйданчыкны карап, чистартып тора. Авыл командасы егетләре өчен махсус киемнәр дә тектергәннәр.

## БЕЗДӘ ҺӘРКЕМ ӨЛЕШ КЕРТӘ

Бөрбаштагы чишмәләр, коелар да курчак өен хәтерләтә. Җәлил хәзрәт үзе артыннан авылдашларын да иярткән. Җирлек башлыгы Сәйдәш Хәкимов белдергәнчә, авылдан чыккан һәр хәлле кеше төзекләндерүгә үзеннән өлеш кертергә тырыша. Нинди генә эшкә тотынсалар да, иганәчеләр «Бөрбаш» җәмгыяте ярдәменә таяналар. «Җәлил хәзрәтнең танышлары авылга шактый ярдәм кулы суза», – ди Сәйдәш Шәмсемөхәммәт улы. Үзара салым программасы кергәннән соң, эшләре тагын да зуррак колач алган. Күрше җирлекләр 200 сум дип килешенгәндә, алар 400 сумнан җыярга булган. Бу акчаларга зиратларны тәртипкә китергәннәр, урамнарга юллар түшәлгән, чишмәләр каралган. «Зиратларны төзекләндерү, чистарту эшләре үзара салым программасы кергәнче үк башланган иде, – ди Әхияр Нурмиев. – Ел саен майның бер көнендә без зиратта өмә үткәрәбез. Боларның барысы да Җәлил хәзрәт аркасында. Бездән күреп бу эш башка авылларда да барлыкка килде, хәзер аны дәвам гына итәбез».

Игътибарны бер Бөрбашка гына бирәләрдер дип уйламагыз, җирлеккә кергән Сәрдегәндә дә, Аланда да төзекләндерү эшләре бара. Бу авыллардан чыгучылар да бөрбашлыларның матур үрнәгенә кушылган. Авыл-

ларга булышучы егетләр турында Сәйдәш абый горурланып сөйләде.

– Авылларның проблемасы бетә торган түгел, – ди ул. – Бөрбаш белән Сәрдегәндә юлларны карап бетерсәк тә, Аланда берничә урам бар әле. Төрле программаларда, конкурсларда катнашып, проблемаларны хәл итәргә тырышабыз. Янгынга каршы гидрантлар куйдырасыбыз бар. Өченче ел Аланда булган фаҗига күпләрне тетрәндерде. Җиде йорт янгыннан зыян күрде, бернәрсәсез калучылар булды. Җирлек халкыннан гына да ярдәм йөзеннән 800 мең сумнан артык акча җыелды. Шөкер, төрле программалар белән барысы да йорт-җирле булды. Узган ел Шеңшеңәр авылында яшен сугып дүрт йорт янган иде, өч көн эчендә 103 мең сум акчаны зыян күрүчеләргә тапшырдык. Дин көчле булган җирлек буларак, кеше хәленә керү дигән нәрсә бар бездә.

## БАЛАЧАКТАН СЕҢДЕРГӘЧ

Ә бирердә дин кече яшьтән салына. Җәлил хәзрәт теле ачылып кына килүче балаларны ясле-бакчадан ук мулла бабай белән таныштыра башлый. Тәм-томнарын кыстырып, гает көннәрендә балалар янына бакчага ашыга. «Күчтәнәчләр алып килүче кыш бабайны белгән кебек, мулла бабайның да кем булуын белеп үсәргә тиешләр», – ди хәзрәт. Беренче сыйныфка баручыларны да онытмый. Әти яки әнисен югалткан балаларга да, инвалидларга да ел саен бүләк ясый. Армиядә булган егетләр туганнары белән аралашып торсын өчен, телефоннарына акча салуны да гадәткә керткән. Районда беренчеләрдән булып төзелгән мәчеттә үтә торган авыз ачтырулар, корбан ашлары, мәүлет бәйрәме, тәрәвих намазларын авыл халкы гадәти хәл итеп кенә саный.

– Җәлил хәзрәт Бөрбаш авылының изге бер кешесе. Аңа дин, мәчеткә йөрүче бабайлар белән балалар гына түгел, мәктәп, балалар бакчасы, авыл тормышы, бөтен бәйрәмнәре якын. Ул авылыбызның дәү әтисе, – ди мәктәп директоры Гүзәл Бариева.

## САБАНТУЙ МӘЙДАНЫ

Бөрбаш – батыр көрәшчеләр биргән авыл да. Фидаил Шакиров, Рифкать Хөсәенов, Миңнегали Шакиров, Сәлим Әхмәтҗанов һәм башка исемнәр заманында бөтен республикага билгеле иде. Тик соңгы елларда билбирмәс егетләре белән мактана алмады Бөрбаш. Бу хәл җирлек башлыгын гына түгел, хәзрәтне дә нык борчуга салган. Бергәләп киңәшләшәләр дә, егетләргә заманча шөгыльләнерлек урын булдыралар. Иң гаҗәпләндергәне: Җәлил хәзрәт тренерга хезмәт хакын берара үзе түләп торган.

Проблемасыз авыл дип уйлый күрмәгез. Булган кыенлыктан чыга белә алар. Ничә еллардан бирле бөтен кешенең дә күңеленә хуш килә торган Сабантуй мәйданын таба алмый интегәләр. Урман буенда да, авыл читендә дә уздырып карыйлар. Су буенда, чишмә янәшәсендә авыл халкы сыярлык мәйдан ясаганнан соң гына проблема чишелә. Әмма озакка түгел. Җәлил хәзрәт Бөрбашта мөселман балалары арасында Сабан туе уздырыла башлый. Әлеге бәйрәмгә чит өлкәләрдән, автобусларга төялеп, халык агыла башлагач, мәйданның кечкенә булуы ачыклана. Читтән килгән 10 меңләп кешене сыйдырыр өчен урын кирәк була. Җәлил хәзрәт тагын ишекләр шакый башлый, иганәчеләрдән акча җыя, ярдәм итүләрен сорый. Үзара салым акчасының да бер өлеше бу җирне төзекләндерүгә китә. Нәтиҗәдә, әлеге урын әкияти сихри көчкә ия булырлык матур бер мәйданга әверелә. «Сабантуй мәйданында җир астыннан утларга кадәр үткәрелгән», – ди Сәйдәш абый.




Балалар өчен мөселман Сабан туе бик матур һәм үзенчәлекле үтә.

Ә мөселман балалары Сабан туе чыннан да бик матур, үзенчәлекле үтә. Ярышларда катнашучыларны бүләкләр өчен, ел саен 400–500 мең сумлык әйберләр алына. Иң кызыгы шунда: бу бәйрәм дәүләт акчасына үткәрелми, Җәлил хәзрәт хәлле кешеләрне әлеге игелекле эшкә җәлеп итә. «Сабантуйга бер тапкыр акча биргән эшмәкәр, икенче елда кабат өлешен кертә. Үз акчасына яхшы бүләк алынуын кунакка килгәч күреп, белеп китә ул», – ди Гүзәл Бариевна. Быел да

Авыл халкы резина итекләрнең барлыгын онытa башлады.







«Безнең чишмәләрне күрергә ераклардан ук килмәләр», – дип, горурланып сөйлиләр Бөрбаш авылында.




2012 елда яңа ике катлы мәктәп сафка баса, ул үз ишекләрен шул ук елның декабрендә ача.

әлеге күркәм гадәтне дәвам итмәкчеләр. Бөтенроссия мөселман Сабан туе, уразадан соң, 17 июльдә булачак.

## СЕРЕ БИК ГАДИ АНЫҢ

Узган ел Сабантуй мәйданын вакытында өлгертү өчен, башлап йөрүчеләргә авыл халкы кулларыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырышкан. Бакчаларыннан чәчәкләргә кадәр алып килеп утыртканнар. «Бу хәлләргә бик күңелем булды», – ди Җәлил хәзрәт, авыл халкын мактап.

Авыл кешеләре дә аларның җирлек өчен тырышып йөрүләрен белә. «Безнең Җәлил белән Сәйдәшнең өйләренә кайтып кергәне дә юк», – диләр. Әле кирәк документлар артыннан чыгып китәләр, әле программаларда катнашып булмасмы дип, җитәкчеләр ишеген шакыйлар, әле, резина итек киеп, төзүчеләр янында кайнашалар икән. Гомумән, аларның икесен дә авылда очрату бик читен. Гел эзләнүдә.

– Бөтен эшне дә авыл җирлеге башлыгына гына өю дөрес түгел, – ди Җәлил хәзрәт. – Ул ялгызы гына бөтенесенә дә өлгерә алмый. Һәркем үз авылы өчен тырышырга тиеш. Бергә-бергә эшләгәндә генә эшнең нәтиҗәсе күренә. Мин берәр нәрсә хакында уйланам икән, иң башта Сәйдәш белән киңәшләшәм. Аннан район җитәкчеләренә китәбез.

Җәлил хәзрәт авыл җирлеге каршында мәхәллә советы эшләргә тиеш, дигән уйда. Бу яңалыкны бөтен республика буенча кертергә кирәк, дигән фикердә ул. «Элек авылларда мәхәллә системасы булган, аны күтәрергә кирәк, диләр. Ул чорда авыл советы да, мәктәп тә, кумәк хуҗалыклар да булмаган, мәчет кенә эшләгән. Ә хәзер бөтенесе дә бар. Минемчә, безнең үрнәккә кушылып, берләшеп, киңәшләшеп эшләргә кирәк. Балтач районында бу уңайдан күпмедер эш башланды инде. Район сессиясенә авыл имамнарын чакыра башладылар. Авыл мулласы район, республика тормышы белән хәбәрдар булырга тиеш. Җыелышта программалар турында ишетеп кайткан имам, халыкка үтемле вәгазе белән җиткереп тора икән, бу да авыл җирлеге башлыгына зур ярдәм булачак», – ди ул. Юк, моның белән генә бетми әле аның тәкъдимнәре.

– Безнең авылда Коръән ашларында сәдаканы хуҗалар гына өләшә дә, килгән кунаклар тәлинкәгә сала, җыелган акча мәчеткә бирелә, – ди Җәлил хәзрәт. – Күп җирдә бу гадәт тә кермәгән. Сәдака авыл өчен эшләргә тиеш. Мин мәҗлесләргә күп йөрим, алып баручы итеп тә чакыралар. Зуррак суммадагы акчаны Сабантуй конвертына куеп барам. Дөрес, бөтен мулла да зур суммада акча туплый алмый. Әмма тамчыдан күл җыелуын онытмыйк. Бал корты да бал ясар өчен, меңәрләгән чәчәккә куна. Нәтиҗәсе юк дип тик ята икән, без бал ашый алмас идек. Бу очракта да шулай. Мулла авылы өчен эшләргә, аны яратырга тиеш.

Ә Җәлил хәзрәт үз авылын бик ярата. Кайларга гына чакырсалар да, туган җиреннән китмәгән. Ике малаен да авылда калдырган. Биш ел архивларда казынып авылның тарихын да өйрәнгән. Планлаштырган эшләре дә шактый әле. Моңа кадәр башлангыч мәктәп булып торган бинаны да төзекләндереп, читтән килгән балаларга дини уку йорты итәргә хыяллана.

– Без эшләгән эшләрне күрергә дип төрле җирләрдән килләр, – ди Сәйдәш Шәмсемөхәммәтович. – Алай гына түгел, сез ничек эшлисез, безне дә өйрәтегез әле дип сораучы җирлек башлыклары бар. Эш алымыбыз күпләрдә кызыксыну уята. Сере бик гади аның: бергәләп эшлибез.



**376 мең бакча кишәрлеге – бүген Татарстанда әнә шул санда исәпләнә. Аларның гомуми мәйданы – 28 мең га.** Республиканың 1 миллионнан артык гражданы бакчалары хисабына үзләрен җиләк-җимеш һәм яшелчә белән тәэмин итә, артык калганын базарларда сата. Күп кенә бакчачылык җәмгыятьләренең инфраструктурасы ремонтлану һәм реконструкциягә мохтаҗ. Сүз чүп-чар алып китү, автотраспорт чаралары, һәм шулай ук янгын сүндерү һәм башка махсус машиналар үтә алырлык 402 км лы керү юлы; 418 км лы электр тапшыру линиясе; 1600 км лы сүүткәргеч торба; 255 су кудыру манарасы; 240 насос станциясе; 154 скважина турында бара.



**32 торак йорт республикада 2016 елда арендалы торак программасы кысаларында төзелергә тиеш.** Аларның гомуми мәйданы 50,1 мең кв. метр булчак. Шулай ук күпфатирлы инвестицияле торак программасы буенча да 99 йорт салырга ниятлиләр.



**60 мең кеше, 2 мең предприятие һәм оешма Казанда агымдагы елның 23 апрелендә** узган гомумшәһәр өмәсендә катнашкан. Полигоннарга 8,5 мең тонна чүп-чар китерелгән.



**8,5 меңнән артык кеше, 38 илдән килеп, Казан марафоны-2016да катнашты.** 42,2 км лы марафон дистанциясеннән тыш, ярыммарафон дистанциясенә (21,1 км), 10 км һәм 3 км лы араларга йөгереш оештырылды. ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Казан алдында дөнья марафоннарының Топ-5легенә керү һәм масштабы буенча Бостон һәм Нью-Йоркныкына җитү бурычы тора, дип белдерде.



**98,5 млн сум акча республика муниципаль берәмлекләре җирлекләре советлары урнашкан биналарны төзекләндерүгә юнәлдереләчәк.** 78 бинаны ремонтлау күздә тотыла.

**21 объектны (20 муниципаль берәмлектә) 2016 елда Татарстан Республикасында** Су саклау елы кысаларында төзекләндерү күздә тотыла.



**43 объект (36 муниципаль берәмлектә) быел «Парклар һәм скверлар» программасына кертелгән.** Территорияләрне төзекләндерүгә 849 млн 506 мең сум акча бүлеп бирелгән.



**65 меңнән артык Бөек Ватан сугышы ветераны, сугышта һәм сугыштан соң үлгәннәрнең тол хатыннары Татарстанда яши – агымдагы елның май аена саннар әнә шундый.** Алар арасында 2658 сугышта катнашучы һәм инвалид, 57 мең 565 тыл хезмәтчәне, 3953 сугышта һәм сугыштан соң үлгәннәрнең тол хатыннары, 612 хәрәкәттәге армия составына кермәгән сугышта катнашучы, 214 элек яшүсмер килеш концлагерь тоткыны булганнар, 212 Ленинград блокадасында катнашучы бар.



**27 яшүсмерләр клубы быел республикада төзекләндереләчәк.** Программаны финанслау күләме 98,5 млн сумны тәшкил итәчәк.



**66 торак пункт – Татарстанның 125тән артык кеше яшәгән әнә шулкадәр авылы каты өслекле керү юлларыннан мәхрүм.** 2015 елда 62 авыл торак пункты каты өслекле юл белән тоташтырылган.






**Надил ГЫЙМАДЕТДИНОВ тексты.**
**Автор һәм Кадрия ГАМИРОВА фотолары.**

# *ЧИРМЕШӘН районы: киләчәккә инвестицияләр*


ЧИРМЕШӘН РАЙОНЫНЫҢ ЮГАРЫ КӘМИНКӘ АВЫЛЫНДА УЗГАН ЕЛДАН БИРЛЕ БЕР МЕҢ БАШ САВЫМ СЫЕРЫНА ИСӘПЛӘНГӘН СӨТ КОМПЛЕКСЫ ТӨЗЕЛЕШЕ АЛЫП БАРЫЛА. ГОМУМИ СМЕТА БӘЯСЕ 405 МИЛЛИОН СУМЛЫК ӘЛЕГЕ ИНВЕСТИЦИОН ПРОЕКТНЫ ЮГАРЫ КӘМИНКӘ АВЫЛЫНДА ТУЫП-ҮСЕП, ХӘЗЕРГЕ ВАКЫТТА ТҮБӘН ВАРТОВСК ШӘҺӘРЕНДӘ ЯШӘҮЧЕ ЭШКУАР ИЛЬЯС ХӘНӘФИЕВ ГАМӘЛГӘ КУЯ.

Эшкуарның эшлекле башлангычларында дәүләтнең дә өлеше бар. Чирмешәнле чыгымнарының бер өлешен агымдагы елда федераль бюджет каплый. Республика исә үз чиратында буаз сыерлар сатып алырга ярдәм итәчәк. «Илхан» ҖЧҖ мегафермасының заманча саву залы белән җиһазландырылган беренче чираты быел җәй көне үк кулланылышка тапшырылыр, дип планлаштырыла.

Бу вакыйганы Югары Кәминкә халкы түземсезлек белән көтә, алар әлеге терлекчелек комплексы авылга яңа сулыш өрер, халыкны даими эш белән тәэмин итәр һәм, ниһаять, яшьләрнең элек-электән суган үстерү белән шөгыльләнә торган торак пунктыннан китүен туктатыр, дип өметләнә.

Мегафермага район җитәкчелеге дә өмет баглый, инвестор муниципаль берәмлеккә сөт җитештерү буенча гомуми күрсәткечләрне күтәрергә ярдәм итәр, дип уйлыйлар.

– Безнең икътисадка нефтьчеләр зур өлеш кертә, – дип сөйли Чирмешән районы башлыгы Фердинат Дәүләтшин. – Район территориясендә 9 нефть компаниясе бар, алар «кара алтын» чыгару күләмнәрен елдан-ел арттырып баралар. Авыл хуҗалыгында, илнең тулаем аграр тармагындагы кебек үк, хәлләр





Югары Кәминкә авылы янында сөтчелек мегафермасы төзелеше.

***Республика программалары белән беррәттән, бүген районда хуҗалык итүнең кече формаларына булышлык итү буенча үз проектлары да актив рәвештә гамәлгә ашырыла. Мәсәлән, муниципаль бюджет токымлы башмак таналар сатып алуга киткән чыгымнарны каплау өчен субсидия, шулай ук җирле шәхси ярдәмче хуҗалыкларга һәм крестьян-фермер хуҗалыкларына, терлек асрау объектлары төзү максатына керамзит блоклар сатып алу өчен, 2 мең сумга кадәр акча бүлеп бирә.***

алай ук күңелле түгел, шулай да вазгыятьне йөгәнләргә була әле. Һәм монда без яңа инвесторларга һәм эшләп торган агрофирмаларга гына исәп тотмыйбыз, крестьян-фермерлык һәм шәхси хуҗалыкларга да җитди игътибар бирәбез.

Шушы максаттан республика программалары белән беррәттән, бүген районда хуҗалык итүнең кече формаларына булышлык итү буенча үз проектлары да актив рәвештә гамәлгә ашырыла. Мәсәлән, муниципаль бюджет токымлы башмак таналар сатып алуга киткән чыгымнарны каплау өчен субсидия, шулай ук җирле шәхси ярдәмче хуҗалыкларга һәм крестьян-фермер хуҗалыкларына, терлек асрау объектлары төзү максатына керамзит блоклар сатып алу өчен, 2 мең сумга кадәр акча бүлеп бирә.

## ИВАШКИНОНЫҢ КӨР КҮҢЕЛЛЕ ФЕРМЕРЫ

Ивашкино авыл җирлеге башлыгы Никонор Ефимов белән без Геннадий Макаровның гаилә фермасына бик үк уңайлы вакытта килеп кермәгән булып чыктык: басудан ашыгып кайтып кергән фермер хуҗалыгы җитәкчесе терлекчесе белән бергә сыер бозаулата иде.

– Ел башыннан бирле 24нче сыер бозаулый инде, тагын 9 буаз сыер калды, – дип аңлатып китте эштән бушагач Геннадий Федорович. – Аллага шөкер, бозауларның барысы да исән-сау. Менә шулар өчен аерым терлек абзары салырга ниятләп торам. Минем 50 баш сыя торган бинада озакламый аларга кысан булачак: алга таба тагын 20 савым сыеры алырга исәплим.

Бүген Макаровлар гаиләсенең активында 49 баш мөгезле эре терлек бар инде. Шуларның 30дан артыгы – сыерлар. Хуҗалыкта тәүлек саен ярты тоннага якын сөт савып алалар, аның күп өлешен Әлки районыннан Дамир Шәйхетдиновка тапшыралар. Фермер сүзләренә караганда, ул сатып алу хакы белән дә алдамый, вакытында акчасын биреп бара, өстәвенә, һәрвакыт финанс ярдәме күрсәтергә әзер. Мәсәлән, савым сыерлары көтүен арттыру өчен бер-ике миллион сум бурычка биреп торырга да вәгъдә иткән.



Ивашкино авылы фермеры Геннадий Макаров тормышка оптимизм белән карый.

*– Авылга, әти-әни янына кайтканыма бер дә үкенмим, – ди Раушан Шәйхетдинов. – Бергә-бергә эшләгәндә, эш тә күңеллерәк бара. Авылда да акча эшләп була, бары тик тырышлык һәм өлгерлек кирәк. Тормыш шартларына килгәндә, безнең Лашман шәһәрдән бер дә калышмый диярлек. Газ, су кергән, барлык урамнарга, хәтта тыкрыкларга да асфальт түшәлгән, мәдәният йорты эшли, берничә ел элек ФАП ачылды. Бассейнлы һәм ике спорт залы булган мәктәпкә теләсә кайсы шәһәр кешесе кызыгыр иде.*



ТР Президенты Рөстәм Миңнехановның Чирмешән районына эш сәфәре. (Уңда – район башлыгы Фердинат Дәүләтшин.)

Геннадий Макаровның һөнәре – терлекчелек буенча механик, кулында Чистай авыл хуҗалыгы техникумы дипломы бар. Тугыз ел җирле «Дружба» колхозында белгечлеге буенча эшләгән. Авыл хуҗалыгы предприятиесе таралгач, күпмедер вакыт районның газ куллану хезмәтендә эшләп алган, ләкин җирне ярату көчлерәк булып чыккан, һәм ару-талу белмәс крестьян агае үзен фермерлык буенча сынап карарга тәвәккәлләгән. Башта үсемлекчелеккә басым ясаган, әмма 2010 елгы каты корылыктан соң, 200 гектардан җыеп алган уңышны көч-хәл белән орлыкка җиткерә алгач, ул карашын терлекчелеккә төби. Шуңа да район җитәкчелеге аңа гаилә фермалары буенча республика программасында катнашырга тәкъдим иткәч, ул уйлап та тормыйча ризалык бирә. Ивашкино авылы читендә сыер фермасы төзелеше 2012 елда башланып китә, ә бер елдан соң анда савым сыерлары барлыкка килә. Шуннан бирле һәркөнне иртә белән бергә эш кайный башлый: терлекче янына ике сыер савучы да килеп кушыла. Тракторчының да тик утырырга вакыты юк. Кирәк булганда, мисал өчен, азык әзерләгәндә яки уңыш җыеп алу вакытында, фермер сезонлы эшчеләр яллый. Шулай да фермер Макаровның төп ярдәмчесе һәм киңәшчесе – улы Александр. Югары белемле энергетик һәм табигате белән аграрий, ул күпмедер вакыт шәһәрдә эшләп карый, ләкин үзенең язмышын бары тик туган авылында таба.

## ШӘҺӘР КЕШЕЛӘРЕН КӨНЛӘШТЕРЕП

Туган җирендә бүген Казан дәүләт аграр университетын тәмамлаган Раушан Шәйхетдинов та үз бизнесын булдырып ята. Әтисе Рәүфән белән ул бер елдан артыграк элек банкротлыкка чыккан «Лашман» агрофирмасы нигезендә фермер хуҗалыгы оештырганнар. Бүген анда 186 мөгезле эре терлек санала, шуларның 157се сыер.

Хайваннар өчен азыкны фермерлар 410 гектар чәчүлек җирендә әзерли, аның төп өлешенә кукуруз һәм берьеллык үлән чәчәләр. Якын араларда аталы-уллы фермерлар тагын 350 гектар җирне арендага алырга җыена. Шөкер, басуларда эшләр өчен кирәк булган барлык авыл хуҗалыгы техникасы бар үзләрендә. Шәйхетдиновларга гаилә эшен алып барырга биредәге ялланып эшләүчеләр ярдәм итә.

– Авылга, әти-әни янына кайтканыма бер дә үкенмим, – ди Раушан Шәйхетдинов. – Бергә-бергә эшләгәндә, эш тә күңеллерәк бара. Авылда да акча эшләп була, бары тик тырышлык һәм өлгерлек кирәк. Тормыш шартларына килгәндә, безнең Лашман шәһәрдән бер дә калышмый диярлек. Газ, су кергән,



Лашман авылыннан аталы-уллы Рәүфән һәм Раушан Шәйхетдиновлар.



Районда гаилә фермаларын үстерүгә зур игътибар бирелә.



Күптән түгел генә Лашманда Бөек Ватан сугышында катнашкан авылдашлары истәлегенә тантаналы рәвештә мемориаль комплекс ачылган.

барлык урамнарга, хәтта тыкрыкларга да асфальт түшәлгән, мәдәният йорты эшли, берничә ел элек ФАП ачылды. Бассейнлы һәм ике спорт залы булган мәктәпкә теләсә кайсы шәһәр кешесе кызыгыр иде.

Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, Лашман урта мәктәбен алты ел элек капиталь рәвештә үзгәртеп корганнар иде, бүген ул җирле халыкның гына түгел, ә бөтен Чирмешәннең горурлыгы булып тора. Әлеге вакытта биредә якын-тирәдә урнашкан биш авылдан 200 бала йөреп укый. 2014 елдан алып мәктәптә инвалид балаларны укыту практикасын башлаганнар. Уку-укыту учреждениесенең визит карточкасы булып җәядән ук ату секциясе тора – аңа энтузиаст педагог Фәиз Билалов җитәкчелек итә, ул әлеге спорт төрен яшьләр арасында популярлаштыру өчен барысын да эшли. Бу эштә ике ел элек мәктәптә Татарстан кубогы өчен җәядән ату ярышлары уздыру да зур ярдәм булган.

Лашманнан кала, шушы исемдәге авыл җирлегенә Әмир авылы да карый. Муниципалитетның ике торак пунктында барлыгы 1650 кеше яши. Ихаталарда терлек асрыйлар, 2015 елда гына да биш гаилә мини-ферма төзелеше өчен республикадан субсидияләр алган. Халык арасында теплицада яшелчә-җимеш үстереп сату киң таралган.

Былтыр җирлектә 50 миллион сумлык төзелеш эшләре башкарылган. Президент программасы кысаларындагы иң зур объект Әмирдә төзелгән – ул башлангыч мәктәп, балалар бакчасы һәм ФАП бер түбә астына алган күпфункцияле үзәк. Моннан тыш, Лашманга бара торган юлга ремонт ясалып, аңа асфальт түшәлгән, республика бюджеты акчасына авыл үзәгендәге буа төзекләндерелгән. Үзара салым акчасы да эшкә яраган: ике авылда да программа кысаларында урам утлары урнаштырылган, чүплек тәртипкә китерелгән, зират капкалары яңартылган, шулай ук үзәк авылның урамнарына тавыш көчәйткечләр куелган. Агымдагы елның үзара салым акчасын, Лашман авыл җирлеге башлыгы Рәфгать Фәттахов сүзләренә караганда, урам утлары системасын көйләп бетерү өчен тотарга ниятлиләр.

Әйтергә кирәк, җирлек тормышын яхшыртуга якташлар да иганә-хәйрия ярдәме күрсәтә. Әйтик, күптән түгел генә Лашманда Бөек Ватан сугышында катнашкан авылдашлары истәлегенә тантаналы рәвештә мемориаль комплекс ачылган. Һәйкәлне яңарту һәм аның тирәсендәге территорияне төзекләндерү буенча чыгымнарның төп өлешен ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров күтәргән.



2015 елда Чирмешән авылында ятим балалар өчен бер катлы дүрт йорт төзелде.

***Президент программасы кысаларындагы иң зур объект Әмирдә төзелгән – ул башлангыч мәктәп, балалар бакчасы һәм ФАП бер түбә астына алган күпфункцияле үзәк. Моннан тыш, Лашманга бара торган юлга ремонт ясалып, аңа асфальт түшәлгән, республика бюджеты акчасына авыл үзәгендәге буа төзекләндерелгән. Үзара салым акчасы да эшкә яраган: ике авылда да программа кысаларында урам утлары урнаштырылган, чүплек тәртипкә китерелгән, зират капкалары яңартылган, шулай ук үзәк авылның урамнарына тавыш көчәйткечләр куелган.***





2015 елда Чирмешән районында 23 яңа социаль объект сафка бастырылган. Алар арасында Ульяновка авылында ачылган модульле ФАП һәм 50 урынлык балалар бакчасы бар.

## ТОРМЫШ ТҮГЕЛ, «ӘКИЯТ»

Чирмешән районының башка торак пунктларының да тышкы кыяфәте көннән-көн уңай якка үзгәрә. 2015 елда гына да авылларны төзекләндерү, инженерлык челтәрләрен реконструкцияләү, социаль-мәдәни өлкә объектларын төзү һәм булганнарына капиталь ремонт ясау буенча биредә 835 миллион сумлык эш башкарылган.

Район актив рәвештә берничә федераль һәм республика күләмендәге программада катнаша. Мисал өчен, узган елда районда яшәп, шунда эшләүче 37 яшь гаилә һәм яшь белгеч торак шартларын яхшырту өчен субсидияләр алган.

Моннан тыш, 2015 елда президент программалары кысаларында районда 7 күпфатирлы йортка, 4 ФАПка, 3 авыл мәктәбенә һәм Чирмешән лицеена, Ивашкино авылындагы балалар бакчасына, «Кояшлы» балалар сәламәтләндерү лагерена, 4 авыл мәдәният йортына һәм башка объектларга капиталь ремонт ясалган.

Параллель рәвештә 23 яңа социаль объект кулланылышка тапшырылган. Аерым алганда, 2015 елның сентябрендә Чирмешән авылында 9 Бөек Ватан сугышы ветераны һәм сугышта катнашучыларның тол калган хатыннарына яңа йортлардан ачкычлар тапшырылган. Яңа ел алдыннан Чирмешән авылында Бакчалы урамының бер катлы дүрт йортында ятим балалар өй туе үткәргән. Һәр йортның торак мәйданы 42 квадрат метр тәшкил итә. Аларга коммуникацияләр үткәрелгән, ут, газ, кайнар һәм салкын су кергән.

***Җирлек тормышын яхшыртуга якташлар да иганә-хәйрия ярдәме күрсәтә. Әйтик, күптән түгел генә Лашманда Бөек Ватан сугышында катнашкан авылдашлары истәлегенә тантаналы рәвештә мемориаль комплекс ачылган. Һәйкәлне яңарту һәм аның тирәсендәге территорияне төзекләндерү буенча чыгымнарның төп өлешен ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров күтәргән.***

Илгиз һәм Лилия Гыйрфановлар гаиләсе үзләренең яңа оясына Түбән Кәминкә авылыннан күчеп килгән – Илгиз 12 яшендә Гарифуллиннар гаиләсенә тәрбиягә алынган булган.

– Безгә өебез бик ошый. Тыштан караганда зур түгел кебек, әмма эчтән иркен һәм җылы, – ди Илгиз Гыйрфанов. – Кышны җиңел үткәрдек. Өйдә электр уты белән җылытыла торган мунча булуы да бик рәхәт.

Бүген Гыйрфановларның яшь гаиләсе бәби турын-



2015 елның сентябрендә ветераннарга яңа йортлардан ачкычлар тапшырылды.



Халык арасында теплица бизнесы популяр.



Чирмешән районы икътисадының нигезендә нефть тармагы ята.

да да җитди уйлана. Шунысы яхшы: туачак баланы бакчага урнаштыру белән кыенлыклар килеп чыгарга тиеш түгел. Былтыр гына нәкъ аларның өй каршында диярлек «Әкият» дигән исем йөртүче зур һәм матур балалар бакчасы ачылган. Анда 80 бала йөриячәк. Биредә балалар өчен дә, тәрбиячеләр өчен дә уңайлы шартлар тудырылган. Уен, йокы бүлмәләре, ашарга пешерү, кер юу блоклары заманча итеп җиһазландырылган.

Ульяновка авылы балалары да хәзер уңайлы шартларда үсә – биредә узган елның сентябрендә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашлыгында «Йолдызчык» балалар бакчасы ачылган иде. Бүген 335 кеше яши торган авылда моңа кадәр үзенең мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе юк иде.

– Хәзерге вакытта дәүләт авылны ташлады, дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә, – дип фикер йөртә Ульяновка авыл җирлеге башлыгы Самат Шәмсетдинов. – Мин бу сүзләр белән килешмим. Безнең җирлек районда эреләрдән санала. Аның составына 5 торак пункт керә. Соңгы елларда аларның социаль-мәдәни инфраструктурасы күзгә күренерлек булып яхшырды. Шул сәбәпле без халыкның авылдан күпләп чыгып китү тенденциясен туктата алдык. Үзегез уйлап карагыз, 2012 елда Кызлар Аланы авылында ФАП белән бер түбә астына урнаштырылып төзелгән Мәдәният йорты ачылды. Ике елдан соң үзәк утарда мәдәният учагына капиталь ремонт ясалды. 2015 елда шушында ук балалар бакчасы, модульле ФАП кулланылышка тапшырылды, Сосновка авылында күпфункцияле үзәк ачылды.

Соңгысы 100 кеше сыйдыра алырлык Мәдәният йортын, фельдшер-акушерлык пунктын һәм күчмә китапханәне берләштерә. Аңа кадәр 15 ел буена Сосновка халкының мәдәни тормышы, күп дигәндә берьюлы 20 кешене сыйдыра ала торган клуб ролен үтәүче зур булмаган бер йортта үткән. Сосновка авыл клубы мөдире Нина Иванова сүзләренә караганда, хәтта шушы кысан оя да алар өчен сарай булып тоелган, чөнки авыл кешеләре элек-электән, клуб дигәннәре истә дә булмаганда әле, үзешчән сәнгатьтә актив катнаша торган булганнар. Шуңа да күпфункцияле үзәк ачылышын биредә дулкынланып көтеп алганнар. Бүген аның ишекләре һәрвакыт ачык. Клубта яшьләрнең «Шанкарав» вокаль ансамбле, пенсионерларның «Авал» фольклор ансамбле, җыр сөючеләрнең «Милли фольклор» берләшмәсе һәм «Дымков уенчыклары», «Варюшка», «Хуҗабикә» остакуллар түгәрәкләре эшләп килә. Агымдагы елда республика мелиораторлары көче белән күпфункцияле үзәк янәшәсендәге буа тәртипкә салыначак.




Сосновка авылындагы күпфункцияле үзәккә 100 урынлык Мәдәният йорты, ФАП һәм күчмә китапханә сыйган.

***2015 елның сентябрендә Чирмешән авылында 9 Бөек Ватан сугышы ветераны һәм сугышта катнашучыларның тол калган хатыннарына яңа йортлардан ачкычлар тапшырылган. Яңа ел алдыннан Чирмешән авылында Бакчалы урамының бер катлы дүрт йортында ятим балалар өй туе үткәргән. Һәр йортның торак мәйданы 42 квадрат метр тәшкил итә. Аларга коммуникацияләр үткәрелгән, ут, газ, кайнар һәм салкын су кергән.***



«ТАТАРСТАНДА ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ МУНИЦИПАЛЬ ХАКИМИЯТ ӨЧЕН ИҢ ӘҺӘМИЯТЛЕ ЯҢА ЗАКОННАРГА ҺӘМ НОРМАТИВ АКТЛАРГА, ШУЛАЙ УК ФЕДЕРАЛЬ ҺӘМ РЕСПУБЛИКА ЗАКОННАРЫНА КЕРТЕЛГӘН СОҢГЫ ҮЗГӘРЕШЛӘРГӘ КҮЗӘТҮ ЯСЫЙ.

**«Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының нигезләре турында» Федераль законның 11 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 26 апрелендәге 113-ФЗ номерлы Федераль закон.**

Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү буенча җирле хакимият вәкаләтләре төгәлләштерелде. Төзәтмәләр «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының нигезләре турында» Федераль законга элек кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә федераль законнарда һәм хокук куллану практикасында барлыкка килгән каршылыкларны бетерә. Алар югарыда аталган комиссияләрнең хокукый статусын үзгәртте. Моңа кадәргесе буенча, хокук куллану практикасында муниципалитетлар территорияләрендә эшли торган комиссияләрне төзү вәкаләтен финанслау һәм җирле хакимияткә тапшырыла торган вәкаләтләрдән күрсәтелгән вәкаләтне алу өлешендә төбәк законнарына үзгәрешләр кертүнең зарур булуы турындагы мәсьәләне хәл иткәндә нормалар төрлечә аңлатыла иде. Моннан тыш, үзгәрешләр комиссияләр эшчәнлеген федерациянең аерым субъектларында оештыруның үзенчәлекләрен исәпкә алмый иде. Сүз җирле үзидарә органнарына комиссияләр төзү вәкаләтләре бирелмәгән регионнар турында бара. Урыннардагы комиссияләр территориаль була һәм турыдан-туры региональ хакимият тарафыннан төзелә. Мондый вазгыять Коми-га, Төньяк Осетия – Аланиягә, Башкортостанга, Архангельск, Курган, Белгород, Ярославль өлкәләренә хас иде.

Моңа бәйле рәвештә, әгәр җирле үзидарә органнарына федерация субъекты законы белән тиешле вәкаләтләр бирелсә, мондый комиссияләрнең алар тарафыннан төзелү мөмкинлеге каралды. Шул ук вакытта регионнарның югары башкарма хакимияте органнары комиссияләрне, әгәр җирле хакимияткә мондый вәкаләт бирелмәгән булса, муниципалитетлар территорияләрендә төзергә хокуклы.

**Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 13 маендагы 890-р номерлы күрсәтмәсе.**

Документта дәүләт сатып алуларын башкарганда заказчы тарафыннан электрон аукцион уздыру мәҗбүри булмаган эшләр исемлеге тәгаенләнде. Дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен биналар, корылмалар, аларны төзүгә караган эшләр, махсуслашкан төзелеш эшләрен һәм гражданнар өчен төзү өлкәсенә караган эшләрне сатып алганда, заказчы, гомуми кагыйдәләргә таянып, электрон аукцион уздырырга тиеш, ләкин кайбер эшләр моннан чыгарылма була ала.

Аеруча куркыныч, техник яктан катлаулы һәм уникаль капиталь төзелеш объектларын, шулай ук федераль, региональ яки муниципалитетара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары составына кертелгән ясалма юл корылмаларын төзү,

реконструкцияләү, капиталь ремонтлау эшләрен дәүләт тарафыннан сатып алу өчен электрон аукцион уздыру мәҗбүри түгел.

Әгәр бу кагыйдә элек контрактның башлангыч (максималь) бәясе 150 млн сум (дәүләт ихтыяҗлары өчен) һәм 50 млн сум (муниципаль ихтыяҗлар өчен) булганда кулланылган булса, хәзер исә күрсәтелгән эшләргә контракт бәясе теләсә нинди булганда электрон аукцион уздыру мәҗбүри түгел.

**Россия Федерациясе Конституция Судының «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 51 статьясы нигезләмәсе белән конституциячел хокуклары бозылу буенча гражданнар Агафонов Андрей Георгиевич, Агафонова Наталья Игоревна һәм башкаларның шикаятьләрен карауга алудан баш тарту хакында» 2016 елның 25 февралендәге 405-О номерлы билгеләмәсе.**

Шикаятьтә муниципаль мөлкәткә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итүгә кагылышлы нормаларга дәгъва белдерелгән. Гариза бирүчеләрнең (берничә гражданның) фикеренчә, кайбер нигезләмәләр конституциягә туры килми, чөнки алар муниципаль милеккә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү хокукларыннан мәхрүм итәләр. Тулаем алганда, нәкъ җирле халык һәм аны тәшкил иткән гражданнар аерым-аерым (гариза бирүчеләр күзлегеннән) муниципаль мөлкәтнең милекчеләре булып торалар, ә җирле үзидарә органнары исә бары тик алар белән идарә итүчеләр генә.

Мондый дәлилләрне инкяр итеп, Россия Федерациясе Конституция Суды түбәндәгеләрне аңлатты.

Конституция нигезләмәләренең эчтәлегенә бәйләнешле карасак, халык җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне турыдан-туры бары тик җирле референдумда гына хәл итә ала. Шул ук вакытта җирле референдумга җирле әһәмияттәге теләсә нинди мәсьәләнең чыгарыла алуы күздә тотылмый. Гамәлдәге законнарда каралганча, җирле референдум мәсьәләләре һичьюгы федераль һәм региональ законнарга каршы килергә тиеш түгел.

Әйтик, җирле бюджетны һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау, муниципаль милектәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибен билгеләү муниципалитетның вәкиллекле органының махсус компетенциясенә керә. Бюджет кабул итү яки аны үзгәртү, муниципалитетның финанс йөкләмәләрен үтәү һәм үзгәртү турындагы мәсьәләләр җирле референдумга чыгарыла алмый.

Шулай итеп, әлеге мәсьәләләр турыдан-туры муниципаль берәмлек халкы тарафыннан хәл ителә алмый.

**Россия Федерациясе Конституция Судының «Нерюнгрино районы» муниципаль берәмлеге администрациясе шикаятенә бәйле рәвештә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 18 пунктының һәм 15 статьясындагы 1 өлешенең 14 пунктының конституциягә туры килү-килмәвен тикшерү хакындагы эш буенча» 2016 елның 26 апрелендәге 13-П номерлы карары.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Закон шәһәр җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерып җыю) һәм транспортта ташу эшчәнлеген оештыруда катнашуны да кертә. 2016 елның 1 гыйнварына кадәр сүз көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны җыю һәм алып китүне оештыру турында бара иде. Ә муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә тиешле муниципаль районнар территорияләрендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерып җыю), транспортта ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу карый. Элек  көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерүне һәм эшкәртүне оештыру иде.

РФ Конституция Судына рөхсәтсез барлыкка килгән чүп-чар өемен юкка чыгару буенча прокурор дәгъвасы таләбен алган муниципаль район администрациясе мөрәҗәгать итте. Ул өем әлеге муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан урман фонды җир кишәрлегендә билгесез затлар тарафыннан барлыкка китерелгән булган.

РФ Конституция Суды хокук нормаларында муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына, әгәр ул органнарга тиешле дәүләт

вәкаләтләре бирелмәгән булса, рөхсәтсез барлыкка килгән мондый чүп-чар өемнәрен җирле бюджет акчалары исәбеннән бетерү бурычларын йөкләүнең элек тә каралмавын һәм хәзер дә булмавын таныды.

РФ Конституция Суды элегрәк бер охшаш мәсьәләне карап тикшергән иде инде, ләкин ул шәһәр округының җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә карый иде. Әле шул вакытта ук ул шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына мондый чүп-чар өемнәрен бетерү бурычлары аларга тиешле дәүләт вәкаләтләре бирелми торып йөкләнә алмый, дип билгеләнгән иде.

Шушы очракта шикаять белдерелгән нормалар үз көчен саклап калган хокукый якны исәпкә алып аңлатылырга һәм кулланылырга тиеш иде. Ләкин хокук куллану органнары моңа игътибар бирмәгәннәр.

Моңа бәйле рәвештә РФ Конституция Суды норманың конституциячел-хокукый мәгънәсе ачыла торган үз хөкемнәренең юридик нәтиҗәләрен ассызыклады. Бу очракта әлеге нормага нигезләнгән, йә аңа охшаш булган яки аны кабатлый торган башка норматив хокукый актларның нигезләмәләре ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәгә каршы кулланыла алмый.

**Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең «Элекке дәүләт хезмәткәрен һәм муниципаль хезмәткәрне эшкә алучы эш бирүчегә белешмәлек җибәрү турында» 2016 елның 23 мартындагы 04-42 номерлы хаты.**

Белешмәлек коррупциягә каршы тору максатларында эшләнде. Законнарда элекке дәүләт хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен эшкә урнашуга кагылышлы чикләүләр билгеләнгән, шуңа күрә аларны эшкә алырга теләгән эш бирүче элекке хезмәткәрдән элек ул эшләгән вазыйфаның махсус вазыйфалар исемлегенә керү-кермәвен ачыкларга тиеш. Аны белешмә-хокук системаларында, дәүләт органнарының рәсми сайтларында табарга, шулай ук әлеге дәүләт органнарына соратулар юллап, тиешле мәгълүматны алырга мөмкин. Эшкә алучы элекке хезмәткәрләрнең элек эшләгән вазыйфаларыннан азат ителүләренә һәм хезмәттән чыгарылуына 2 ел үтү-үтмәвен ачыкларга тиеш. Әгәр шул вакыттан 2 елдан кимрәк вакыт узган булса, эш бирүче 10 көн эчендә элекке хезмәткәрнең соңгы эш урыны буенча эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә шартнамә төзү турында хәбәр итәргә тиеш. Белешмәлектә мондый хәбәрнамәгә кертелергә тиешле мәгълүматлар санап үтелгән.

**«Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2016 елның 5 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.**

Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр (ТОСЭР) резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкалары билгеләнде.

5 процент күләмендәге салым ставкасы ТОСЭРда эшчәнлек башкару турында килешүне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән салым исәбе мәгълүматлары буенча беренче табыш алынган салым чорыннан башлап биш салым чоры дәвамында гамәлдә булачак. 10% күләмендәге ставка алтынчы салым чорыннан башлап унынчы салым чорына кадәр билгеләнә.

Әгәр резидент өч салым чоры дәвамында (салым түләүче резидентлар реестрына кертелгән салым чорыннан башлап) табыш алмаган булса, югарыда күрсәтелгән сроклар дүртенче салым чорыннан исәпләнә башлый.

Билгеләнгән салым ставкалары ТОСЭРда эшчәнлек башкару турында килешүне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән алынган (эшчәнлеккә бәйле тотылган) керемнәрнең (чыгымнарның) һәм башка эшчәнлек башкарганда алынган (тотылган) керемнәрнең (чыгымнарның) исәбе резидентлар тарафыннан һәркайсы аерым алып барылганда гына кулланыла. Закон 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 3 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.**

Татарстан Республикасында җирле үзидарә

турындагы ТР Законы федераль законнарга туры китерелде. Республиканың муниципаль берәмлекләре реестрын алып бару тәртибен җайга сала торган нигезләмә төшереп калдырылды.

Россия муниципаль берәмлекләренең дәүләт реестрын алып бару РФ Хөкүмәте тарафыннан РФ Юстиция министрлыгының территориаль органнарына тапшырылды. Реестрдагы белешмәләр һәркем өчен дә ачык, һәм алардан һәркем файдалана ала. Моңа бәйле рәвештә Татарстан муниципаль берәмлекләре реестрын алып бару ихтыяҗы бетте.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органына өстәмә бурычлар йөкләнде. Ул, муниципаль берәмлекләр чикләрен билгеләү яисә үзгәртү турында Татарстан Республикасы законнары кабул ителгән очракта, җир төзелеше объектларының карталарын (планнарын) кадастр исәбенә алу органнарына җибәрәчәк.

### «Татарстан Республикасында гражданнарның эконом классы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 26 мартындагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

Татарстан Республикасында гражданнарның эконом классы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турындагы ТР Законы башка законнарга туры китерелде.

Үзгәрешләр кертү өчен җирле үзидарә органнарының аерым өлкәләрдәге (юллар хезмәте эшчәнлеге, җирдән файдалану, коммуналь хуҗалык, әйләнә-тирә мохитне саклау, табигатьтән файдалану, мәдәният һ.б.), шул исәптән торак төзелеше өлкәсендәге вәкаләтләренең федераль законнарда төгәлләштерелүе нигез булды.

Моннан тыш, эконом класслы торакны сату-алу шартнамәләре яисә аларны өлешле төзүдә катнашу шартнамәләре төзелергә тиешле гражданнарның исемлекләренә үзгәрешләр кертү өчен нигез булырлык шартлар исемлеге киңәйтелде. Мәсәлән, мондый исемлекләргә үзгәрешләр кертү шартнамә нигезендә төзелә торган эконом класслы торакның гомуми санын арттыруга китермәсә, гражданнан аны мондый исемлеккә кертү турында гариза алынганда.

### «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы

Закон Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәтен формалаштырганда һәм гамәлгә ашырганда сәнәгать өлкәсендә эшчәнлек башкаручы субъектлар, әлеге эшчәнлеккә ярдәм итү инфраструктурасы составына керүче оешмалар, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары арасында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала.

Сәнәгать сәясәтенең система барлыкка китерү максатлары продукциянең көндәшлеккә сәләтлелеген һәм сәнәгатьнең техник дәрәҗәсен арттырудан, инновацион продукцияне һәм югары технологияләрне эчке һәм тышкы базарларга чыгаруны тәэмин итүдән, импорт продукциясен алмаштырудан һ.б. гыйбарәт.

Җирле үзидарә органнарына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын гамәлгә ашыру хокукы бирелде.

Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чаралары билгеләнде. Аларга сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү, импортны алмаштыруны, сәнәгать кооперациясен үстерүгә ярдәм итү, сәнәгать өлкәсендә фәнни-техник эшчәнлеккә һәм инновация эшчәнлегенә ярдәм итү керә. Шулай ук сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына аларның кадрлар потенциалын үстерү өлкәсендә һәм тышкы икътисадый эшчәнлек өлкәсендә ярдәм, мәгълүматконсультация ярдәме, сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына аларның РФ һәм ТР дәүләт программаларында катнашу мәсьәләләрендә һ.б. ярдәм күрсәтеләчәк;

Республика исеменнән махсус инвестиция контрактын төзү, индустриаль (сәнәгать) паркларны һәм сәнәгать паркларына карата сәнәгать өлкәсендә эшчәнлекне кызыксындыру чараларын куллану тәртибе билгеләнде.

Закон составында спирт булган азык-төлек продукциясе, алкоголь продукциясе һәм тәмәке әйберләре җитештерүгә бәйле мөнәсәбәтләргә карата кулланылмый.



АГЫМДАГЫ ЕЛНЫҢ АПРЕЛЬ АЕНДА РЕСПУБЛИКАДА МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘР ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ ӨЧЕН ТР ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ ҺӘМ ТР МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ СОВЕТЫ ОЕШТЫРГАН СЕМИНАР-КИҢӘШМӘЛӘР БУЛЫП УЗДЫ. УКУДА АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕ БАШЛЫКЛАРЫ, РАЙОН БАШЛЫКЛАРЫ УРЫНБАСАРЛАРЫ, МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЛАРЫ АППАРАТЛАРЫНЫҢ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ КАТНАШТЫ. СЕМИНАРЛАР БАРЫШЫНДА ОЕШТЫРУЧЫЛАР ИСЕМЕНӘ КАТНАШУЧЫЛАРДАН СОРАУЛАР КИЛДЕ, АЛАР МУНИЦИПАЛИТЕТЛАР ҮСЕШЕНДӘГЕ АКТУАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАРГА КАГЫЛА ИДЕ. ЖУРНАЛНЫҢ ӘЛЕГЕ САНЫНДА БЕЗ СОРАУЛАРНЫҢ БЕР ӨЛЕШЕНӘ ТР МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ СОВЕТЫНЫҢ ЮРИДИК ИДАРӘСЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ ТАРАФЫННАН ӘЗЕРЛӘНГӘН ҖАВАПЛАРНЫ БИРӘБЕЗ.

# СОРАУ – *җавап*

**- Сорауларның зур өлеше түбәндәге чараларны финанслауга һәм аларны башкару вакытына кагыла - иске карьерларны рекультивацияләү, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү һ.б. Семинарда катнашучыларны кайсы очракарда югарыда күрсәтелгән чараларны үтәмәгән өчен административ җаваплылыкны урап узарга мөмкин булуы кызыксындырды.**

– 2015 елның 5 октябрендә 288-ФЗ санлы Федераль закон кабул ителде. Ул Россия Федерациясе Кодексының 24.5 маддәсенә һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 77 маддәсенә үзгәрешләр кертте. Бу үзгәрешләрнең асылы түбәндәгедән гыйбарәт.

РФ Административ хокук бозулар кодексының 24.5 маддәсе 4 нче өлеш белән тулыландырылган, аңа ярашлы рәвештә, әгәр вазыйфаи зат, муниципаль учреждение җитәкчесе җирле үзидарә органының әлеге вәкаләтләрен тормышка ашыру, муниципаль учреждениенең уставта куелган бурычларын үтәү өчен, үз вакытында (ягъни шундагы җирле бюджет проектын формалаштыру тәртибенә һәм вакытына ярашлы) бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирү тәкъдиме белән мөрәҗәгать иткән булса, һәм шул ук вакытта әлеге максатларга бюджет акчалары бүленмәгән булса, вазыйфаи затка (башкарма комитет җитәкчесенә, җирле үзидарә органының башка вазыйфаи затына), муниципаль учреждение җитәкчесенә карата административ хокук бозу турындагы эш туктатылырга тиеш.

Бу, әгәр бюджетта чыгымнарны алдан исәпләргә кирәк булса (мисалга, янгынга каршы чаралар күрү, карьерда эшләгәннән соң бозылган җирне рекультивацияләү, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү яки җирле әһәмияттәге башка мәсьәләне хәл итү өчен), ул чагында муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты җитәкчесе җирле бюджетны кабул иткәнче, язма рәвештә әлеге муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органына (Советына) (район башлыгына түгел) югарыда күрсәтелгән максатларга бюджет ассигнованиеләре бүлү турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә тиеш, дигәнне аңлата. Шушы ук кагыйдәләр муниципаль учреждение җитәкчеләренә дә кагыла.

Совет, әлеге мөрәҗәгатьне карап, карар кабул итә. Әлеге мөрәҗәгать һәм Советның аның буенча кабул ителгән карары административ хокук бозулар турындагы эшне туктату өчен нигез булып тора.

Бу процедура үтәлмәгән, һәм контроль-күзәтчелек органы кагыйдә бозуларны туктату турында боерык биргән булса, бу вакытта 131-ФЗ санлы Федераль законның 77 маддәсенә кертелгән үзгәрешләргә ярашлы, дәүләт контроле (күзәтчелек) органы кагыйдә бозуларны туктату өчен бирелгән вакытта җирле үзидарә органнарының РФ законнары тарафыннан куелган таләпләрне һәм процедураларны да үтәргә тиешлеген искә алырга тиеш.

Мәсәлән, прокурор авыл җирлегенең җирле үзидарә органына бозылган җирләрне (карьерда законсыз рәвештә эшләү нәтиҗәсе буларак) ике ай вакыт эчендә рекультивацияләү таләбен куеп, судка мөрәҗәгать итә.

Бозылган җирләрне ике ай вакыт эчендә рекультивацияләү мөмкин түгел, чөнки моңа эш күләмен билгеләү өчен рекультивацияләү проектын эшләргә, чыгымнар сметасын әзерләргә кирәк. Шулай ук рекультивация эшләре һава торышы белән бәйле көзге, язгы һәм кышкы чорда башкарылмавын да истә тотарга кирәк.

Муниципаль берәмлекнең бюджеты елга бер тапкыр гына формалашуы, ә бозылган җир кишәрлекләрендә торгызу эшләре башкару өчен, беренче чиратта, әлеге эшләрне финанслау чыганакларын табарга һәм ул чыгымнарны авыл җирлегенең киләсе ел бюджетына кертү турында тәкъдим кертергә кирәк булу сәбәпле, бозылган җирләрне рекультивацияләү буенча таләпне билгеле бер вакытка (мәсәлән, 1 елга) соңрак үтәү турында судка гариза бирергә кирәк. Башка очракларда да шушылай эшләү кулай.

**- Барлык норматив һәм хокукый актлар Интернет челтәренә куела барырга тиеш. Без әлеге актларны Интернетка куючы оешмалар белән килешүләр төзибез. Кызганычка каршы, алар актларны урнаштыру буенча эшләрне һәрвакытта да үз вакытында үтәми. Бөтен районнарның хокукый актларын җыеп, Интернетка элеп бара торган үзәкләштерелгән бердәм сервер булдыру мөмкин түгелме?**

– Татарстан Республикасында массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлгән һәм рәсми хокукый мәгълүматларны урнаштырып бару өчен барлыкка килгән «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) (алга таба – портал) бар. Әлеге портал дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының барлык норматив хокукый актларын рәсми рәвештә челтәргә элеп баруны тәэмин итә, анда хокукый актларны тәүлек әйләнәсендә иректә рәвештә кереп карап була. Шулай да портал муниципаль берәмлекнең уставында муниципаль норматив хокукый актларны рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка күрсәтү) чыганаклары исемлегенә турыдан-туры кертелгән булса гына, биредә бастырып чыгару ысулы рәсми санала. Үзәкләштерелгән бердәм сервер булдыру, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталы» оештырылу сәбәпле, максатка ярашлы түгел.

Норматив хокукый актларны Интернет челтәренә урнаштыру турында билгеле бер оешма белән килешү төзегәндә, «Килешүнең төп шартлары» бүлегендә башкаручы үтәргә тиешле эшләр кысаларында хезмәт күрсәтү вакыты турындагы шартны яңадан карарга киңәш итәбез.

**- Мамадыш муниципаль районының Красногорск авыл җирлегендә 2014 елда 7 ТИҮ барлыкка килеп, шуларның берсе республика бюджетыннан финанслана иде. Без башка ТИҮләргә «Мамадыш» совхозы ягыннан ярдәм булыр, дип өметләнгән идек, чөнки алар шул территориядә урнашкан. Ләкин ярдәм булмады. Җирлек территориясендә барлыгы 5324 кеше яши. ТИҮләр - безнең бердәнбер ярдәмчеләребез. Җирле үзидарә органнарының штатында 4 кеше. Кайбер көннәрдә безгә төрле мәсьәләләр буенча 40лап кеше мөрәҗәгать итә. Авыл җирлегендәге ТИҮләргә ярдәм итегез.**

– Безнең республикада ТИҮләр эре шәһәрләрдә дә, авыл җирлекләрендә дә оештырылды. Авыл җирлекләренең күпчелегендә халык саны ике меңнән дә артмый. Бу шәһәрдәге бер ТИҮ территориясендәге халык санынннан күпкә аз.

Халык саны ике мең кешедән артып киткән авыл җирлекләре гомуми саннан нибары 8 процент тәшкил итә. ТИҮләр халык белән җирле хакимият арасында бәйләп торучы звено ролен үти, алар хакимиятне халыкка якынайта. Шуңа да авыл җирлегендә (җирле үзидарә органнарына өстәмә рәвештә) ТИҮләр оештыру артык.

Территориаль иҗтимагый үзидарәләргә дәүләт ярдәменең төп бурычы – нәкъ менә шәһәр ТИҮләренең үсешенә булышлык итү. Шуңа бәйле рәвештә, ТР Муниципаль берәмлекләре Советы Президиумы тарафыннан 2015 елның 20 ноябрендә кабул ителгән карарда 2016 елда шәһәр округларында һәм шәһәр җирлекләрендә оештырылган, халык саны 500дән дә кимрәк булмаган ТИҮләргә генә компенсация бирү турында әйтелә.

Шулай да муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары ТИҮ кирәк дип саный икән, 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131нче Федераль законның 27 маддәсенә ярашлы, алар ТИҮләргә җирле бюджет хисабына ярдәм күрсәтергә хокуклы. Әлеге нормага ярашлы, җирле бюджеттан кирәкле акча бүлү шартлары һәм тәртибе муниципаль берәмлекнең уставы һәм (яки) муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.





# ПРОФЕССИОНАЛЛАР өчен стимул

Муниципалларның һөнәри бәйрәме – Җирле үзидарә көне алдыннан Казанда, ТР Дәүләт Советы бинасында, ТР Муниципаль берәмлекләре Советы инде ун ел дәвамында үткәреп күркәм гадәткә керткән республика конкурсларында катнашучыларны бүләкләү тантанасы булды. Беренче бәйге 2006 елда, республикада җирле үзидарә системасы торгызыла гына башлаган чорда уздырылган иде. Җиңүчеләр барлыгы өч конкурс кысаларында билгеләнә: «Муниципаль идарә тармагында иң яхшы хезмәткәр», «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә иң яхшы иҗтимагый инициатива» һәм «Массакүләм мәгълүмат чараларында җирле үзидарә темасын иң яхшы яктырту».

Бәйгедә катнашырга теләүчеләр саны елдан-ел арта. Былтыр конкурс комиссиясенә 110 гариза бирелсә, быел инде 15 номинация буенча 164 гариза кергән. Быелгы бәйгеләрдә җиңүчеләрне ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров, ТР Дәүләт Советы вице-спикеры Римма Ратникова, ТР Президент Аппараты җитәкчесе урынбасары – ТР Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе җитәкчесе Илнур Гарипов сәламләде. Чарада шулай ук министрлык һәм ведомстволарның җаваплы хезмәткәрләре, республика муниципаль бергәлеге һәм ММЧ вәкилләре катнашты.

Җиңүчеләрне тәбрикләгәндә, ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров муниципаль берәмлекләр арасында республика конкурсларны үткәрү традициясенең җирле хакимият органнары эшчәнлеген камилләштерүнең мөһим юнәлеше булуына басым ясады. Муниципаль хакимият алдында күп бурычлар тора – җирле үзидарәне ныгыту, аның финанс мөстәкыйльлеген һәм ресурс мөмкинлекләрен киңәйтү. Муниципаль хакимият структураларына квалификацияле белгечләр һәм идарәчеләр килүе өчен шартлар тудыру зарур.

Минсәгыйть Шакиров муниципалларга нәтиҗәле эшләре өчен рәхмәтен җиткерде: «Бүген, бәйрәм алдыннан, барыгызга да зур рәхмәт әйтәм. Хакимиятнең халыкка иң якын баскычы булган җирле үзидарә органнары, көн саен меңләгән катлаулы мәсьәлә һәм проблеманы хәл итеп, халыкка уңай яшәү шартлары тудыра».

Бүләкләү тантанасында катнашучыларга сәламләү сүзләре белән Татарстан парламенты Рәисе урынбасары Римма Ратникова һәм ТР Президенты Аппараты җитәкчесе урынбасары Илнур Гарипов та мөрәҗәгать итте. Аннары конкурста җиңүчеләргә һәм лауреатларга, бу исә җиде дистәдән артыграк кеше, ТР Муниципаль берәмлекләре Советының махсус дипломнары, акчалата һәм кызыксындыру бүләкләре тапшырылды.








ТАТАРСТАН
ШАКИРОВ
РАТНИКОВА












*Татарстан муниципаллары журналы*







**Язылу индекслары:**

**П2268**

**татар телендә**

**П2258**

**рус телендә**

**Журналга барлык элемтә бүлекләрендә язылырга була**